Рим Идиатуллин

Хәерле кич!

***Шигырьләр, кечкенә драмалар,***

***Хикәятләр***

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2007
УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
И27
Төзүчесе һәм соңгы сүз авторы

***Роберт Миңнуллин***

**Идиятуллин Р.З.**

Хәерле кич!: шигырьләр, кечкенә драмалар, хикәятләр / Рим Идиятуллин; төз. һәм соңгы сүз авт. Р.Миңнуллин; кереш сүз. авт. Н.Нәҗми. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 271 б.: фоторәс. б-н. — 1500 д. — ISBN 978-5-298-01573-8

Уфада яшәүче татар шагыйре Рим Идиятуллинның Казанда беренче тапкыр чыккан бу китабына аның иҗат кыйбласын гәүдәләндергән әсәрләре тупланды.

ISBN 978-5-298-01573-8

© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Миңнуллин Р.М., төзү, соңгы сүз, 2007
© Идиятуллин Р.З., 2007

Бу китабымны улым Илдарның
сүнмәс рухына багышлыйм.

Автор

**ТАНЫЛМАГАН ТАЛАНТ**

*яки «нейтраль зона»дагы иҗат хакында*

Шагыйрь Рим Идиятуллин 1983 елда чыккан «Хәерле иртә» дип аталган тәүге китабын миңа бүләк итеп биргәндә шундый юллар язган: «Барысы да соңлап килде миңа» дип, Сез бик дөрес әйткәнсез. Безнең бердәнбер уртаклык, бәлки, шулдыр». Монда уртаклык бармы икән соң әле: аңа барысы да соңлап та килмәскә итә түгелме соң?

Рим Идиятуллинны ниндидер яман рух эзәрли шикелле. Ул үзенең тәүге шигырьләре белән үк киләчәккә зур өмет баглады. Хәтеремдә, сәнгать институты залында, Язучылар союзы идарәсе рәисе буларак, шигырь кичәсен алып бардым. Шунда Марат Минһаҗетдиновтан (ул вакытта фәннәр кандидаты иде микән, юк микән, хәзер инде күптән мәрхүм) «Рим Идиятуллин ни өчен шагыйрьләр арасында утыра?» дигән язу килде. Ни өчен ул утырмаска тиеш иде соң әле?

Икенче бер хәл. Язучылар союзында шагыйрьнең өстә әйтеп киткән «Хәерле иртә» дигән китабының кулъязмасы тикшерелде. 1981 елның язында иде булса кирәк. Күп шагыйрьләргә бәһа бирергә өйрәнгән Муса Гали, шигырьләр китабының кулъязмасын тикшергәндә, халыкның бер мәкален искә төшереп: «Иртә уңмаган кич уңмас...» — диде. Бәһаләүче мәкальнең «Кич уңмаган һич уңмас» дигән соңгы өлешен әйтмәде. Шундый хөкем чыгарылганнан соң һәм мәкаләнең башын да «Танылмаган талант» дип куйгач, шагыйрьне яклавы җиңел түгел. Миңа монда Хәсән ага Туфан ярдәмгә килә. Рим Идиятуллинның олуг шагыйребез укыган кулъязмасын күргәнем бар иде. Мин аны әле Рим Идиятуллинның үзеннән сорап алдым. Олуг шагыйрьнең шигырьләргә карата: «Яхшы бу!», «Молодец!», «Гаҗәп егет (талант) ләбаса бу! Х.Туфан», — дип гадәттәгечә яшел карасы белән язып куюлары күп нәрсә турында сөйли. Бу китап хакында вакытында бер мәкалә чыгуын чыккан. Аннан соң 13 ел үткән. Мин дә, китапны укып чыккач, «бик үзенчә-

лекле шагыйрь» дип, аның соңгы битенә язып куюдан узмаганмын. Чынлап та, китапка бәһа бирү, гомумән, Рим Идиятулинның шигърияте хакында фикер йөртү миңа да соңлап килде.

Рим Идиятуллин үзе дә китабы шикелле юка тәнле, чандыр гәүдәле. Шулай булуга карамастан без аны йолкыштырудан баш тартмаганбыз. Берничә мисал китерим. Шагыйрьнең яхшы шигырьләре арасында тагы яхшы 12 юллык шигырь бар — менә ул:

Гомеремнең әле таңы гына,
Үрмә гөлдәй үскән чакларым.
Мин күрергә диеп туганмындыр
Бу дөньяның бөтен якларын.
Күп нәрсәне мин үземчә ясыйм
Үзем салып күңел-калыпка.
Кызыктырмый мине бабай Колумб,
Мин кызыгам туар Колумбка.
Күктә, диләр, кояш берәү генә,
Бу дөньяның, диләр, дүрт ягы.
Бишенче як нишләп булмасын ди,
Бардыр кояш, бардыр бер тагы!

Нинди тирән фәлсәфә! Шигърияtнең дә бит бөтен бурычы шул бишенче якны ачарга тырышу түгелмени?!

Минем «Кыңгыраулы дуга» дигән пьесамда бунтарь йөрәкле, дөньяда үз яшәешеннән канәгать булмаган Әхмәмәт исемле персонаж-егет бар. Пьесаның тәүге вариантында ул: «Мине тугыз авылда кыйнадылар, унынчы авылны эзлим», — дип йөри иде. Соңынан Ә.Атнабаев киңәше буенча, тугыз авылны дүрт авылга, ягъни дүрт тарафка әйләндереп, бишенче авылны бишенче тараф итеп алдым, соңыннан гына бишенче тараф Рим Идиятуллин шигырьләреннән икәнлеген белдем. Моның өчен шагыйрьдән гафу үтендем, ә Әхмәмәтнең «Яшәсен бишенче авыл!» дигән сүзен алып ташлау мөмкин түгел иде инде.

Минем «йолкуым» әз генә булса да үзгәртелгән, ә бит турыдан-туры йолкулар да юк түгел. Шагыйрь Муса Галинең көтмәгәндә, бервакыт гәзиттәме, журналдамы чыккан шәлкемендә «Үземә кайтып киләм» дигән шигырен укып шаккаттым: нинди һәйбәт шигырь! Күпмедер вакыт үткәч, Рим Идиятуллиның да шул ук исемдәге «Үземә кайтып барам» дигән шигырен укыгач, аптырап калдым. Туры килүме бу, әллә чәлдерүме? Әйтүе кыен, әмма Рим Идиятуллинның бу шигыре, белүемчә, күпкә иртә язылган. Менә ул шигырь:

Күз ачкысыз ыжгыр буран
Яуса да урап-урап,
Кереп киттем бер сукмактан,
Тормадым мин юл сорап.
Кая барып чыгармын дип
Шомланып уйлап куям;
Таныш җирләр түгеллеген
Табаным белән тоям.
Кайсыбызның юлларына
Җәеп куйганнар юрган?!
Адашса да, алда була
Бертуктамый юл ярган!
Мәңге котырмас җил-давыл,
Басылыр көн ачылгач;
Күңелгә күчкән бураннар,
Аһ, тиз генә басылмас!..
Кайда илтә хис сукмагым?
Кай тарафка юл ярам? —
Үземә дә сиздермичә,
Үземә кайтып барам...

Мондый шигырьләргә нинди дә булса «аңлатма» бирү кирәк түгел. Бу шигырьдә шагыйрьнең (димәк, лирик геройның) үтә катлаулы рухи һәм психологик торышы чагылдырылган, мондый ачыш шагыйрьләрнең бик тә санаулыларына тәти. Бу очракта да «талант» дигән төшенчә шагыйрьнең бөтен барлыгына табигый рәвештә килеп сеңә, ясалма рәвештә китереп тагылмый. Шигырь язганда шигырь исемнәре башкаларныкына туры килүе бик мөмкин, әмма Рим Идиятуллин шигыренең «Үземә кайтып барам» дигән исеме генә дә бер ачыш — аның бөтен тозы да шунда.

Алда әйтеләчәк фикеремне нигезләр өчен тагын бер мисал китерергә мәҗбүрмен. Рим Идиятуллинның «Өйрәтү» дигән шигыре бар. Кешене (лирик геройны) гомер буена өйрәтәләр, һәм шигырь «Беркем өйрәтмәде үләргә» дип тәмамлана. Әнгам Атнабаевның «Өйрәттеләр» дигән шигыре бар. Монда да кешене (лирик геройны) гомер буе өйрәтәләр, һәм шигырь «Сине яратырга качып-посып үзем өйрәндем» дип бетә.

Өстә китерелгән өч мисал (ә бу шигырьләр барсы да алда язылганнар, фикерләр алда әйтелгәннәр) Рим Идиятуллинның — «иртә уңмаган кич уңмас»ның талант дәрәҗәсе турында сөйли.

Нигә әле мин «йолку» мәсьәләсен озакка суздым? Сорау туа: тормышта кемнең хәерчене йолкып мантыганы бар? Үзеннән-үзе аңлашыла: Рим Идиятуллин шигърияте бай, һәм шагыйрь үзенең тирән фикерләү сәләте белән, шигърияттә иң төп аргумент саналган йөрәк януы белән, тирән һәм каршылыклы хисләре белән, шуларның барысын да укучыга җиткерү осталыгы белән үзе булып аерылып тора. Шуны моңа кадәр белмәү, аны игътибар үзәгеннән читтә калдыру безнең барыбызның да гафу итә алмаслык хатасы. Ул кайдан килә? Елгаларның да бит тирән, чоңгыл җирендә агым бер урында бөтерелүчән һәм Рим Идиятуллин да Башкортстандагы шигърият агышының тирән һәм чоңгыл җиренә туры килде. Аның иҗаты болай да тирән ага, билгеле булуынча, сай елгалар гына шаулы булалар, бу яклап Рим Идиятуллин да хаклы, — ул бер шигырендә болай ди:

Ә гәүһәрләр, асылташлар —
Тирән диңгез төбендә.

Талант та әнә шундый:
Күренергә, үзен күрсәтергә
Һич тә ашыкмый.
Үзе бер сәнгатьтер әле
Аны күрә белү, тану.
Миңа бер дә сәер түгел
Талантларны ача алган
Талантларга табыну.

Бу шигъри юлларында Рим Идиятуллин мең мәртәбә хаклы, әмма талантларны ача торган талантлар мәсьәләсенә килгәндә, урыс классик әдәбияты зур бер үрнәк (Пушкин, Лермонтов һәм Белинский), ә безнең көннәрдә андый сәнгать юк дәрәҗәсендә, талантларны ачуда (алар чын булсалар әле) сәнгатьтән бигрәк сәясәт өстенлек итә. Безнең талантларыбыздан сәнгатьчә булырлык дәрәҗәдә кем ачылган? Моңа җавап бирүе авыр. Ә Бабич? Ә Даут Юлтый? Ә... диярләр. Бәлки, шагыйрьне сәнгатьчә ачуы авырracтыр. Безнең тәнкыйтьчеләребезнең тәнкыйтьне ташлап, романнар яза башлаулары юкка түгелдер, ә шигърият хәзергә бәхетле, — тәнкыйтьчеләр шигырь яза башламадылар.

Тагын бер мәртәбә иманым камил: шагыйрьләр — тумыштан шагыйрь. Миңа көтмәгәндә (кайда басылганын оныткамын) бөекләрдән бөек, хәтта Пушкинга замечание ясаган («Его лошадка снег почуя, плетется рысью как-нибудь» дигәндә «как-нибудь» берни аңлатмаганны, ә «путь» сүзенә рифма өчен генә китерелгәнлеген әйтә) Лев Толстой язган шигырьне укырга туры килде. «Бу бит шигырь түгел, нигә язды икән?» дип уйлап куйдым.

Толстойларга да барып җиткәч, мәсьәләгә бик тирән кереп киттем һәм үземне укучы алдына талантны күрә белгән кеше сыйфатында китереп бастырдым шикелле. Күпме генә көчәнсәм дә, бу хәл минем кулымнан килми, мин бернинди кандидат та, доктор да, профессор да, академик та түгел, мин, бары тик шигырь язучы гына буларак, шигырьне, бәлки, тирәнрәк тоямдыр; ә асылда, тою бер нәрсә, ә ул тоюны сәнгать дәрәҗәсенә күтәрү икенче нәрсә.

Шигырьне тою мәсьләсенә килеп терәлгәч, шулай да Рим Идиятуллинның бер шигырен тоташ күчерим әле. Ул «Бер хатирә» дип атала.

Оныттым да бугай хәзер сине,
Үткәннәргә күңел күнекте;
Югалтып та һәм табып та
Буламы әллә синең кебекне?!

Беләм,
Син дә мине бик күптәннән
Кугансыңдыр күңел түреңнән;
Тик тамчы да гаеп тага алмыйм,
Таба алмыйм аны үземнән.
Таба алмыйм.
Тик уйлыймын кайчак:
Яратуым минем
　　үзем төсле

Булмадымы икән
холыксыз?
Бәлки, шуңадыр да
аны бүген менә
Хәтерләү дә хәтта
икенче кат
Күргән кино кебек
кызыксыз.

Күнегәдер күңел үткәннәргә,
Мин суындым сөю хисеннән;
Кайчан табыштык та
югалтыштык? —
Чыгардым да бугай исемнән.

Кинәт...
Еллар аръягында калган,
Мәңге кайтмас булган
хатирә,
Борылмадан чыккан поезддай,
Үкереп өскә килә...

Шигырьдә күпме контраст фикерләүләр, эчке әрнү, капма-каршылыклы тойгы һәм образлылык. Берәүләр бу шигъри юлларда әллә ни артык нәрсә дә күрмидер, ләкин мин монда Лермонтов рухын тоям, ә андый рухлы булу бөтен шагыйрьләргә дә тәтеми.

Әйе, тагын да бер хакыйкать бар — шагыйрь үз шигырьләрендә үз тормышын, үз холкын, үз кичерешләрен чагылдыра, әгәр дә шулай булмаса, шагыйрь үзе дә, шигырьләре дә гомум, бертөрле тәэсир көче булмаган рифмалы сүзләр генә булыр иде. Талантлы шагыйрьләр шигырендә аның үз рухи сурәте, үз тойгысы, язмышы гына да чагылуга карамастан, укучыларның тойгылары белән уртаклык табуы күптән билгеле хакыйкать.

Кайбер шагыйрьләр: без — егерме сигезенче елгылар, без — утыз тугызынчы елгылар, бигрәк тә, без — кырык беренче елгылар, дип, үз язмышларын туган еллары белән бәйлиләр. Ул елларда туучыларга мондый тойгылар үз кордашларына аваздаштыр да, ләкин минем кебек картларга, ул еллар минем күз алдымнан үткәнгә күрә, һич тәэсир итми. Мәсәлән, мин: «Без — унсигезенче елгылар», — дип язсам, Сәйфи ага Кудаш, Хәсән ага Туфан, Гомәр ага Бәширов кебекләрдә, ул заманны башыннан үткәргәннәрдә һичбер тойгы уятмас иде.

Рим Идиятуллин да сугыш елында туган бала, ләкин, мин фәлән елгы, дими, ә:

Мин бишектә чакта явыз фашист
Әтиемнең гомерен сүндергән.
Тел очымда торган сүземне дә
Ул үтергән, ул, у-у-ул үтергән, —

ди.

Тел очында торган сүз — «Әти» дигән сүз. Ә шигырьдә күпме тойгы: сүзне үтерү — ятим калу. «Чын шигырь» дигән төшенчә шул үзедер инде.

Әйе, «Хәерле иртә» китабы — шагыйрьнең тәүге һәм соңгы китабы. Китапның чыгуына унөч ел. Иҗатның — иҗатлылыгы, талантның талантлылыгы, әлбәттә, китап саннары белән билгеләнми. Әмма Рим Идиятуллин туңып калган шагыйрь түгел, Казанда һәм Уфада аның шигырьләре гәзит-журналларда әледән-әле чыгып тора. Алар барысы да мин искә алып киткән шигырьләр дәрәҗәсендәләр. Шулай да күп кенә дүртьюллыклар арасыннан берсен генә укучыларга тәкъдим итәм — ул «Президентның нотыгы» дип атала.

Ил дә — алтын, җир дә — алтын,
Рәсәй халкы эштә алдын;
Җиде диңгез артларыннан,
Алтын биреп, ашлык алдым.

Кызык хәл. Моннан күпмедер вакыт элек кенә Татарстанның халык шагыйре Гамил Афзалның шигырьләрен укыган идем. Шушы шигырьне шул шәлкемдә укыдым шикелле тоелды. Шунда ук Гамил Афзалның шигырьләрен табып алдым. Юк. Бу шигырь юк. Беренчедән, күптән укысам да, истә калган, икенчедән, шигырь остасы, зур Гамил Афзалны хәтерләтү Рим Идиятуллинның нинди шагыйрь булуын да күз алдына бастыра.

Бу мәкаләмне язуымның тагын икенче сәбәбе бар. Беренче сәбәбен мин төрле-төрле мисаллар нигезендә һәм үземнең тоюыма нигезләнеп (бәлки, бу нигезне кире кагучылар да булыр) исбат итәргә тырыштым. Беренче сәбәп белән икенче сәбәп бик тыгыз бәйләнгәннәр.

Рим Идиятуллин — Башкортстанда яшәүче татар шагыйре. Ул татар телендә яза. Без, ана телебез татар теле булган шагыйрьләр һәм язучылар, Сәйфи Кудаш, Гариф Гомәр, Мәлих Харис, Гайнан Әмири, Максуд Сөндекле, Тимер Арслан, Мостай Кәрим, Әнгам Атнабаев, Марат Кәримов, Динис Исламов, Габдулла Байбурин, Муса Гали, Нәҗип Асанбаев, Ибраһим Абдуллин, Әсгать Мирзаһитов, Кирәй Мәргән, Гыйлемдар Рамазанов, Рафаэль Сафин һәм мин фәкыйрегез башкорт телендә яздык. Шәхсән мин татар орфографиясен бөтенләй белмәүгә барып җиткән идем, татар язучылары белән хат алыша башлавым да башта башкорт телендә барды. Ә менә Фәрит Габдерәхим, Рим Идиятуллин, Халисә Мөдәррисова, Рәшит Гатауллин, Нәҗибә Әминева кебекләр башкорт телендә язмадылар, алар үз китапларын башкорт теленә тәрҗемә итеп чыгарырга мәҗбүр булдылар. Бу шагыйрьләргә Башкортстанда татар дип карадылар, ә Татарстан исә аларга артык игътибар итмәде.

Сиксәненче еллар башында татар мәктәпләре белән бергә бөтен районнарны башкортлаштыру башлангач, татар телендә язучыларга караш читенләшә төште. Үз нәүбәтендә татар теллеләр дә таякны артык бөгеп куйдылар. Шушы капма-каршылык Габдерәхимов, Идиятуллин, Мөдәррисова кебекләр өстенә битарафлык болыты булып калыкты һәм алар «нейтральный зона»да калдылар. Мәсәлән, сугыш яланындагы алгы чиктә нейтральный зонада калу куркыныч, каршы торучыларның кайсысы булса да аңа һөҗүм итә. Әдәбият яланындагы нейтраль зонада калу ул ике ут арасында яшәү дигән сүз. Рим Идиятуллинның бервакыт: «Без тегендә дә юк, монда да юк», — дигән әрнүле сүзе йөрәккә сеңеп калган. Ә тегендә дә, монда да бар итәр өчен нишләргә кирәк соң? Дөрес, аларны «бар» итәр өчен Татарстан Язучылар союзы Рим Идиятуллинны, Халисә Мөдәррисованы, Рәшит Гатауллинны үз сафларына әгъза итеп алды, әмма ләкин алар һаман «нейтраль зона»да, ике ут арасында калуларын дәвам итәләр. Бу хәл вакытында зур шау-шу куптарган «Туган җирнең үги баласы» дигән төшенчәне искә төшерә. Үги бала сыйфатында яшәмәү өчен нишләргә кирәк соң? Башка үзеннән-үзе шундый фикер килә: бездә, бюрократлык хөкем сөргән илдә, бюрократ аппарат, оештыручы аппарат мотлак кирәктер. Ул аппаратның булдырылу мәсьәләсе Язучылар союзы тарафыннан гына түгел, ә югары даирәләрдә хәл ителергә тиештер, чөнки бу очракта Башкортстан Язучылар союзы да, аның татар секциясе дә көчсез.

Дөрес, татар секциясен Башкортстан Язучылар берлегенең татар әдипләре иҗади берләшмәсе дип (исемен дә табалар бит! Берлек эчендә берләшмә...) исемләделәр, Башкортстан «Китап» нәшриятында татар телендә китаплар чыга башлады. Нәҗибә Әминева (ул да танылмаган талант) кебекләрне Союзга әгъза итеп алдылар (алдылар да, ул менә дигән талантлы шигырьләр яза башлаган елларда туган, укытучы буларак, аларны укытып чыгарган кеше, хәзер инде Союзда әгъза булып, танылган шагыйрьләр рәтендә, яшь шагыйрә исемен «яулап» алды). Әмма бу чаралар гына үги балалыктан, ике ут арасында яшәүдән коткара алмый.

Язучының тормышы, эше, язмышы китап чыгарудан гына, Союзда әгъза булудан гына тормый. Аның санап бетергесез серле һәм милли үзенчәлекле үзара бәйләнешләре бар.

Моннан ярты гасыр элек, безнең буын әдәбиятка килгән елларда, татар һәм башкорт арасында бары тик туганлык хисе хөкем сөрә иде. Элекке милли туганлык хәзер дуслык (халыклар дуслыгы — әдәбиятлар дуслыгы) «югарылыгына» күтәрелде. Мәсьәлә бүгенге көндәгечә барса, дәвам итсә, безнең дуслык «үсә-үсә» әллә нәрсәләргә әйләнүе мөмкин.

Әдәбият бар булмышы, тамыры белән милләткә бәйле. Ике арада калган дуслыкны саклап калу өчен, ничек кенә булмасын, Башкортстандагы татар телле язучыларның аерым оешмасы кирәктер. Ул оешма Башкортстан һәм Татарстан Язучылары союзына караган, ул «бүлек» дипме йә башкача аталырмы, әмма тормыш шундый бер оешма булуын таләп итә һәм оешманың башында талантлы, акыллы, эшлеклелек сыйфаты белән зур авторитет казанган кеше (Татарстан язучыларының Әлмәт бүлегенең тәүге җитәкчеләрен — Ахуновны, Фәйзуллинны һ.б. күз алдына китерегез) булырга тиеш. Шундый оешма булмаганда, Башкортстандагы татар телле язучыларның ике ут арасында калулары дәвам ителәчәк.

*Нажар Нәҗми,*
Башкортстанның халык шагыйре
*15 ноябрь, 1996*

# ШИГЫРЬЛӘР

*Үз йолдызымны тапмыйча,*
***Күкләрдән күзем алмам...***

## *ШУЛ БЕР ГОМЕР ЭЧЕНДӘ*

*Килер буын сүз кузгата калса*
*Мин яшәгән дәвер хакында,*
*Белегез сез, кайгы күлен кичеп,*
*Күрсәтмәдем зарның затын да, —*
*Шул бер гомер эчендә.*

*Атсагыз да, ассагыз да риза,*
*Мин гөнаһлы Вакыт каршында:*
*Җаһил булып тумасам да җиргә,*
*Җиттем җиде патша башына, —*
*Шул бер гомер эчендә.*

*Кояшларың сүнсә, хәсрәтләрең*
*Сүрәнәйми икән кичен дә:*
*Мин яшәдем яуда янган әткәм,*
*Суга баткан улым өчен дә, —*
*Шул бер гомер эчендә.*

*Шул бер гомер эчендә, —*
*Тәүдә — дәһри, соңра диндар итте,*
*Кертте заман төрле сурәткә,*
*Фанилыкта тәмуг утын татып,*
*Юл яралмый калдым җәннәткә.*

*Әрвахларым, һәммә җирдәшләрем!*
*Дәшеп сезне, кордым шау табын;*
*Рухыгызга атап яздым менә*
*Ач гасырның ачы китабын, —*
*Шул бер гомер эчендә.*

*1999*

**ҮЗ ЙОЛДЫЗЫМ**

Кайларга илтер юлларым,
Каян беләсең алдан?
...Үз йолдызымны тапмыйча,
Күкләрдән күзем алмам.

Күз яздырмый күзлим күкне,
Күзләрем яшькә тулып;
Атылды берсе арадан,
Шигырь юлларым булып.

*1961*

* * *

Без балага бигрәк аз кирәккән,
Белмәгәнбез бит күпне.
Ат көткәндә, төне буе

Күзәтә идек күкне.

Без — азга да риза балакайлар,
Күктән күпне көтә башладык,
Ипине без, майга ниткән кебек,
Йолдызларга манып ашадык.

Хыялларда инде әллә кайчан
Айкап йөри идек күк йөзен.
Зөһрәсенә күкнең ул чакларда
Гашыйк малай идем мин үзем.

Ул хыяллар хыялмыни инде?!
Хыялларны җилеп уздылар:
Малайларны бүген кызыктыра
Җирдән күренмәгән йолдызлар.

*1968*

*** * ***

Малай чакта
Һәрвакытта
Югарыга үрмәләдек.
Тау башына менеп баскач,
Күзне йомып,
Куллар белән
Йолдызларны сәрмәләдек.
Кулга килеп капканнарын
Җиргә аттык,
Кабат күккә күчмәсен дип
Каплап яттык,
Күктә күпме калган диеп
Санап яттык.
Йоклап киттек...
Ә уянсак —
Берни дә юк:
Җирдә дә юк,
Күктә дә юк.
Әнә кояш!
Кояш булгач,
Үпкә дә юк.
Йолдызларның
Барчасы да
Кояш булып
Укмашкан бит.
Безнеке дә
Шул кояшка
Тоташкан бит...

Шуны уйлап
Барыбыз да
Куаныштык.
Кичен кояш
Җиргә бәрелеп
Ватылгачтын,
Бик күп, бик күп
Йолдыз булып
Атылгачтын,
Тотарбыз диеп
Таралыштык...

...Малайларны
Нидән икән
Гел йолдызлар кызыктырган?
Дөньясы да
Шул ыштансыз малайларның
Баш китәрлек ачышына,
Белмим, ничек түзеп торган?!

*1961*

* * *

Тирән карда «окоп» казып,
«Кызыллар» һәм «аклар»
Уйный идек.
Әгәр «аклар» бик тиз җиңелмәсә,
«Кызыллар»дан кыюыбыз,
«Мешать итмәсен», — дип,
Танавын бишмәт җиңенә
Сөртә иде дә,
Шуышып барып,
«Аклар» окобын
Җимереп «үлә» иде.

...Авылдан бик еракта
Фашист белән алышкан
Әткәйләр бу вакытта
Үлемсезлеккә шуышкан...

*1969*

* * *

Безнең авылны
Күреп ярата алмаса да,
Никтер бик еш урый иде
Сукыр музыкант.
Йорт күләгәсендәге
Ташка утырып,
Скрипкасын —
Иң-иң нечкә кылын,—

Йөрәк өзгеч моңлы көен
Тарта иде.

Малайлар бик сак,
Үрелеп кенә,
Музыкантның йомык күзләреннән
Чебен куа;
Әнкәйләр,
Җиргә текәлгән килеш,
Яулык читен уа...

*1966*

*** * ***

Сугыш бетте;
Ә малайлар һаман,
Матчадагы талчыбыкка карап,
«Усал» әтиләрен көтте.

*1966*

*** * ***

Гомеремнең әле таңы гына,
Үрмә гөлдәй үскән чакларым.
Мин күрергә диеп туганмындыр
Бу дөньяның бөтен якларын.

Күп нәрсәне мин үземчә ясыйм
Үзем салып күңел-калыпка.
Кызыктырмый мине бабай Колумб,
Мин кызыгам туар Колумбка.

Күктә, диләр, кояш берәү генә,
Бу дөньяның, диләр, дүрт ягы.
Бишенче як нишләп булмасын ди,
Бардыр кояш, бардыр бер тагы!

*1966*

**СУКЫР**

Җир тәненә
Суга да ул
Таягы белән,
«Авырттымы?» дигән кебек
Сыйпап уза
Табаны белән.

*1966*

**КАРЫШУ**

Кар төшә җиргә
Теләр-теләмәс,
Әллә беткәнме Җирнең
Тарту көче? —
Җиргә төшеп
Тапталмас борын
Бу һәр бөртекнең
Карышу көче.

*1966*

**ЕЛЛАР ҮТКӘЧ, ТУГАН ҖИРГӘ КАЙТКАЧ**

Элек
Көннәр харап эссе була,
Арба астында телен чыгарып,
Эт әлсерәп ята торган иде;

Элек
Тарзан күле
Таба зурлык табан балыклы,
Буй җиткесез тирән,
Йөзеп чыгалмаслык киң иде;

Элек
Бу тирәкләр күккә ашкан,
Күләгәсе, киң урамны аша чыгып,
Безнең болдырга ук башын сала иде;

Элек
Ындыр артындагы кичке уенда,
Итек кунычын каз мае белән ялтыратып,
Гармун күреге ясаган малай-шалай
Җир-күк тетрәтеп бии иде;

...Ни әйтим бүген килеп?
Шул «элек»ләр искә төшсә,
Үтә йөрәкне телеп.

*1967*

**ТӘМАМЛАНМАГАН ШИГЫРЬ**

Китәләр миннән әйберләр:
Ат итеп йөрткән талчыбыгым,
«Үгез тышаулар малай» дигәч тә,

Ник ашыгып сындырдым?

Әнкәмнең «кала бүләге» дип
Сөендергән каешын
Тузгач кемгә бирдем соң?

Әткәм истәлеге булган
Кесә сәгатен
Ике телем икмәккә
Алыштырдым мин — исәр.

Тәүге мәхәббәтемнең
Чигүле кулъяулыгын
(Ят күзләр күрмәсен дип)
Кайларга яшердем соң?

Елый-елый язылган
Иң беренче шигырем
(Учакта ут алынсын дип)
Яндырылдымыни соң?

Яратылган-янылганның
«Гомерлеккә» дигән фотосы
(Өйләнгәннең тәү кичендә)
Ертылган дамыни соң?

...............
Хәтереңә шайтан төкергән,
Тартыргамны кая тыктым соң?..

*1966*

**ЧАКЫР ӘЛЕ!**

Чакыр әле мине, туган җирем!
Охшасам да мин бер качакка,
Җылы тыным бөркеп китәсем бар
Юл читенә баскан башакка.

Чакыр әле мине, тәүге ярым!
Барган чакта кояш авышып,
Аңлашасы килә: «Ник сөйгәннәр
Яши алмый икән кавышып?»

Чакыр әле мине, газиз Әнкәм!
Әҗәлеңне күтеп алганда,
Соң мәртәбә баккан күзләреңнең
Нуры калса иде улыңда.

*1981*

**ТУГАН ЯКТА**

Пыскып яна күктә сукыр йолдыз;
Бу дөньяда минем барлыкны
Белми дә ул. Тын йокыда авыл.
Өрә-өрә эт тә карлыкты.

Күп иде бит күктә йолдыз элек,
Буш милектәй ул да таланган...
...Сагынмыймын сине хәзер, авыл,
Сагынып кешем инде калмаган.

Бәндәләрне гомер азагында
Туган туфрак тарта, имеш тә...
...Ятим йолдызымны явыз көчек
Кабат өркетергә керешсә,
Нишләрмен мин?!

*1989*

**КИТКӘННӘРГӘ ҮПКӘ БЕЛДЕРМӘГЕЗ**

*Якташларыма*

Исәнмесез әле, якташларым!
Исәнмесез, якын дусларым!
Күрешергә насыйп булган икән,—
Кычып тора иде учларым.

Хәлләрегез ничек? Бер көеме?!
Шөкер әле, мин дә бер көе;
Кайларда да тормышларны кормыш
Җиңел түгел икән шул, ие!

Зарлана дип уйламагыз берүк,
Зарланырга һич юк исәбем;
Туган якка аяк басу белән
Искә төшә кинәт кичәгем.

Озатканда әйткән иде Әнкәй:
«Ипекәйгә туен, хуш, балам!»
Истән чыкмый аның фатихасы,—
Җылы ипи булса, хушланам.

Киткәннәргә үпкә белдермәгез,
Мин үзем дә шул ук нәселдән;
И туган як! Татлы төш кебек син,
Мәңге чыкмас уем-исемнән.

Аһ, китүләр авыр, киткәннәргә

Язмыш түгел, нужа баш булды.
Саный китсәң, Чакмагышның чая
Татарлары белән ил тулды.

Кая гына барып сыенса да,
Сынатмады алар, сынатмас!
Ат башыдай алтын тапсалар да,
Туган җирен гомер онытмас.

Сайрар талын юксынган кош кебек
Очып кайтыр алар, дәшсәгез.
Кайтканнардан теләк тик бер генә:
Иман белән, имин яшәгез!

*1990*

**БИК САГЫНДЫМ, ДУСЛАРЫМ!**

*(Ташкент истәлеге)*

Кайда да бер кояш, дидем,—
Киттем ялгыз башларым;
Калдырдым шул туган якның
Айларын, кояшларын.

Һич сагынмас кебек идем,
Бик сагындым, дусларым!

Талпынышыннан таныймын
Туган якның кошларын;
Яз җиткәнен көтмәс идем,
Кайтыр идем кышларын.

Һич сагынмас кебек идем,
Бик сагындым, дусларым!

Хәлләремне сорамагыз,
Була төрле чакларым;
Коштай очып барып җитсен
Сезгә сәлам хатларым.

Һич сагынмас кебек идем,
Их, сагындым, дусларым!

*1986*

**ҖИРӘН БИЯ ВАФАТЫНА**

Шыксыз көздә туган авылымда
Җирләгәннәр Җирән бияне;

Аһ итәрлек кайгы булмаса да,
Күңелемне сагыш биләде.

Дучар булган икән
мал затына
Сирәк төшә торган язмышка:
Бугазына пычак эләкмәгән,
Ауган малкай тартып барышка.

...Хәтерлимен,
Хәтерлимен аның елгыр чагын:
Торышында күпме горурлык! —
Һични өстәмичә,
гүзәлеккә
Тере һәйкәл булып торырлык!

Гүзәллеге бер хәл,
карашларын
Шундый мәгънә белән тутырыр, —
Үзен акыллы дип исәпләгән
Кайбер бәндәләрдән уздырыр.

И изге җан!
Юлсыз җирләрдә дә
Юлдан язмас, юлдан яздырмас,
Сыртын каезлаган кансызны да
Ярты юлда ташлап калдырмас.

(Берчак,
кыйнап туйгач,
чанасына
Чалкан төшкән сәрхуш Шәйхине
Кышкы төннең ыжгыр буранында
Алып кайткан иде сау көе...)

Күпме төясәң дә тартты,
мәхлук,
Тубыкланып тартты,
көч тапты.
(...Дүрт аяклы ат та абына, дип,
Булдыксызлар нахак ат такты...)

Ат-аргамак!
Гасыр-дәверләрдә
Булды ирнең тугры юлдашы;
Ятып калса яуда күпме егет,—
Шулкадәрле калды ат башы...

Алышларга җилгәннәрдән
кемнәр
Каһарманлык сезгә ят дисен?!
Их!
Һәйкәлләр сезгә коелмаган,
Уелмаган ташка бер исем!..

...Нәселеңне беләм, беләм,
Җирән биям! —
Көн буена йөреп сабанда,
Тирен катырып та өлгермичә,
Яу чапты бит синең бабаң да.

Ияреңдә җырлап китте ирләр,
Кайтып кермәбез дип җиңүсез;
Антларына тугры әтиләрдәй
Ятып калды алар
билгесез...
Ни могҗиза! —
Җирдә җан иясен
Нинди генә төргә син бүлмә,—
Ил-ояга дошман ут үрләтсә,
Бөҗәге дә барыр үлемгә!

Тереклекне, имин яшәешне
Туры килер чакта якларга,
Дөнья һәрчак күзен терәп багар
Асыл ирләр, асыл затларга!..

Аягүрә үлгән Җирәнкәем
Күз терәрлек асыл зат иде;
Бу сагышым минем юкка
түгел,—
Авылда ул соңгы ат иде.

Җирән биям!
Акыл-аңны җигеп
Җиһаннарга җилгән заманда
Нигә әле синең тере сының
Күз алдымда тора һаман да?

Вафатыңа күңел күнмәсә дә,
Еллар үткәч, хисем сүрелер;
Тик авылым гына,
атсыз калгач,
Котсыз калган кебек күренер...

*1974*

**Ә МИН КАЛАМ**

Җилкәннәрне ефәк җил күтәрде,
Тын ярларны инде калдырам...

*Рәдиф Гаташ*

Палубадан берәү кул изәде —
Берәү китә ерак сәфәргә.
Яшем тыеп, аңа ак юл телим,
Мин каламын монда яшәргә...

...Туктат әле, күңел, талпынуың:
Киткәннәрне күрсәң, талыйсың;
Исәннәрне ташлап киттең дә ди,
Үлгәннәрне ничек ташлыйсың?!

Ата-бабадан ук кендегебез
Туган җиргә ләса береккән,
Ышанмасаң менә,—
              җир тамчысы! —
Маңгай миңем белән ант итәм.

Китә алмам туган җирем ташлап,
Китә алмыйм кайтмас сәфәргә;
Һәм исәннәр, һәм үлгәннәр белән
Язган миңа монда яшәргә.

*1969*

*** * ***

*Шагыйрь халкы гомер бакый*
*Гүзәллеккә тәрәз шакый.*

**ӨЙРӘТҮ**

Кешеләрне гомер буе өйрәтәләр;
Туа кеше:
«Йом күзеңне, йокла, балам!» —
Тирбәтәләр.
Кешеләрне гомер буе өйрәтәләр;
Үлә кеше:
«Ач күзеңне, йомма, балам!»—
Тилмертәләр.
Күзең ачсаң — йомдыралар,
Күзең йомсаң — ачтыралар,—
Кешеләрне бик тә харап шаштыралар.
...Менә мине
Инде күпме өйрәттеләр:
Вакытында йокларга да,
Вакытында ашарга да,
Вакытында эчәргә дә,

Вакытында сөяргә дә,
Акыл белән яшәргә дә
Өйрәттеләр.
Шулай яшәп,
Тәки адәм булдым дигәндә:
— Йөрәгең таш икән... —
Диде миңа иркәм;
Егыл да үл шушы сүзләргә!
Әйтү генә җиңел,
Ничек үләсең ди, —
Беркем өйрәтмәде үләргә.

*1965*

* * *

Күзем ачкач —
якты яраттым;
Тәпи баскач —
җирне яраттым;
Төсләр күргәч —
акны яраттым;
Кызлар күргәч —
сине яраттым.
Җир дигәнем —
ташлы да икән;
Ак дигәнем —
таплы да икән;
Яктыны төн
каплый да икән;
Тик мәхәббәт, тик мәхәббәт —
Ташны көл итүче,
Төнне көн итүче
Шифалы бер
тамчы ла икән!

*1964*

* * *

*Наиләгә*

Төн белән көн кавышканын
Карыйк әле —
Ничек икән?
Әйдә йолдыз саный торыйк —
Ничә икән?
Әнә берсе күз кыса ич —
Кемгә икән?
Кинәт күктән атылды ул —
Нигә икән?
Күп карасаң, күз тия, ди —

Тия икән.
Йолдызларны керфек каплый —
Нигә икән?
Мин санадым:
Күктә йолдыз икәү генә.
Синең ничә?
...Төн белән көн кавыштылар —
Әллә бүген, әллә кичә.

*1966*

**ҮТКӘН ҖӘЙ ИСТӘЛЕГЕ**

Күгәрченнәргә җим ыргытасың,
Күгәрченнәр ташлана җимгә.
Җитен кебек җитез чәчләрең
Җиңел генә тарала җилгә.
(Мин карамыйм сиңа, мин карыйм җиргә.)

Күгәрченнәр тагын җим сорыйлар.
Күгәрченнәр ни,
өйрәнгән күпкә.
Иелгәндә күкрәгеңне күреп,
Кояш болытка чумды —
белдерә үпкә.
(Мин карамыйм сиңа, мин карыйм күккә.)

Күгәрченнәр очып киттеләр,
Озатып күзләр талды.
Күгәрченнәр күктә;
Инде дөнья
Башка бер ямь,
Башка төс алды.
Киттең...
Ә артыңнан
Ике күз багып калды.

*1973*

* * *

Ялганчы ул — «яратам» дип
Сөрән салса көн дә:
Татлы җимеш күп татысаң,
Тәмне тоймый тел дә.

*1969*

**БЕР ХАТИРӘ**

Оныттым да бугай хәзер сине,

Үткәннәргә күңел күнекте;
Югалтып та һәм табып та
Буламы әллә синең кебекне?!

Беләм,
Син дә мине бик күптәннән
Кугансыңдыр күңел түреңнән;
Тик тамчы да гаеп тага алмыйм,
Таба алмыйм аны үземнән.
Таба алмыйм.
Тик уйлыймын кайчак:
Яратуым минем
үзем төсле
Булмадымы икән
холыксыз?
Бәлки, шуңадыр да
аны бүген менә
Хәтерләү дә хәтта
икенче кат
Күргән кино кебек
кызыксыз.
Күнегәдер күңел үткәннәргә,
Мин суындым сөю хисеннән;
Кайчан табыштык та
югалтыштык? —
Чыгардым да бугай исемнән.

Кинәт...
Еллар аръягында калган,
Мәңге кайтмас булган
хатирә,
Борылмадан чыккан поезддай,
Үкереп өскә килә...

*1972*

**КӨНЛӘШҮ**

Көнләшәмен:
Бәхетленең бәхетенә,
Чибәр кызның егетенә.
(Хыялымда аны үзем белән алмаштырам,
Әгәр ул кыз мине кире какса,
Яратмаса, —
Карурманга илтеп адаштырам,
Син кайда, дип, яратам, дип,
Ялынганчы, елатканчы өнсез торам.)

Көнләшәмен:

Эре адымлы кешеләргә,
Матур шигырь яза алган шагыйрьләргә,
Дошманымның туры сүзлегенә,
Якын дусның мәхәббәтенә,
Хәтта
Мин күзледән күпне күргән сукырга да,
Мин исәннән күбрәк йөргән чатанга да,
Шау-гөр килеп сөйләшкәндә
Башын иеп тынып калганнарга,
Бәндәләргә көч өстәүче ялганнарга,
Миннән элек яшәгәннәргә,
Миннән соң да яшәүчеләргә
Мин көнләшеп яшим һәрвакытта.

Кайчагында гаепсезгә каккан-суккан,
Бер гөнаһың булмаса да төртеп еккан,
Тик барыбер кызыктырып үзенә тарткан
Бу дөньяда
Көнләшмичә ничек яшәрсең?

*1967*

**MEMENTO MORI!***

*Неапольдәге дустым Зиләгә*

Сөйгән ярлар чиккән кулъяулык ич
Туган җирнең шадра ак кары;
Шадраларын үбеп гел кабатла:
Memento mori! Memento mori!

Гомер язы — кыңгыравын кояр
Умырзаямыни нибары?!
Зәңгәр битен үбеп гел кабатла:
Memento mori! Memento mori!

Әнкәйләрнең назлы карашыдай
Күзгә сеңеп кала җәй нуры;
Син аларның каберләрен ура:
Memento mori! Memento mori!

Бу көзләрнең йөзләренә кемнәр
Сагыш йөгерткән соң?— сап-сары;
Соңгы дуслар белән җылы күреш:
Memento mori! Memento mori!

...Уян, чал Везувий! Син уянсаң,
Күңелләрдә күкрәү өзелми;
Инде безгә хушлашсак та ярый:

Memento mori! Memento mori!

**ЭЛЕГИЯ**

Серсез яшәү — төнсез яшәү кебек,
Серсез яшәү — синсез яшәү ул.
Бәхет кошын кулларыңда тотып,
Алтын тауларына менеп утыр,
Яшәвеңнән канәгатьлек хисен
Күңелеңә мөлдерәмә тутыр,—
Кайчан булса да бер
Онытылган кемдер,
Үткәнеңнән килеп дәшә ул.
Дәшәр ул!

...Берчак кичен,
Җыеп ул-кызларың,
Таһир илә Зөһрә кыйссасын
Укыганда, күңел кылларың
Шартлап өзелер кебек,—
Түзәсең!
Тып-тын яткан хисләр
Шаулап түгелер кебек, —
Түзәсең!
...Нинди бәхет! —
Төнең үзеңнеке,—
Яшьләреңне төнен түгәсең...

**КЫЗЛАР КӨЛӘ**

Кызлар көлә...
Кыш та көлә, җәй дә көлә,
Яз да көлә, көз дә көлә;
Урамда ни, урманда ни,
Яңгырда ни, буранда ни
Нәрсәдәндер кызык табып
Кызлар көлә.
Җәен —
Су кергәндә су чәчрәтсәң,
Язын —
Кар йомарлап, кар ыргытсаң,
Кышын —
Юл бирим дип, көрткә чумсаң,
Көзен —
Нинди кызык табалардыр,
Шайтан белсен!

Урманда ни —

Бүләгем дип чәчкә тоттырсаң,
Яңгырда ни —
Очрашырга сүз куешып,
Бик чак кына көттерсәң,
Буранда ни —
Чәчләренә кар кунгачтын
Тының белән эретсәң,
Урамда ни, урамда ни —
Ялгыш кына каш сикертсәң,
Кызлар көлә.

Кайгы килми, шатлык килми?
Юк, юк, килә. —
Кайгыдан да, шатлыктан да
Кызык табып, шашып көлә:
Шатланганда —
Чәче көлә,
Кайгырганда —
Яше көлә.

...Урамнарга шатлык чәчеп,
Кызлар килә.
(Ирексездән елмаясың.)
— Исәнмесез!
Кызлар көлә-ә-ә...

*1966*

* * *

Хуш бул! Хуш бул!
Каралары булды,
Акларын да ләкин онытма.
Кара күлмәк кигән малай итеп
Гомерлеккә саклап йөретмә.

Хуш бул! Хуш бул!
Күз яшьләрен көтмә, көтмә:
Ирләр халкы артык тәкәббер.
Бер минутка гына китмә, китмә! —
Караш кына ташлыйм тагын бер.
Хуш бул!
Хуш бул!

**БЕЛЕП ТОР!**

*(Энекәшкә шаян киңәш)*

Син белеп тор, сине ялантәпи

Утлы күз өстендә биетер,
Бер тамчысы ялгыш тама калса,
Котыпның бар бозын эретер,—
Хатын-кызның кайнар күз яше.

Син сынап тор, агу сораганда,
Дару салыр бәллүр савытка,
Гөнаһың юк килеш оҗмахыңны
Әйләндерер утлы тәмугка,—
Хатын-кызның зәһәр күз яше.

Син белеп тор, сыек муеныңа
Камытның иң зурын кидерер,
Әгәр шайтан ияләшкән булса,
Шайтанына башың идерер,—
Хатын-кызның төче күз яше.

Син әзер тор, имеш-мимеш хәбәр
Колагыңа кунса кайдандыр,
Бөртек «юк»ны тулы бер йөк «бар»га
Алыштырып алып кайтартыр,—
Хатын-кызның ялган күз яше.

Син түзеп тор, кала күрмә көнгә
Үзең теләп Себер китәрлек,
Өмет итмә, көн-төн түгелсә дә,
Түгел һич тә агып бетәрлек, —
Хатын-кызның дәрья күз яше.

*1994*

## ИСЕМЕМӘ КАРАТА БЕР ШАЯРУ

Кичә үлсәм, бүген белмәс идем:
«Римнәр көне» дә бар икән.

*Шул кичәдә укылган шигырь*

Бөтен юллар Римгә илтә, диеп
Әйтмәгәндер юкка борынгылар:
Яшәгән, ди, анда акыллылар һәм...
Минем кебек озын борынлылар.

Гөрләп торган Рим-дәүләттән бүген
Калган бары тузан-хәрабәләр;
Рим атлылар шул тузаннан туган,
Ә башкалар бар да сәләмәләр.

Яшәдек без тап төшермәс өчен
«Римнәр» дигән горур исемнәргә, —

Каберләрен белдек киткәннәрнең,
Гел изгелек кылдык исәннәргә.

Гашыйк булдык үлеп гомер-гомер
Клеопатра кебек гүзәлләргә;
Без картайгач кызлар чибәрләнде,
Ярдәмең бир, Ходай, түзәрләргә!

Юк, йөрәктә көл дә күмер диеп
Ялгышмасын кызлар берүк кенә:
Мәхәббәттә зина кылу гаеп түгел,
Кыла калсаң әгәр белеп кенә.

Яше узган, үзе тузган, диеп
Сөйләмәгез, зинһар, юк хәбәрләр,
Берне генәме соң, бөтен мирне
Сокландыра бөек хәрабәләр.

Кызыгы һич бетмәс бу дөньяның —
Рим атлылар аман яшәсәләр;
Римнәр көне узган мәҗлесләрдә
Тәгәрәшеп ятсын буш шешәләр...

*2001*

**ЭЛЕГИЯ**

Сары яфрак — сары тупсада;
Ничек кенә атлап үтәргә?
Йөзе кояш, сары чәчле кыз:
«Әни кайта хәзер, кушты көтәргә».

Кайсы чатта кала адашып
Кавышырга тиеш юлыбыз?
Картая көз, өй дә салкынча:
«Һаман тәмле икән чишмә суыгыз...»

Көзнең көне кәрлә әйтерсең...
«Әниемә кем дип әйтермен?»
«Әйт, сылуым! Гафу үтенәм,
Еш елата идем тартып чәченнән...»

*2003*

**ҮТКӘННӘН УЗЫП БАРЫШ**

Чык төшкән уйсу болын,
Уйнаклап чаба колын;

Үләннәрдән тама әллә
«Яратам!» дигән тавыш?

Һич исемә төшералмыйм:
Бу болын каян таныш?

Иренеп ага инеш,
Үзәне — соры камыш;
Кыяклардан коеламы
«И көттем!» дигән тавыш?

Исләремә төшми тора:
Бу инеш каян таныш?

Авыл башында — капка,
Уртасында — зур алка;
Ачынып чыга ачканда
«Оныттың!» дигән тавыш.

Исләремә төшми һаман:
Бу капка каян таныш?

Өй каршында өч усак,
Тилмерә дымга сусап;
Яфрак булып коеламы
«Саргайттың!» дигән тавыш?

Ник исемә төшми әле? —
Усаклар бит бик таныш.

Яшиләр икән кемнәр? —
Тәрәзе саен гөлләр.
Шул гөлләрдән сибеләме
«Соңладың!» дигән тавыш?

Ник исемә төшмәгән соң? —
Бу йорт бит миңа таныш.

...Юлаучыга күз ташлап,
Буй җиткергән кыз бала
Тетрәткеч хәбәр сала:
— Әнкәем күптән вафат.

...Хушлашып китеп барыш.
Озата сынык тавыш:
— Борылып кергәч юлдан...
Тәүге кабер... уң кулдан.

...Сөелгәннең баш очында
Бер бөртек шиңгән чәчкә...
...Бу болын, инеш, усаклар
Ник, нигә төште искә?!

...Юк шылт та иткән тавыш;
...Көзге көн кичкә авыш.

*1978*

**КӨЗЛӘРГӘ ДӘ КЕРДЕК**

*Даниягә*

Көз дә җитте менә,
ява сагыш
Берчә яңгыр, берчә кар булып;
Кавышканга күпме гомер үткән
Бер-беребезне сөяр яр булып.

И дөньялар диген...
Кичә генә
Яшел үлән кебек яшь идек,
Көләч язның кабат кайтмасына
Бүген генә килеп төшендек.

Төрле төсләр анда, узганнарны
Хәтер көзгесенә күчерсәң;
Татлы яшьләр куна күзләремә,
Яктыларын искә төшерсәм.

Карасы да күптер, кемнәр белсен
Үз юлларын үзе кисәсен;
Юаныч бар: кыркалар бит сабак,
Саклап калыр өчен кәүсәсен.

Мин бәхетле иттем сине дисәм,
Санарлар дип куркам исәргә,
Шатлыгын да мәгәр, газабын да
Язды, шөкер, бергә кичәргә.

Гел турыдан ярдым, бу юлы да
Чынын әйтсәм, калма гаҗәпкә:
Минем белән яшәү җиңел түгел,
Җиңел булмас минсез яшәп тә.

...Көзләргә дә кердек,
коя сагыш

Берчә яңгыр, берчә кар булып;
Их, яшәсәк иде, җаным, гүргә
Кергәнчегә кадәр пар булып.

*1990*

* * *

«Гөнаһсыз фәрештә түгелсең...» —
Дип, йөрәкне өзгәләмәгез;
Мин кечкенә кояш (кичке),
Нурларым да сүрән төште;
Якыннарым, үпкәләмәгез!

«Мәхәббәттә Мәҗнүн түгелсең...» —
Дип, бәгырьне кискәләмәгез;
Шагыйрь халкы гомер бакый
Гүзәллеккә тәрәз шакый;
Сөйгәннәрем, үпкәләмәгез!

«Дөньяда мәңгелек түгелсең...» —
Дип, җанымны телгәләмәгез;
Алмаларны юып сөрттем,
Гөлләргә су сибеп киттем;
Исәннәрем, үпкәләмәгез!

*1994*

* * *

Җир-күктәге барча җисемне дә
Кунак иттем җылы җанымда;
Суга баткан җәйдә яр читеннән
Сыек кулын сузган Талыма
Рәхмәтлемен.

Зар-кайгымны тыңлап тормыйча да
Ят иткәндә якын туганым,
Ялгызларны ялгыз аңлар диеп
Көткән идем Айның тулганын
Дүрт күз белән.

Күктә минем күпме кардәшләрем!
Ага Болыт. Аһ, ул болытлар!—
Тезләремә чүгеп, көлә-көлә
Күз яшьләрен сыккан оныклар
Сыман алар.

Күк йөзенең җем-җем шадралары, —
Йолдызлар бит, — яшьле күзләрем.

Көзге төндә өшеп күшексәләр,
Учларыма алып үзләрен
Җылыттым мин.

Бер җанымны меңгә бүлә-бүлә
Яшәмәдем ләса мин юкка:
Йолдызны Ай белән кавыштырдым,
Сыек Талны елак Болытка
Тоташтырдым.

...И җаныем, сәламнәр дә бармас
Җирләргә мин китеп юлыксам,
Түкмә яшең, көзге йолдызларны
Кочагыңа алып җылытсаң,
Кайтырмын мин.

*1994*

## ХӘЛЕГЕЗ НИЧЕК?

*Ай-уракның иңбашына*
*Эленгән бишек;*
*Күкне биләү иткән сабый,*
*Хәлләрең ничек?*

*Калка кояш, төннең кара*
*Пәрдәсен тишеп;*
*Таңны уяткан гашыйклар,*
*Хәлегез ничек?*

*Атлый солдат, утлы-бозлы*
*Тауларны кичеп;*
*Сыкрый Ана: «Балакаем,*
*Хәлләрең ничек?»*

*Өлгесе ватык тәрәзгә*
*Кар сала ишеп;*
*Ир вафатын кичкән хатын,*
*Хәлләрең ничек?*

*Адашкан юлчы да килеп*
*Какмады ишек;*
*Үлем көтеп яткан әби,*
*Хәлләрең ничек?*

*Кайлардан кемнәр эндәшә*
*Хафага төшеп?*
*Җирдәге җан ияләре,*
*Хәлегез ничек?..*
*Хәлегез ничек?*

*1995*

**ХӘЕРЛЕ КӨН**

«Хәерле көн!» — дидем гашыйкларга —
Алар миңа күз дә атмады;
«Хәерле көн!» — дидем бер әбигә —
Баш күтәрми ары атлады.

«Хәерле көн!» — дидем байбикәгә —
«Ни эшең бар?» — диеп бәйләнде;
«Хәерле көн!» — дидем хәерчегә —
Кулын сузып акча теләнде.

«Хәерле көн!» — дидем сандугачка —
Үзәкләрне өзеп сайрады;
...Бинахакка мине рәнҗетүче
Берәүгә дә үпкәм калмады.

*** * ***

Бу дөньяга без тумаган
Барын да белеп кенә;
Тормыш кайчак елмайса да,
Тормый гел көлеп кенә.

Йөген дөнья җиңел генә
Җилкәләргә аса ул;
Җәяүлегә янчык та авыр,
Бара-бара баса ул.

Шул ул тормыш — арба кебек,
Майланып та җитмәгән;
Шул ул тормыш — ярма кебек,
Вакланып та бетмәгән.

Юк, тормыш ул — бер матур җыр,
Яңгырап уза торган;
Их, гомеркәй, булсаң иде
Гармундай суза торган.

*1971*

**БҮГЕН МИНЕМ ТУГАН КӨНЕМ**

Белсен бәйрәм икәнен:
Атсын таңы иртәрәк,
Ниләр генә теләсәм дә,
Кабул булсын бар теләк.

Якыннар бер-беренең

Саулыгын белешсеннәр.
Таныш булмаган кешеләр
Елмаеп күрешсеннәр.

Тормышлар булсын имин, —
Туган көн бүген минем.

Телетайп, телефоннар
Җиткерсен якты хәбәр:
Тәхетләр, төрмә-зинданнар
Килде, диеп, зир-зәбәр.

Чыелдамасын пуля,
Гөрселдәмәсен пушка;
Халык ирекТә яши, дип
Шапыртмасыннар бушны
Илнең колак төбендә,—
Минем туган көнемдә.

Баш очымда зәңгәр күк,
Утлы яшен яшьнәми;
Бүген тыныч, ләкин кеше
Бер көн белән яшәми.

Дөньяның иминлеген,
Тормышның бөтенлеген
Күтәр син дә җилкәңә —
Туган көнең иртәгә!

*1975*

**ҮЗЕМЧӘ**

Дөньяда күпме кеше:
Һәрберсенең үз төсе.
Бертөрлелек
Кешеләргә хас түгел,
Канат белән тумый кеше —
Оядагы каз түгел.

Кешеләр ул катлаулырак,
Эшләре бәхәслерәк,
Берәүләре кайгылырак,
Берәүләр бәхетлерәк.

Тормыш йөзе сиздертмичә
Күчә кеше йөзенә.
Күмәкләшеп күтәрсәң дә,
Иң авыры — үзеңдә.

Ялгызыма күтәргергә
Көч җитмәстәй күренсә, —
Олылардан киңәш алып,
Мин күтәрәм
үземчә.

*1967*

* * *

Бу гомерем төгәл бер көн кебек:
Чыкты кояш, батты аннары;
Мин бит сезнең күңел күгегездә
Исемсез бер йолдыз нибары!

Өлешемә төшкән көмешемә
Күз күнсә дә, күңел күнмәде.
...Атылды ла йолдыз көпә-көндез,
Көпә-көндез! —
Беркем күрмәде.

*1987*

**ЯҢА ЕЛ ШИГЫРЕ**

Сискәндереп кинәт сукты әнә
Иске елның соңгы сәгате;
Күңелемә кайтты кабаттан
Могҗизалар көтү гадәте.

Йөрәгемдә куәт, күңелдә дәрт,
Күзләремдә өмет үстерәм,—
Иңбашымны сарган сагышларны
Җәһәт кенә кагып төшерәм.

Минсез дә алар үксез яшәмәсләр,—
Сагышларым белән хушлашам;
Аһ-зарларны куып, кочагымны
Туар шатлыкларга шар ачам.

Көләч көннәремне урлап качкан
Ялгышларны юлдан яздырам.
(Абынсам да, егылмадым мин, дип,
Ел чатына язып калдырам.)

Урап кайтмасын дип озатам мин
Кысыр хисләремнең барчасын.
Сабыр тойгы белән көтеп торам
Бәхетемнең капка ачасын.

Дәртләндереп кинәт сукты әнә
Яңа елның тәүге сәгате.
Артта калды кебек кайгыларым,
Алда көтәр — гел-гел әйбәте.

*1969*

**ЧӘЧСӘМ ДӘ ӨМЕТ-ОРЛЫК**

*Шигъри аңгәмәдәшем —*
*вакытсыз вафат булган бурят шагыйре*
*Дондок Улзытуев истәлегенә*

Мине хыялда йөздергән
Бала чагымнан
Гомер буе китмәскә
Исәбем иде;

Мине үләндәй үстергән
Туган нигездән
Гомер буе купмаска
Исәбем иде.

Эссе көндә
Әверелеп тамчыга,
Шиңгән гөлләргә тамарга
Исәбем иде.

Тормыш —
Хуш исле бер чәчкә!
Яшәүдән туйганннарга
Мин якын да йогынмам.
Бу өч җисем:
Җир, су, утым —
Минем терәк баганам.

Ярып вакыт буразнасын,
Чәчсәм дә өмет-орлык,
Их, үзем уралмадым,
Йөгемне сезгә йөкләргә
Юк иде һич тә исәбем,—
Сүземдә торалмадым.

*1982*

**ЮАТУ ҺӘМ ЮАНУ**

Үз яшендә кайсыбыз соң үлә?!
Барыбыз да китә вакытсыз.
Кемнәргәдер еллар бик ягымлы,
Кемнәргәдер бик тә ягымсыз.

Булмый инде үлем үкенечсез,—
Кадерле шул адәм башлары.
Кайгылардан тамган күз яшеннән
Ярыладыр җирнең ташлары...

Кем үлемне күтеп алсын инде,
Килә бит ул әҗәл вакытсыз.
Исән чакта очкын чыгарып тор,
Уйлама син аны, гакылсыз!

Шартлармын дип, ярсуыңны тыйма,
Әйе, дөрес, йөрәк куш түгел.
Башланганын очлап бетерим, ди, —
Үлем алдыннан да буш түгел.

Үз йөрәгем аксый башласа,
Шушы хакта уйлап юанам,
Һәм фатиха биреп юатам:
Йөрәк, димен, ташла исәрлегең,
Бер кырыкка кадәр хет чыда.
Ә туксанга җиткән — теләк тели:
Янә туксанны бир, йә Хода!

*1976*

**ТИШЕК ТАШ**

*Диңгез ярында йөрүчеләр*
*тишек таш эзлиләр. Тапкан кеше —*
*бәхетле, имеш.*

Эзли торгач, мин дә таптым аны,
Миннән соң да күпләр таптылар,
Биш кат бәхетлеләр «бәхетләрен»
Дулкын кочагына аттылар.

Бер уйласаң, бу тормышта безнең
Иң зур байлык — өмет, ышаныч.
Кайгы-сагыш — чакырганны көтми
Килә торган әрсез бер таныш.

Карадым да ташка, узган гомер
Әллә ничек моңсу күренде:
Бәхетем дә минем үзем тапкан
Чуерташтай тишек түгелме?

Үткәннәрдән урап кайткан күңел
Кабат-кабат шуны тукыды:
Дулкыннар бит әнә ташны тишә,
Ниләр тишмәс

еллар дулкыны!

Дулкын тынмый — һаман ярны ялый.
Еллар туймый — ялый гомерне;
Их син, язмыш! — бер ягыннан корсам,
Ул икенче баштан җимерде.

Ә шулай да тормыш гаҗәп матур,
Барысын да барлап карасаң;
Диңгезнең дә менә
биткә бәргән
Салкын тамчысын да яратам.
Ялтыр ташны, тере тавышларны,
Кул җылысын тойган чагында
Кем санасын үзен бәхетсезгә! —
Кит син, сагыш,
якын йогынма!

*1982*

**ИКЕ СУРӘТ**

**1**

И бала чак!
Яшел ялан, кызыл учак,
Очкыннары кочак-кочак.
Уй-хыяллар — күккә сыймас,
Иркебезне беркем тыймас;
Хәвеф-хәл юк шомга салган, —
Атларыбыз тышауланган.
Тышаулы ат ерак китмәс,
Ерак китмәс!

**2**

И олы чак!
Коры ялан, соры учак,
Оча көле кочак-кочак.
Чал башларны сагыш баскан,
Бар өметләр өркеп качкан,
Шомлы тынлык чорнап алган, —
Хис-теләкләр тышауланган.
Тышаулы зат ерак китмәс,
Ерак китмәс!
...Әрнеш бетмәс...

*1989*

**ҮЗЕМӘ КАЙТЫП БАРАМ**

Күз ачкысыз ыжгыр буран
Яуса да урап-урап,
Кереп киттем бер сукмактан,
Тормадым шул юл сорап.

Кая барып чыгармын дип
Шомланып уйлап куям;
Таныш җирләр түгеллеген
Табаным белән тоям.

Кайсыбызның юлларына
Җәеп куйганнар юрган?!
Адашса да, алда була
Бертуктамый юл ярган!

Мәңге котырмас җил-давыл,
Басылыр көн ачылгач;
Күңелдә купкан бураннар,
Аһ, тиз генә басылмас!..

Кайларга илтер сукмагым?
Кай тарафка юл ярам? —
Үземә дә сиздермичә,
Үземә кайтып барам...

*1965*

*** * ***

Белмим, кеше нидән яралгандыр?
Берәү, судан, ди, берәү, уттан, ди,
Ә берәүләр,
без тик тузан, ди.

Белмим, кеше нидән яралгандыр?
Су булып агабызмы,
Ут булып янабызмы,
Әллә инде тузан булып
Туфракта калабызмы?

Белмим, кеше нидән яралгандыр?
Су булса, ул — ташкындыр,
Ут булса, ул — ялкындыр,
Җир булса, ул — алтындыр;
Юктыр, юктыр,—
Кеше — һәм тузан, һәм су,
һәм уттыр.

*1967*

**АШЫГУ ҺӘМ АШЫКМАУ**

Яше дә, карты да ашыга:
Яшь-җилкенчәк очрашырга,
Кеше-кара күрмәгәндә
Үбешергә,
Мәхәббәтен бүлешергә,
Бер дә юктан үпкәләшеп,
Тиз арада килешергә,
Матурлыкка,
Буй-сынына сокланырга.

Кыз —
Яман күздән сакланырга;
Егет —
Чибәрләргә күз атырга,
Моны кызы сизеп калса,
Акланырга,—
Бу дөньяның бар ләззәтен
Тизрәк татырга ашыга.

Карт-коры
Акыл сатарга,
Тәҗрибә уртаклашырга,
Кайгылыны юатырга,
Хөр яшьлеген искә төшерергә,
Оныгын кулында сикертә-сикертә
Тизрәк үстерергә,
Көзләр җиткәч сагышланырга,
Төгәл яшен ялгышырга,—
Дөньяның рәхәте, ләззәте
Алда әле, дип
Яшәргә ашыга.
Менә шул яше дә, карты да
Һич ашыкмый,
Исәннәрдән калышмыйча,
Күз яшьләрен тамызмыйча
Табут артыннан барганда...

*1972*

**ӘЛЛӘ БАЛАН КАРТАЯ?..**

*Украин шагыйре Петро Махка —*
*уртак язмышлы дуска*

Калкулыкта шомлы тынлык,
Сызланамы сугыш кайгысы?
Әтиемнең кабере кайсысы?!

Тирә-юньдә шау балан,
Башым иеп тын калам,
«Тагын килдеңме, балам?!»

Еллар-дәверләр аша
Әткәй миңа эндәшә:
«Минем өчен дә яшә!»

Әллә балан картая?
Ачысы һаман арта...
Эчтә ут булып ята...

Тик нишләптер мин тыныч,—
Җиргә күмелгән сугыш...
Киңәя төшә сулыш...

*1973*

**ЗАМАНДАШКА**

*Нажия Даяновага*

Без назланып яшәмәдек,
Без сызланып яшәдек;
Үскәндә үк бәхет белән
Үрәлмәдек әшнәлек.
Ямаулы иде заманы,
Ә еллары бик ябык;
Кайгы,
көзге яңгыр кебек,
Торды гел өскә явып.
Үлчәргә бизмән табылмас
Безгә төшкән өлешне;
Сукыр лампа сөремендә
Сүндермәдек өметне.
Кырлы-кырыс бу дөньяны
Без үзебезчә ачтык;
Баш күккә тими,
тик җиргә
Аякны терәп бастык.
Бәхете дә хәзер бездә
Кунак булып киткәли;
Нужа бабай кайтмас җиргә
Олакты да микәнни?!
Сагаю сагыш уята,—
Тый аны, тыйма аны,—
Күзләрдән саркып чыккалый
Күңелгә сыймаганы...
Ә безнең холык хакында
Сүз кузгату кирәкмәс:
Яманы — телгә дә йокмас,
Яхшысы — телдән төшмәс.
Утырмыйк әле уфтанып,

Их, картаябыз, диеп,
Башларны бәс сарган саен
Башны югары чөйик!..

*** * ***

Аллаларны үзебез тудырабыз,
Аллалар — арабызда.
Кемгә дә булса табыну
Сеңгән шул каныбызга.

Бабалар утка табынган,—
Уттан көчле булмагач;
Без хакимгә табынабыз,—
Акыл белән тумагач.

Хакыйкатьне, гаделлекне
Син үзеңә баш яса:
Ул чагында «алласыз» да
Яшәп булыр лабаса!

*1964*

## ШУНДЫЙ КӨННӘР БУЛА

Була шундый көннәр: көләч кояш
Күзен кыса сиңа беренче;
Яртылаш ят кешең, шат елмаеп,
Әйтер кебек: «Рим, сөенче!»

Кызык та соң дөнья, — көнгә чыксаң,
Куанычлы хәбәр көтәсең;
И ваемсыз бәндә! — онытасың
Кайтып булмас җиргә китәсен.

...Сүнә кояш, салкын чоңгылына
Чәнти бармак чаклы арадыр;
Сөенечсез калган бәндәләрнең
Йөрәгеннән каннар тамадыр.

*1994*

## БЕЗ БӘХЕТЛЕ ЛӘСА!

Без бәхетле ләса:
Ач-ялангач тудык, үстек,
Ходай бирмеш гомер кичеп,
Дөньяларның фаниена
Ач-ялангач килеш күчтек. —

Без бәхетле булдык ласа...

* * *

*Әнгам абый Атнабаевка*

Киттек, дус, елга буена,
Качыйк бу каласыннан,
Аз гына авыз итәрбез
Озонлы һавасыннан.

...Тукталыйк шунда. Утырыйк,
Аяклар салындырып;
Кайчагында ялгызлык та
Куя бит сагындырып...

Кирәкми дөньяви хәлләр,
Беренче мәхәббәтләр,
Макташмыйк та бер-беребезне,—
Без болай да әйбәтләр.

Күзәтик әйдә тын гына
Агыйделнең акканын,
Күрми яшибез калада
Җәйге кояш батканын.
Ашы-ык-мыйк!

Без өйрәнгән,
            күтәрербез
Бичәләрнең битәрен,
Куркасы юк, көтәр алар,
Беләбез бит көтәрен.

Әйдә кузгалыйк алайса,
Караңгы каплап килә.
...Тын, тын-н, —
Анда аста
Ташлы ярга башын бәрә
Бәйдә торган бер көймә...

*1968*

**БАРЫСЫ ДА КЕШЕЛӘРГӘ КАЛА**

Барысы да кешеләргә кала:
Исәннәргә кала.
Киткән кеше
Әйтелмәгән сүзен генә
Үзе белән ала.

Нидән дисең

Кабер һәрчак
Киткәннәрнең бөкре аркасыдай
Калкып тора? —
Киткән кеше кара гүрдән
Күтәрелеп,
Үзе белән алган
Иң кирәген әйтергә дип
Газаплана...
Менә тора, инде тора...

Соң, кешеләр,
Ник әрвахтан курыктыгыз:
Күтәрергә көче җитмәс
Таш та куйгач,
Тимер койма ураттыгыз?..

...Бар теләгем:
Исән чакта иң кирәген
Әйтеп китеп булса иде,
булса иде!

*1972*

* * *

Юанмыймын хәзер юк-барларга,
Тәти сүзләр җанны эретми,
«Яныңда шан шаулап торсын дисәң,
Очкан чакта оран сал син»,— дигән
Киңәшең дә миңа кирәкми.

Очыш бит ул — сулыш.
«Ник кычкырып
Суламыйсың әле?» — дип сорау
Биргән кебексең син.
Әйдә очсын!
Тып-тын! Канатына кошның
Ник тагарга әле кыңгырау?!

*1981*

* * *

Мин бербөтен. Яманга йә
Яхшыга бүленмәдем;
Сынсам сындым, бөлсәм бөлдем,
Беркемгә бөгелмәдем.

*1975*

* * *

Кайларда калды сүрелеп
Җаннарны өтәр хисләр?
Баешларга баккан саен
Калкына үкенечләр.

...Барасы юлым, һай, ерак,
Офыкны ашкан иде,
Анда бәхет каршы чыгып
Кочагын ачкан иде;

Елларның мин җилләрдән дә
Җитез атында җилдем,
Күңелем белән күкләрнең
Җиде катында идем;

Ак иде минем иманым,
Ярдым һава: «Ха-ак җиңә!»
...Сөрлекте атым кинәттән
Һәм кадалдым как җиргә;

Колаганнар кемгә хаҗәт! —
Атым тукталмый китте,
Шөкер иттем шул хәлемә:
«Ярый таптамый үтте!»

Яраларым ялый-ялый,
Киттем ары кузгалып,
Ялгыз башым шау яланда,
Йөрәгемнән куз алып,

Яктым учак. Тән салкыны
Җанга күчмәсен, дидем,
Сабыйлар бар, дөньясына
Кырау төшмәсен, дидем;
Ут-учагым йолдызларны
Балкытмагандыр, бәлкем,
Тик күкләрне, тик күзләрне
Төтәсләмәдем ләкин;

Бетмәгән икән омтылыш:
Җиһанның тын алышын
Тыңлый-тыңлый акрын гына
Һаман алга барышым;

Көенмәмен, инде бәхет
Ачмаса да кочагын;
Сөенәмен: дөрләтерләр, —

Тере калды учагым!

...Көн сүнә әнә күренеп,
Тәмен югалта төсләр;
Ишелә кояш офыкка, —
Ишәя үкенечләр.

* * *

Исәпләсәң, исең китәрлек, —
Кайчан гына төштек итәктән, —
Күр син,
Тормыш бездәй бөртекләрне
Иләп ята эре иләктән.

Кырыс заман алмый арасына
Бөртекләрнең ярым-яртысын;
Җир үзе дә түм-түгәрәк түгел,
Мәгәр кеше
Күз алдында тота шар төсен.

Җитмәгәнен мин дә җиткерим дип,
Берсен алам, берсен салам...
Мәш килеп йөрим һаман;
Кояш баккан җир өстендә
Әйтерсең дөнья туе.
...Гомернең калган юлы —
Бер сапламлык җеп буе.

*1967*

**ШУНДЫЙ ХАЛӘТТӘ**

Эчләремдә утлар яна,
Көнен дә төнен тынмый,
Кем күрер дә кем сизәр соң? —
Ялкыны бөркеп чыкмый.

«Янам», — диеп яр салу да
Мондый чакта килешмәс;
Дөньясы бит тома чукрак,—
Чаң суксаң да ишетмәс.

*1991*

* * *

О, Могҗиза! Торма якында,
Торыр булсаң әгәр якында,
Гайбәт кубар синең хакыңда.

Туры килер шуны татырга:
Кояш булсаң, бирмәс балкырга,
Алтын булсаң, манчыр бакырга.

*1994*

*** * ***

Көсләр өстә, ә зур балык
Караңгыда — тирәндә.
Нигә алай, зур балыклар
Кояш нурын сөйми әллә?
Шул хикмәтне төшендерер
Бер кеше юк тирәмдә.

## СУКБАЙЛАР ҖЫРЫ

И бу дөнья, бу дөнья
Кайдан тотсаң да шуа;
Без братны карында ук
Ходай каргаган гүя.

Кайда тели, шунда оча акчарлак;
Без йөрибез салкын чардакны чарлап.

И бу дөнья, бу дөнья,
Үги ана ул гүя;
Бәндәгә тиеш назларның
Безгә дигәне кая?

Дулкын чемчеп, ризык таба акчарлак;
Без табабыз чүплек башларын чарлап.

И бу дөнья, бу дөнья
Арт санга тибеп куа;
Җир бетереп эзләсәк тә,
Табылмый җылы оя.

Бер канатың бүлче безгә, акчарлак;
Гизәр идек диңгезләрне, их, парлап.
И бу дөнья, бу дөнья
Сандалга салып төя;
Ышыгы юк илдә безне
Шыксыз җил генә сөя.

Ирек кочып, горур оча акчарлак;
Баермы ил ачның бәхетен урлап?

И бу дөнья, бу дөнья
Кабергә кадәр — нужа;
Дөньядан тиз туяр бәндә,
Күзләрен ачып туса.

Их, дөньяны булсын иде акшарлап;
Канатсызлар өчен дә оч, акчарлак!

*1998*

## КАРА ШИГЫРЬ

Эшкә барам — караңгыда,
Эштән кайтам — караңгыда,
Шулай бер төн китәрмендер
Кара гүргә — караңгыда.

*1986*

## КАБЕРЕМ ТАШЫНДАГЫ ЯЗУ

Исән чакта иң бай кеше идем.
Гүзәл җирләр — минем биләмәм.
Баш очыма чәчкә төртегезче! —
Башка берни сездән теләмәм.

*1985—1991*

## СЕЗ ДӘ БИТ КОШЛАР КЕБЕК

*Рәссам Әнвәр Кашаевка*

Ходай күктән урын биргән
Канатлы кошларына;
Сез дә оя корасыз ич
Биек йорт башларына.

Кошлар илә художниклар!
Ахры, сез бер нәселдән;
Кабарып тора канатлар
Сезнең һәрбер рәсемнән.

Беләм, сез дә мәхрүм түгел
Дөньяның карасыннан.
Тик ак белән хак сайлыйсыз
Мең төсләр арасыннан.

Таң нурлары иң тәү башлап

Сезнең ишекне шакый.
Ник күңел якты булмасын! —
Сез бит кояшка якын.

Җирдәгеләрдән бер теләк:
Төсләрне вакламагыз,
Безгә дә төшсен нурлары, —
Кояшны капламагыз!

**КӨН ӨСТЕНДӘ ТУГАН УЙЛАР**

Ишетте дә пычкы тавышын,
Тетрәнде яфрак шом тыңлап.
Ауды агач, күпме тартышмасын
Тамырлары белән җир тырнап.

...Ары китте урман кыркучы.

Үкси чишмә, әллә тау-ташларны
Ярып чыкканына үкенә?
Кара янып калды зәңгәр күзе
Килеп төшкәч зур кәс битенә.

...Ары китеп барды көнлекче.

«Чәчәгем дә төсен балкытмаган,
Өзмәсәгез иде бу юлга!» —
Биле сынган нәни сабактан
Ал кан тамды йөнтәс бер кулга.

...Ары китеп барды гашыйк җан.

«Хат-хәбәре бармы?»— дигәннәргә:
«Бар, бар», — диде Ана, танмады.
Каладагы улы кош теледәй
Хат язарга вакыт тапмады.

...Дөнья көтте эшем иясе.

«Кешеләрне яратыгыз!» — диеп,
Мөнбәрләрдән ярсып сөйләде.
«Изге бәндә» әле бер тапкыр да
Үз баласын кочып сөймәде.

...Ә теленә тилчә төшмәде.

...Ә мин үзем ничек яшимен соң?

Мин үзем соң ничек яшәдем?
Курка-курка сорау биргән ятим
Бала кебек телем тешләдем...

*1976*

* * *

Җәйне күрми көзгә кердем...
Күңелем тулып китте.
Әйтерсең лә чакырылып
Озакка дип килгән кунак
Берне дә кунмый китте.

Җәй күрмичә көзгә кергән
Бу күңел, күңел, күңел
Төпсез кое белән бер:
Хет чиләкләп түк сагышын,—
Һич саегырлык түгел.

* * *

Күрәсеңме, калка яшел үлән,
Серләшкәнең бармы алар белән?
Үлгәннәрнең рухын аңларсың син,
Үләннәрнең йомшак телен белсәң.

Күрәсеңме, чаба инеш-елга,
Ага көн-төн, һаман агып бетми,
Тыңла җырын яшәгәндә җирдә,
Андый моңнар юктыр әле гүрдә.

Күрәсеңме, җырлый кыя-таулар,
Тукмый җилләр, — һаман исән-саулар;
Күтәр башың, авыр уйлар басса,
Тауга баксаң — кайгыларың кача.

Күрәсеңме, балкый йолдыз күктә,
Кулың сузсаң, күрешер кебек тә,
Фәһем ал син, мәңге яшәп күрше,
Кысрыкламый алар берсен-берсе.

...Үлән үлсә, сулар җиргә сеңсә,
Таулар ауса, барча йолдыз сүнсә,
Ни кылырсың ялгыз и син, бәндә?
Табигатькә табын көн дә, төн дә!..

*1995*

* * *

Бәхетегез баштан ашканда
Онытсагыз мине, —
Гафу итәм.
Кара болыт булып
Кайгы килгәндә
Онытсагыз мине, —
Беркайчан да гафу итмәм
...үземне.

*1966*

* * *

Карая каен
Картайган саен;
Кайгыга батып
Карая бәндә
Яшәгән саен.

*1979*

* * *

Аптырарсың бәндәләрнең кылыгына,
Ятып калганчы дип, кала атып:
Түрә була кайсылары табан ялап,
Имам була кайсы иман сатып.

**ЯРЫЙ АДӘМ КӨЧСЕЗ ӘЛЕ...**

Кеше көчле.
Буй сындырмый гына
Барсын буйсындырыр,—
Табигатьне, җәнлек-хайванны;
Әнә Кояшны да
Тартып алып
Бәйләп куярлар да
Сүндермәсләр иде эш бетми;
Иллә ярый адәм көчсез әле.
Тәки...
Их-ма! — Буй җитми.

* * *

Ни кылаек, заманы залим булды:
Җанга шак басып, каһкаһәләп, һай, көлде;
Бәхетлеләрме? Булды ара-тирә:
«Бере ул — кем тугмады,
бере ул — кем үлде»*.

**АПТЫРАГАННАН ЯЗЫЛГАН ШИГЫРЬ**

*Сөеклеләргә*

Патшаларны барлап чыктым бүген
Дәверләрдән, һәммә илләрдән:
Сугышлар ул шуңа тынмыйдыр да, —
Бит патшалар гел дә ирләрдән.

Тәхетләргә чат ябышкан алар,
Бере — исәр, берсе — башкисәр, —
Җанлы курчакмыни! Арт санына
Шәпләп типсәң генә ул төшәр.

Ә шулай да тәртип-кагыйдәдән
Чыкмый калмас бер-бер искәрмә:
(Искәрмәне искә ал да
тубал
Башларыңны ташка бик бирмә!)

Әнә ерак, әнә якын тарих, —
Әби патша, Тэтчер... башкалар,
Исләп торсаң, шулар хакимендә
Күп хыяллар чынга ашканнар.

Шома йөзле әрсез узаманнар
Тәхет өчен яман өзешә;
Шуңадыр да ирлек горурлыгы,
Күрәсездер, көннән-көн төшә.

Исми яңа җилләр, шуңа тынчу
Без көн иткән тап-тар бу читлек;
Юл ачылсын Әби патшаларга, —
Күрсәтик без, ирләр, егетлек!

*1999*

*** * ***

Бәхәс бара илдә ике гасыр:
Ленин бабабызны күмәргәме, юкмы?
Уйлап куям: мин дә бабай хәзер,
Мал-мөлкәтем мөшкел, —
Үләргәме, юкмы?

*** * ***

Шәһәр агачлары шыр дивана:
Рөхсәт сорамыйча үсәләр,
Башкалардан биек булса берсе,
Башкайларын тотып кисәләр.

*1982*

* * *

«Нинди гүзәл чәчкә!» Бактым аңа
Әллә күпме вакыт тоташтан;
«Нигә әле сула башлады ул?» —
Каплап торам икән кояштан.

*1962*

**БЕЛГӘН КИЛЕШ**

Башларым бәрелмәячәк,
Беләм, күк чиксез биек;
Тик ниткән эш: белгән килеш
Йөримен башым иеп.

Гомердә бер килә торган
Сорау кайный канымда:
«Йә, ни кыла алдым соң мин
Бу мәңгелек алдында!»

Мәңгелек алдында тузан
Икәнлегемне беләм,
Күктән йолдыз чүпләр вакыт
Күптән узганын беләм.

Гомер җебен төйнәр вакыт
Җиткәнлеген дә беләм;
Тик ниткән эш: белгән килеш
Йөрәгем меңгә теләм!

...Җирдә яткан салкын ташның
Монда соң ни катнашы?
Кайнар башым терәү белән
Таш шатырдап чатнады...

*1971*

**НИГӘ, НИК?**

Алкын гына агым сулардан да
Нигә язмыш ачы көлә?—
Дәрьяларны барып кочалмыйча
Сазлыкларга батып үлә.

Йолдызлар бит, зат-милләткә бүлми,
Барчабызга назлы бага,—
Ник мең милләт, үзенеке итеп,

Үз телендә исем тага?

Сайрар кошлар кайгы кичми мәллә?—
Шат сайравы һич өзелми;
Кадерләрен, әйе, һәркем белә,
Каберләрен беркем белми.

Кем аңлатыр безгә, әнисенең
Күкрәк сөтен имеп үскән
Бала... үскән... аннан, йә, ни уйлап,
Әнисенең җанын кискән?..

...Нигә эчем поша,
        бакчадагы
Тир түгүче дус кырмыска
Сәламем дә алмый узса?..
Башым тубал, чыгарыйм соң
Бу кыйссадан нинди хисса!..

*2002*

**БУЛСАЧЫ...**

Бәхетне без умырып тотар идек,
Тик кайда соң аның кулсасы?
Җырлап кына яшәр идек тә бит, —
Җырлап кына яшәп булсачы!

Нигә шулай ис-төтенгә тула
Ак дөньяның кара мунчасы?
Елап кына яшәр идек тә бит, —
Елап кына яшәп булсачы!

Их, кояшта җылынмый да калдык,
Җитеп беткән әнә кичләр дә;
Өннәрендә рәхәт күрмәгәннәр
Ләззәт кичерсеннәр төшләрдә!

Бәндәләрне нинди омтылыш соң
Алга әйди алдап көн-төнен?
Челпәрәмә килгән өмет белән
Бәхетләрнең көтә бөтенен.

Елап туйгач, кинәт җырлый башлый,
Башкалардан кимен куймый ла,
Теткәләнгән йөрәк типкән чакта
Яшәүләрдән беркем туймый ла!

Баемаган кояш, җырлыйк әле,

Елап кына яшәп булмый ла!

*2000*

**ИСӘН ЯШИЛӘР ИЧ!**

*Сөембикә апам Кудашевага*

Бактым исә бакый язмышларга,
Түмгәк кенә — таудай кайгылар;
Меңнәр керсен урманнарга, тәүләп, —
«Безнең тамыр» диеп, —
Сезне танырлар!

Үз кайгысын ташкын Димгә ташлап,
Күшек җанны кемнәр иркәләр?! —
И Ходаем, безнең бәхеткәдер,
Исән яшисез ич, Сөембикәләр!

Яшәү тансык — намус белән сафлык
Күз алдыңда бергә йөрсәләр;
Тамчы яшем күрсәтергә куркам
Исән яшәгәндә Сөембикәләр...

*2002*

**ГОМЕР ТОТАШ ХУШЛАШУДАН ТОРА**

Сагыш йөзе таныш түгел чакта,
Туган ягым белән хушлаштым,
Һәм каланың салкын ташларына
Тузган чабатадан мин бастым.

«Хуш!» дидем мин зәңгәр күзле кызга,
Җиңнәремә сөртеп яшемне.
(Их, кайсыбыз гына булды икән
Тәүге мәхәббәттә бәхетле?!)

Яшәп көйгән Әнкәм белән салкын
Кабер өсләрендә хушлаштым:
Ыңгырашкан зират капкасын да,
Шатлык капкасын да шап яптым.

Түз йөрәгем! — аһ, нинди терәгем! —
Күмелде дә калды чоңгылда;
Син яшисең кебек, улым! Кичер,
Һаман хушлашалмыйм чынында.

Бик вакытлы, бик вакытсыз киткән
Күпме җан дус белән хушлаштым,
Бар гомерем хушлашудан торгач,
Мин кадерен беләм сау башның.

Әйт, нәрсә ул яшәү? Безнең гомер —
Соңгы шәме сүнгән мәгарә;
Үзем белән үз аңымда чакта
Хушлаштырсын Ходай Тәгалә!

*2000*

**ҖИҢЕЛСӘҢ ДӘ — ҖИМЕРМӘ!**

Кеше тауга үрмәли,
Ташларын үбә-үбә;
Кеше мәтәлә таудан,
Ташларын тибә-тибә.

Үрләгәндә, ул ташлар
Табанга терәк иде,
Мәтәлгәндә, ул ташлар
Нәрсәгә кирәк инде?!

*1967*

**СУЛЫШЫМНЫ СУЛГАН ГӨЛГӘ ӨРДЕМ**

Көз каплаган гомер бакчасыннан
Караш атсам килер дәвергә,
Ачы бер хис очлы хәнҗәр булып
Кадала да тора бәгырьгә.

Сискәндерер кемне сәер хисем,
Кем ишетер ябык тавышым?
Китек күңел белән китәрменме
Аңламыйча гавам агышын?

Мин яраткан гөлләр сулган, язын
Терелерме икән кабаттан?
Кара төндә диңгез уртасында
Кара төпкә баткан корабтан
Кем котылып калыр?! Язмыш — давыл,
Кочагына кайчан аласын
Кем соң белсен?! Кыйналган эт кебек
Яраларың ялап ятасың.
Дәрья булып хәсрәт ташкан чакта
Синең кайгың кирәк кемнәргә?
Ярый ла ул якын кешең булса
Ялгыз башкаеңны терәргә.

Кайдан килсен бәхет! — Ач хакыйкать

Яткан чакта җирдә җан биреп:
Ак яшәргә ирек бирелмәде,
Кара үлем өчен мул ирек.

Күз каплаган гомер бакчасыннан
Караш атсам үткән дәвергә,
Әнә шул хис үткен хәнҗәр булып
Кадала да тора бәгырьгә.

Китек күңел белән китәрмендер
Аңламыйча дөнья агышын;
Сулышымны сулган гөлгә өрдем, —
Тере калыр минем тавышым.

*1996*

## *КИЧЕРЕГЕЗ!*

*Баш күтәртмәс зар-кайгылар*
*Баш булган чакта көн-төн,*
*Йә, кайсыгыз әйтә алыр:*
*Бәхтем, дип, минем бөтен?!*

*Дөнья салкын, өши тәнең;*
*Кичерегез, Әнкәйләрем!*
*Кичерегез, әбекәйләрем!*

*Йә, кайсыгыз әйтә алыр*
*Ни икәнен бәйрәм-ялның?!*
*Гомер илне туйдырсаң да,*
*Гомер буе син ач калдың.*

*Тормыш кичеп, бетте хәлең;*
*Кичерегез, Әнкәйләрем!*
*Кичерегез, әбекәйләрем!*

*Йә, кайсыгыз әйтә алыр:*
*Урыным, дип, минем түрдә?!*
*Урыныгыз түрдә булыр*
*Бары гүрдә, бары гүрдә...*

*Узды гомер, тузды шәлең;*
*Кичерегез, әбекәйләрем!*
*Кичерегез, Әнкәйләрем!*

*1982*

## **БИГРӘК МАТУР ЯШЬТӘСЕЗ!**

И апалар, и абыйлар!
Сөйкемлесез барчагыз;

Без кемнәргә сыеныр идек,
Әгәр Сез булмасагыз!

Кол да, тол да булдыгыз Сез, —
Бу сүзем түгел ялган,
Намусны иш иткәннәргә
Аяусыз икән заман.

Биткә бәреп искән җилнең
Сез йоттыгыз ачысын;
Кайтарып алыр идегез
Ул елларның кайсысын?

Кайгы җанны көйдергәндә,
Сабыйларга бактыгыз;
Кояш сүнсә, җан җылысын
Юрган итеп яптыгыз.

Сездән калган олы мирас —
Бу дөньяның ак төсе;
Безгә күчеп калды микән
Сезнең күңел яктысы?

Инде без дә картайдык, дип
Хафаланмагыз юктан;
Әнә сырлар арасына
Яшь чакларыгыз поскан.

И апалар, и абыйлар! —
Ягымлысыз барчагыз;
Дөнья котсыз калыр иде,
Әгәр Сез булмасагыз!

Бигрәкләр матур яшьтәсез,
Яшәгез дә яшәгез!

*2000*

**ӘНКӘЙЛӘРНЕ ЯКЛАП**

Сагышлы дип мине үртәмәгез,
Сатып алмадым мин сагышны.
...Ул елларны, әйе, мин күрмәдем,
Мин күрмәдем, әйе, сугышны.
Мин күрмәдем...
Яттым мич башында
Әткәемнең тунына төренеп.
Ятимлекне шуңа белмим дә мин,
Килмәде ул миңа күренеп.
Килсә килгән... Әнкәй белгән:
Язу төшеп киткәч кулыннан...
Ул язуны миннән тартып алды,
Язу танымаган улыннан.

Хәтта «мәэмәй» итәр чакларда да
«Төпчегем» дип никтер юатты.
Иртә торып соң йоклаган кеше, —
Ул иртәрәк торып соң ятты.
Күз алдымда бар да,
күз алдымда,
Төштә түгел алар — өнемдә.
Әнкәй яшерсә дә,
ятим калганымны
Мин барыбер белдем. —
Белдем
Җиңү көнендә...

Сагышлы дип мине үртәмәгез,
Ятимлектән түгел бу сагыш.
Әнкәйләрне икеләтә ана,
Икеләтә ата итте бу сугыш.
Шуңа да тиз картайдылар алар;
Көтә алар безнең кадерне.
Без, юньсезләр, һаман
бала әле;
Аһ, өйрәндек ашап әзерне...
Без баланың балаларын хәзер
Тәрбияләп яши әнкәйләр.
— Ул карамый, кем карасын!
Тиеш! — дип тә кайчак әйтәләр.

Син дә, мин дә, ул да
күз алдында
Үткәрәбез шундый тормышны.
Сагышлы дип үртәмәгез мине.
Мин кичерәм,
Йөрәк аша кичерәм
Әнкәйләргә төшкән сагышны.

*1967*

**БИТАРАФ**

Күз яшемне көнгә күрсәтмичә
Елар идем
эчем пошканнан;
Тик Әнкәйләр юклык заманда ук
Безгә еламаска кушканнар.

Без тук хәзер,
Барысы да әзер,
Без әзергә генә өйрәнгән.

Дөнья куласасын үз җаена
Әйләндерер өчен көйләнгән
Арык суы кебек ага тормыш, —
Тигез. Уңай. Җайлы. Тып-тыныч.
Тын йокыга талган вөҗданыңны
Уятырга хәтта куркыныч.
Агу алмас коңгыз явымыни! —
Битарафлык басты күңелне.
...Ә Әнкәем минем көтеп ята
Көтмәсәң дә килер үлемне.
Юк,
Яшәүдән һич тә туймаган ул,
Туямыни бәндә кояштан!
Тик кояш та котсыз тоеладыр,
Мәхрүм калсаң җылы караштан.
Борын-борыннан ук яшәешнең
Асыл заты булган мәрхәмәт,
Кая киттең? Син кылдыңмы безгә,
Без кылдыкмы сиңа хыянәт?!
Кайчан гына кытлык, түрә булып,
Түр башында торган заманда
Кеше изгелеккә табына иде,
Көн юк иде ялган-яманга.
Шул изгелек бүген килеп безгә
Ямьсез карчык кебек күренә,
Ахыр чиктә (Әнкәйләрне хәтта!)
Кысрыклыйбыз ишек төбенә.
Аһ-зарларга «аһ» дип торган күңел,
Саектыңмы әллә туклыктан?
Үкенечләр үлгән, шик-шөбһәләр сүнгән,
Әнә диңгез,
        ул да тубыктан...
Арык суы кебек ага тормыш,
Аллы-гөлле әнә бар тараф.
...Әнкәм минем үлем көтеп ята,
Мин битараф бугай, битараф...

Их,
Күз яшемне көнгә күрсәтмичә
Елар идем
        эчем пошканнан;
Тик Әнкәйләр туклык заманда да
Безгә еламаска кушканнар.

*Февраль, 1985*

**БАШ КҮТӘРҮ**

Солдат
Баласын күкрәгенә кыскан Анага
Мылтыгын төзәде.
Бер — яшәү, бер...

Тәү башлап баш күтәрде пулялар:
Алар,
Баш-аягы белән тартышып,
Көпшәгә ябышып каттылар;

Солдат билендәге гранатага үрелде.
Ә граната тотты да күккә атылды;

Солдат хәнҗәренә тотынды:
Үткен хәнҗәр
Кояш нурына тию белән
Челпәрәмә килеп ватылды.

Солдат коралсыз калды.
Ана
Бар дөньяны суырып алырдай
Сулыш алды, —
Котылды.

*1967*

*** * ***

«...Ачлык баскан елда...» —
Дип, Әнкәем әле дә сөйләр,
Кулында көч калмаса да
Ипине ул үзе телер.

«...Сугыш чыккан елда...» —
Дип, Әнкәем һаман сөйләр,
Тыныч йоклый алмаса да,
Безгә тыныч йокы теләр.

Килеп, китеп тора афәт,
Кайлардадыр
Җир тетри, сугыш котыра...
...Аягына басмак булган улым
Аягында чак-чак басып торган
Әнкәм итәгенә тотына.

*1973*

## КӨЗГЕ КӨНДӘ ЙОРТ АЛДЫНДА

Көн туды тагын бүген,

Берни юк күтелмәгән:
Күчәрендә әйләнгән Җир, —
    ә дөньяның
Чите дә кителмәгән.

Әнә кояш күтәрелә,
Калмаган һич тә соңга.
Исем китеп карамадым —
Кояш бит көн дә чыга.

Ихатада чыр-чу килеп
Куыша бала-чага,
Искитәрлек берни дә юк —
Алар көн саен чаба.

Аяк аска соры яфрак
Шарт та шорт килеп ява;
...Күрше әби көнгә чыккан,
Килешер дип саф һава.

Утыра ул өйалдында,
Көннәр буена тормый;
Тыңламасаң да сөйли ул,
Ишетмәсә дә тыңлый.

Сулышларың бәрелгәндә
Сөйләшми булмый һич тә, —
Сорап куям сүз булсын дип:
— Инде, әби, ничәдә?

Әллә гомер тугаеннан
Үткәнен сәрмәп йөри:
— Истә булмыйча, истә,— дип,
Әби хәтер йомгагының
Чуалчык җебен сөйри.

— Ямьсез карчыкның яшьлеге
Булмагандыр димә син...
Һи, гомерләр ага икән,
Исләр китә исләсәң...

Саулыкның хет бер мыскалын
Кайтарырга соң кая?!
Мәгәр тузып-тутыксаң да,
Туйдырмый икән дөнья!

Керим әле, чәйләр эчсәм,

Хәлләнеп китәм тәмам...
Иртәгәсе кояшны да
Күрергә язсын, балам!

...Ихатада шау-гөр килеп
Кинәнә бала-чага;
Баш очыма агачларның
Сап-сары яше тама...

Көнләшепләр карап калам
Мең сырхаулы карчыкка;
Әби түгел, мин чирлимдер:
Күнегәм — матурлыкка...

*1973*

**ИШЕТӘСЕҢМЕ?**

Ишетәсең микән аһ-зарларны
Җил-давыллы гыйнвар кичендә?
Бураннарны каргап ята булыр
Ялгыз карчык авыл читендә.

Тышкы келә җан-бәгырен телә
Җил каерган саен шап та шоп;
Пошына ул нигә? Кайтыр юлда
Калыр кешесе юк адашып.

Балалары гүрдә, ә ул исән,
Исән килеш ята ут йотып;
Әҗәл аның арык гәүдәсеннән
Алыр кебек бүген үк тотып.

Салкын өен сискәндергән уен
Сүндерер дә янә кабызыр:
«Китеп барсаң капылт, тәүбә, тәүбә,
Туң салкында кабер кем казыр?»

Уятты да уен, ач бүредәй
Ташландылар аңа хафалар:
«Кем соң белә, бозлы тәрәзәңне
Кайчан килеп, кемнәр кагарлар?

Урамбашта кыен, ошбу өем
Кап уртада иде бит элек;
Һай давыллы булды бу замана,
Таралды да тузды ил-милек.

Фани дөнья калыр, яшәлгәннең
Кадерләрен генә бел икән!
Их, күзеңә газиз балаларың
Багып торган мәлдә үл икән!
...Авыл йоклый, гавам, галәм йоклый,
Карчык кына төшкән шом-шиккә;
Шау юаныч биреп мич артында
Сайрый иде ләса чикерткә.
Ник ул тынган?!

*1991*

## ЙОЛДЫЗЛЫ ЙОРТ

Көз туңмаган, кыш тумаган әле,
Байый кояш, дер-дер калтырап;
Барасы җир ерак,
        бер авылда
Тукталдым мин,
                                    кунар йорт сорап.
Капка төбендәге агай-эне
Сузмый гына сүзне артыкка:
«Өе җылы, иркен», — диделәр дә
Төбәделәр ялгыз карчыкка.
...Төпченмичә артык, кемлегемне
Сорашты да
          куйды чәйләрен;
Ияләштек бик тиз, сабыр гына
Сөйләп китте тормыш хәлләрен:
— И-и, зарланамы кеше дөньяга!
Алай ук буш түгел чоланым;
Көндезләрен ару, тик төннәрен
Ялгыз башка авыр, оланым.
Балалармы? Булды... Картым белән
Дөнья кудык без дә ду килеп;
Бишесе биш якта сикергәндә
Тора иде өйләр селкенеп.
Шул инде, шул, югалттым шул
Дүртесен дә узган сугышта...
Төпчегемне...
Анысын — тынычта...
Аһ, хәтәре булмас шуннан да.
Язган иде хатын...
             Ил чигеннән,
Кайтырына ун көн калгачтын...
Кадерле шул бала, — каберен дә
Җир читеннән барып табасың...
Еламыймын тыштан, эчтән генә,

Агып беткән инде күз яшем;
Кирәкми күп нәрсә, яннарыңда
Сөйләшергә булсын бер кешең!

...Черем иттем мин дә чак кына,
Кузгалырга исәп иртәрәк;
Кай арада торган, әби инде
Йөреп ята чәен хәстәрләп.
Хушлашканда теләр теләкләрем
Авыз ачмас элек бүленде,—
Бирде Ходай саулык-гомерне,
Телә, бәбкәм, җиңел үлемне!

...Туктыймын мин азга,
                                        якын кешем
Торып кала кебек шушында;
Җиргә сеңгән бер йорт...
            һәм биш йолдыз
Балкый әнә кәрниз тышында.
Сугышларда һәм дә тынычта
Күңел йолдызларын югалткан
Бу ялгызак Әнкәйләрне безнең
Тормыш бигрәк саран юаткан.

Бар медальләр:
        яу кырында
Калаларны азат иткәнгә,
Дистәләгән бала тапканга,
Коткарганга — суга батканны...
Коелсын медаль — югалтканнарга!
Андыйларны
Өй борынча мөмкин табарга,—
Һәм шуларга җылы кул белән
Кирәк иде дә бит тагарга,—
Коелмаган шул югалтканнарга...

...Көз туңмаган, кыш тумаган иде,
Чыга иде кояш ялтырап;
Кәрнизенә йолдыз кунган йортта
Укылмаган тарих бар сымак.

*1977*

**ТОЛЛАР УРАМЫНДА**

**Гөлҗамалның бер төне**

Яшьләргә куш! — Тавышларын

Бар галәмгә чәчәргә,
Белмиләр күк, карт-корының
Торасы бар сәхәргә.

Вәт азгыннар! Түбән очтан
Булмыйдыр шул үтәргә,
Сынык җаннарның күңелен
Нигә кирәк үртәргә?!

Бәлки, берчак аңларлар да, —
Гармун тартып узарлар;
Моңнарының бер тәме юк, —
Тәмсезләнде дөньялар.

Өй турында туктап, бәлки,
«Гөлҗамал»ны сузарлар;
Җырларының җылысы юк, —
И суынды дөньялар.

Таң атканчы, бәлкем әле,
Тагын бер кат урарлар;
Сылу түгелдер кызлары, —
Картайды ич дөньялар.

...Без балавыз булып калдык
Бал тулышкан кәрәздән;
Ай көлгәндә яшьлегемә
Күз салыймчы тәрәздән...

**Миңсылуның кичке уе**

Байый кояш ындыр артында...
Җитмеш тулыр иде картыма.
...Гарифҗан да күптән
ялгыз да бит,
Сүз тишәргә никтер тартына.

**Гәрчә...**

Илгә төшкән кайгыларны
Күтәрәсең ил белән,
Үзеңә төшкән кайгыны
Күтәрәсең иң белән.

Кырмыскадай, кеше белән
Дөнья тулса да гәрчә,
Култыклап йөри үз кайгың

Бишектән кабергәчә.

**Ник?**

Кое сиртмәсе очына
Менеп кунгач та кояш
Бу көннең зәңгәр төсләрен
Бетерер инде ашап.
(Шуңынчы калыйк яшәп!)

Чыклардай чиста икән лә
Гомерләрнең иртәсе;
Башларың күккә чөелә,—
Хас шул кое сиртмәсе.
(Килми тор гомер киче!)

**Гөлҗамалның каладагы бер иртәсе**

...Каласына килгәнемә бүген
Унике төн булыр таң туса,
Шатлы-ык күле, хәсрәт
дәрьясымы? —
Кайда йөзмә, — гомер ялт уза.

Уза димен дә бит, ят өйләрдә
Яман озын кышның койрыгы;
Улым какмас, иллә төрле чакта
Аларның да төрле кылыгы.

Кухня ябык. Монау татылдыкның
Борыйм әле бераз колагын:
Дөнья йоклаганда шыпырт кына
«Шахта» көен килә тыңлыйсым.

И бүгенге җырлар! — Шушы хрущоф
Йортын тырнап язган тач сырлар...
Исән микән, димен, кыр казлары,
Яшел микән, димен, буш кырлар?..

Шикәр комын санап саткан дәвер
Авыл качып беткәч шәһәргә,
Яшьтиләрдән кемнәр?.. Һи, безнең очтан
Торучы да юктыр сәхәргә.

«Китә-әү...» Тукта, көйләр көйләгәнче
Ипи-тозын чемчим иң башта;
Казлар, бәлкем, очып кайткандыр да,

Кызым калды ерак Донбасста...

Мәликәмнең илләр сүтелгәнче
Сызган хаты тора хәтердә:
«Язга таба исәп кузгалырга...» —
Дип язды күк. И тәкъдирләр диген...
Мөселманча микән кабере?

Ят илләргә юл сабулар ка-ая! —
Үзем беләм, — нинди төстәмен...
Мәчет урап кайтсак... рухына атап...
Алып бара күрсә Рөстәмем.

Шәһәр һавасымы, әллә башкасымы...
Нидән шаулап суга соң чигәм?!
Ут капкандай килеп чыккан килен
Кемгә дәшә: «Позвать Рустика?!»

**Их...**

«Саумы, апа!» — «Әй! Ярыйсы...
Кибеттән кайтып килеш».
Сул кулында — кирпеч ипи,
Уң кулында — бер ярты;
Их,
Өнәмәс иде карты!

Шыр ялгызы торып калды;
Байтак кичте кайгыны...
Их,
Баш күтәрми эчәр идек,
Сүндерәлсә хәсрәтләрне
Хәмерләрнең ялкыны!

Исергәне истә микән
Мич ипие исенә?
Йокысы да — саташудыр...
Их,
Гел төз йөргән Төз Мисбахы
Керә микән төшенә?
Бер тавык та бер әтәче, —
Шушы — уптым мөлкәте!
Әллә гавамга кысылмый —
Ул да таңын кычкырмый.
Их,
Кемнәр безне уятыр?!

**Келәт алдында**

Кырмыскалар чаба, йортын-җирен
Туздырган шул кайсы явыздыр,
Бүрәнәгә башын салган берсе, —
Ул да, бахыр, ялгыз калгандыр.

**Мирас**

Дөнья көтү — көтү көткән кебек,
И чабасың, бетә җегәрең;
...Өй буш, салкын... саклыйм карткаемның
Мич алдында калган түмәрен.

**Зар**

Битләремне терәп кайттым
Картым каб(е)ренә кичә;
Барганда да, кайтканда да
Җиле гел каршы исә.

*

Фәлән елда, диләр, дөнья бетә...
Дөнья бетүләрен кем көтә?
Минем башта әле башка хәсрәт:
Түбә кала — калаеннан су үтә.

*

Көрчеккә килеп терәлдек
Гасыр чатында гына:
Яшәү хакында уйлау юк,
Ашау хакында гына.

*

Нәрсәгә дип өзешәбез
Тамаклар карлыкканчы?!
Бак гөлләргә, баш очыңда
Салкын таш калыкканчы!

**Үпкә**

Хак Тәгалә тигез яратса да,
Бәндәләрен нигә аралый? —
Көн дә чыккан кояш

никтер минем
Тәрәзәмә генә карамый...

*
Юк-бар чиргә күңелеңне кырма!—
Әҗәл дә көлә белә:
Сәгатьләрен санап ятучы да
Йөзләргә җитеп үлә.

**Миңсылуның мунчадагы җыры**

Пенсиягә ыштан алдым,
Тормадым ла хакыннан;
Юлбашчылар туар, бәлки,
Юлбашсызлар артыннан...

*1987—2000*

**АВЫЛГА — ӘБИГӘ ХАТ**

«Безнең хәлләр шулай: сүз чәйнибез,
Бүленешеп «уңнар», «сулларга»;
...Юллар тайгак, кое ерак, газап
Чигәсеңдер чәйлек суларга».

*1989*

* * *
Авылыма кайттым, кичтән әйттем:
«Уятыгыз көтү киткәндә».
Әби-бабай мәрхүм, ихатада
Сукыр сыер да юк икән лә.

*1998*

* * *
Бер авылда бары бер өй калган,
Салкын өйдә — кеше җылысы.
Сөйләп туйгач, көйләп алды әби, —
Туң гасырның соңгы җырчысы.

*1989*

* * *
Эт күтәргән хатын бара,
Өстерәлә арттан сабые,
Кычкырасым килеп китте:
«Син эт кенә, ханым, тап иде!»

## ГАЙБӘТЧЕ АВЫЗЫННАН

Башым кисәргә бирсәм дә,
Телем кисәргә бирмәм! —
Ирексез илдә дә, шөкер,
Гайбәт сөйләргә ирек.

* * *

Әйт, Ходаем, мондый гамәл
Кайсы калыпка сыя:
Бер гөнаһсыз хайван-малны
Гөнаһлы бәндә суя.

## СУКТЫ СӘГАТЬ

*(Соңгы монолог)*

*Сәрбия, Нурия әбиләремнең*
*якты истәлегенә*

Мин бәхетсез бүген!
            Бәхетлеләр
Таңны аягүрә аттыра.
Бу ни галәмәт соң?
            Һаман ятам.
Ә көн туган күптән,
            яктыра.
Күтәргесез тәнем,
            аяк-кулга
Җен-пәриләр герләр такканмы?
Хәерсезең! Әҗәл явыз әллә
Эзли торгач килеп тапканмы?
Әй, кояшым! Назлы нурларыңнан
Мәхрүм итмә, зинһар, бер көнгә!
Якшәмбе бит. Хәлем хәстәрләргә
Кушмаган да идем беркемгә.
Ял ит, бакчаңа бар, дип, улыма
Әйткән булган идем
            инәлеп;
Ник борчырга,
            аягыма бассам,
Йөри идем әле терәлеп.
Ә көне соң бүген! Үтә күренмәле
Бал кәрәзе кебек ялтырый.
Бакча, су буйлары гөр киләдер...
Их, ят инде өши-калтырый.
Бу дөньяның сере! —
            Башкаеңны

Нинди генә хәсрәт басмасын,
Бәндәләрдә бардыр бетмәс
нәфес! —
Мәңге яшәп, мәңге туймассың!
Гөнаһ булыр, аз яшәлде, дисәм,
Биргәненә шөкер итәрлек;
Рәнҗемәсләр безгә,
дөнья йөген
Һичбер уфтанусыз күтәрдек.

Заманалар!..
Яңа тормыш тугач,
Без беренче кердек күмәккә;
Малсыз калдым, соңра ирсез
калдым...
Яңа исем алдым, —
Ирдәүкә.
Икебез дә актив, икебез дә
Таянычы идек Советның;
Хәтәр заман,
үлем яный иде
Һәр минуты саен сәгатьнең...
Шул көннәрдә әнә Мифтахымны
Куып җитте кулак пулясы;
И тартышты...
Кемнең килсен
Әти булыр чакта үләсе...
Малай көткән иде, мәрхүмкәем.
Юраганы, әйе, юш килде:
Туды!
Тик ятимлек, шомлы
шарламадай,
Сабый йөрәгенә ишелде...
Ил күргәнне күрдек.
Улым белән
Ерып чыктык сугыш афәтен.
Армиягә китте.
Кайтты.
Төягендә
Төпләнмәде никтер Әхәтем...
...Егәр беткәч, улым чакыргач,
Ният иттем монда күчәргә;
Ияләшеп булмады ла тәмам,
Кала һәйбәт —
карап китәргә.
Оныкларны буйга бастырганчы
Килен әмерендә яшәдем.

Сөешмәдек,
мәгәр сыештык без,
Сүз озайса — телем тешләдем.
Үземдәдер гаеп. Аңлыйм хәзер,
Кешеләрдән оят, улымнан:
Юллаттым да бүлмә,
башка чыктым,
Юләр димә, үләр алдыннан.
Ни кыласың, ана булсам да мин —
Мыжык карчык алар алдында.
Гел күзеңә торса терәлеп,
Югалтадыр төсен алтын да...
Күңелкәем таза, берсенә-бер
Рәнҗешем юк,
бөртек үпкәм дә;
Оныкларым — наян
койрыкларым! —
Тоткан булсагызмы киткәндә...
Ялгыз башың тыныч яшәсәң дә,
Булмый ялгызлыкка күнегеп...
...Улым да шул
сирәк чыккан кояш
Кебек кенә кала күренеп.
Бар ул күрше-күлән,
кибеттәнме
Кайтып ишегеңне яптисәң,
Алар сине белми, син — аларны...
Телем корыр, мәгәр ят дисәм.

Тик нигә әле бүген берәүсен дә
Адаштырып миңа китерми?
Җан сихәте өстәр бер уртлам чәй
Кипкән иренемә тидерми?!
Килсен дә ул менә керсен иде,
Тормасын да иде шакып та,
Ишек ачык,
бикләнмичә ятам,
Сизгән кебек соңгы вакытта.
...Нинди тавыш? Ә-ә, сә-ә-гать суга,
Суга икән ничә сәгатькә?
Кала бугай, кала әйтер сүзем,
Тик бер сүзем... улым... Әхәткә...
Кояшы да кача, тәнемдәге
Җылым кача,
кача бар көчем.
«Бик сызланган» димәсеннәр иде,
Кипсен иде берүк күз яшем...

*1984*

**БЕРГӘЛӘШЕП КИТӘЛӘР ДӘ...**

Уралтаудан Кафтауларга
Күз күгәрер аралар;
Бергә-бергә китәләр дә
Берәм-сәрәм кайталар, —
Әгәр исән калсалар...

Көньяклардан көн дә хәтәр
Хәбәр китерә җилләр:
Анда адәмнәр ашаучы
Аждаһалар бар, диләр.—
Кафтауда булмас ниләр!

Әйтәләр: кыя кашында
Ут бөркер чәчкә үсә;
Ят куллар кагылды исә,
Яшәр гомерен кисә,—
Сабагын кыеп өзсә...

Сабыйлар ич: уйга кертми
Янасыларын утта;
Исәне кайта — сөйрәлеп,
Көйгәннәре — табутта, —
Булмый йөзен танып та...

Хәсрәт яшьләре әгәр дә
Агымсуга койсалар,
Валлаһи да, ярларына
Сыймас иде дәрьялар, —
Түзә! Түзә Аналар!..

Итек белән изделәр шул
Ата-баба йоласын! —
Бала җирләгән Анасын,
Инде...
Ана җирли баласын, —
Сынган бәгъре парәсен...

Бергәләп киткән егетләр
Берәмләп кайта тора;
...Уты сүнгән өйдә кайгы
Керфек какмый утыра;
Ана укый бәддога...

*2003*

**ЧЫРА ЯНДЫРЫП**

Әйттең, Әнкәм, кич утынга киткәч
Мин сабыйны ялгыз калдырып,
Кайтуыңа — мин юк: «Мич эченнән
Таптым,— дидең,— чыра яндырып».

Бүген сине мин югалттым, Әнкәм,
Кабереңдә киттем калдырып.
Их, табалмам, эзләсәм дә сине
Көндезләрен чыра яндырып.

*14 февраль, 1992*

* * *

И Әнкәем, табутың! —
Сабый чагымда тирбәлгән
Бишегем кадәр генә.
Җаның берлән тәнеңне дә
Өзеп-йолкып өләшкәнне, —
Без ваемсыз балаларың, —
Белдек шул бүген генә.

*1992*

* * *

Әнкәм! Фани дөньялардан
Хәбәрләр бара микән?
Бу ике йорт — яшәү, үлем —
Бик кыска ара икән.

* * *

Нух пәйгамбәр көймәсендә безне
Кайда илтер җилләр-җилкәннәр?
...Кичәгенәк Әнкәм кабереңең
Рәшәткәсен урлап киткәннәр...

**ТӘҮБӘ, ТӘҮБӘ**

Оныгымны сөеп баккан чакта
Күзгә кунган бер ым-ишарә,
Белсәң, Әнкәм, синең шәп-шәрә
Сүзләреңне искә төшертте:

«Берегезгә-бер һич кул якмадым,

Балагызны сез дә какмагыз!
Ни галәмәт, соңра күз яше
Булып кайта сабый рәнҗеше...»

Берни белми онык, алларымда
Көпә-көндез чаба, шәп-шәрә.
...Мин улыма берчак суктым мәллә,
Суктым мәллә?! Салкын гүрдән син,
Син ясыйсың әллә ишарә,
Әнкәм?.. Тәүбә, тәүбә!

*2002*

**СОҢГЫ ХАТ**

Кайтып керер дигән көннәрдә
Кайтардылар... кургаш табутта;
Күз сыярлык кына ачтылар,
Шапылдатып кире яптылар,
Калалмады Ана танып та:
«Яндыңмыни, кошым, тәмугта?!»

...Әллә кичә, әллә күп элек,
Тар маңгайлы үшән бер тиран
Державада итте хакимлек.
Җитәмени корбан җаһилгә! —
Үз җирендә беткәч кыйратып,
Дошман эзләп керде ят илгә.

Куйган Ана табут очына
Малаеның солдат фотосын;
Күлмәк-яулыгының карасын
Кигән дә ул гаҗиз карашын
Теккән аңа: «Кошым, кемнәргә
Ләгънәтләрең укып ятасың?»

...Әллә кичә, әллә бик элек
Керле куллы тиран Җир шарын
Ак-карага куйды бүлеп үк;
Әйтте: «Кара яга зәхмәтләр,
Идеалны кирәк якларга!» —
Озатылды Иван, Әхмәтләр.

Күтәргәннәр кургаш табутны
Икмәк исе сеңгән кулларга,
Табут җиңел, табут авыр да, —
Кайгы баса һәрбер адымда:
«Иртәгә бит тула егермең,

Кая киттең, кошым, кунарга?»
...Әллә кичә, әллә күп элек,
Оеп киткән чакта намазга,
Ят ил өстен узды ут телеп;
Хәрабәдә ята диварлар, —
Тәре үпмәс тиран әмерен
Үтәделәр Әхмәт, Иваннар.

Зират каршындагы чирәмдә
Башлау булды җирләү йоласын,—
Учларына кысып чал башын
Күккә атты Ана бар аһын:
«Тәүбә, тәүбә, теге ят илдә
Калды әллә, кошым, гөнаһың?»

...Әллә кичә, әллә бик элек
Язды Әхмәт соңгы сәлам-хат,
Канга катнаш комга тезләнеп;
Әйтте Иван: «Бетә хезмәтең,
Әйдә бәхәс: син бу хатыңнан
Күпкә элек кайтып җитәсең!»

Кайгыларга шаһит булмыйм, дип,
Качты кояш болыт артына;
Кайтып ятты Ана йортына.
Китерделәр аңа хат кичтән,
Күз салды да язды ул истән:
«Син исәнме, Әнкәм? Мин исән!..
Мин ис-ә-ә-н!»

*1987*

**ТӘКЪДИР**

Тәкъдиреңне белеп булмый, диләр,
Мәрьям әби китәсен бит белгән:
Җомга көнен көтеп җиткермичә,
Ак мунчасын җитештереп кергән;
Ходай нинди җегәр-көч биргәндер, —
Өс-киемен шунда юып, элеп,
Яратканын, чип-чистасын кигән;
Мендәренә башын терәп тормыйча да,
Мичен ягып, чәен куйган, коймак изгән,
Бар нигъмәтен өстәленә тезеп куеп,
Якын-тирә чордашларын чәйгә дәшкән.
И серләшкән алар, чөкердәшкән;
Тик табында шаулап зар акканда
Мәрьям генә гел шаярган, көлгән.

Көтү кайтыр вакыт һәммәсе дә
Аңа саулык теләп таралышкан.
...Тәкъдирен ул тәгаен дә сизгән:
Улы бүләк иткән ап-ак батист
Яулыгына кәфенлеген төргән,
Хәер-садакасын саклап яткан
Бикле сандыгын да ачып куйган;
Җәен тышта куна-төнә йөргән
Песиенә сыек сөт тә салган;
Ни уйлаган? Хәзер белмәссең дә, —
Элмәгән ул ишек келәсен дә;
Инде кермәс төшләр күрә-күрә
Көтү киткәндәрәк җан да биргән...

...Кояш баер, иртәгә дә чыгар,
Дөнья көткән — көтәр беркөе;
Чал болдырга сузылыплар ятып,
Яшен юа ятим песие...

*2000*

**ӘЛЛӘ СЕЗ ӘЙТӘСЕЗ?**

*Рәиф Әмировка*

Узганына бага-бага,
«Уңдым!» ди анда кемнәр?
Әллә сез әйтәсез моны,
Кырыклар, кырык берләр?!

Әткәйләр хаклы сугышта
Ауган чакта камылга,
Беребез яткан биләүдә,
Икенчебез — карында.

Нәсел сабагын Әнкәйләр
Салкын җилдән сакларга
И тырышкан — «Уңдык!» дигән...
Арыш уңган чакларда.

Аһ, бәгырьсез заманалар!
Үстермәде өф итеп;
Бур булмадык, зур булдык без,
Ятимлеккә үч итеп.

Тыштан түгел, эчтән-рухтан
Охшаганбыз имәнгә,
Туры юлда адашсак та,
Тугры калдык иманга.

Әгәр туа калса бүген
«Уңдым!» диярлек көннәр,
Әнкәйләргә баш иегез,
Кырыклар, кырык берләр!
Басыгыз!..

*2001*

**КҮЗ ТИМӘСЕН!**

И сабыем, күгәрченем!
Син тормышның бөтен ямен
Күзләреңә күчергәнсең;
Шат йөзеңдә кайгыларның
Шәүләсе дә күренмәсен!
Берүк кенә күз тимәсен!
Күз тимәсен!

И сылуым, матуркаем!
Килә минем гүзәллеккә
Гомер бакый баш иясем;
Яшьлек-сафлык гел-гел генә
Тапсын ишен, үз иясен!
Берүк кенә күз тимәсен!
Күз тимәсен!

И абыем, апакаем!
Бу дөньяның ваклыклары
Сезне һич тә үртәмәсен;
Тату гомер кичерегез,—
Тере ятим үрчемәсен!
Берүк кенә күз тимәсен!
Күз тимәсен!

И әбием, бабакаем!
Утка керткән, суга салган, —
Мең сынаган сезне заман;
Әҗәлнең дә котын алып,
Йөз яшәгез исән-аман!
Берүк кенә күз тимәсен!
Күз тимәсен!

И Әнкәем, бәгырькәем!
Шул сугышның кара күзе
Йөрәгеңне көйдергәнне
Сизмәдеңме, сизмәдеңме?!
Тол тормышны тының бетеп
Тарта-тарта алҗып аугач

Дөньялыктан өметеңне
Өзмәдеңме, өзмәдеңме?!
И Әнкәем, бәгырькәем!

Көннәр йончу, утың сүрән...
(Каян килгән? Каян килгән?)
Сүрән генә йөзеңдә мин
Якты-якты бер нур күрәм.
Берүк кенә күз тимәсен!
        Күз тимәсен!
Күз тимәсен!

*1982*

**КАРЛАР ЯУГАНДА**

Күрәсеңдер ич! — Күкләрдән Ходай
Кушучлап сибә өмет бөртеген;
И Алма әби! —
Күзеңнән һаман яшь койдырамы
Картайган мичтән бөркелгән төтен?

Җем-җем кар ява, — җилферди җилдә
Зәңгәр каймалы ап-ак ашъяулык;
И Чибәр әби! —
Ятасың, беләм, сызланган килеш
Безләргә теләп гомерлек саулык.

Иркә кар ява, — алчак кунактай
Томса күңелнең түрен балкыта;
И Ерак әби! —
Чеметеп пәрдәң, ник син зиратка
Күз саласың еш соңгы вакытта?!

Чабыша карлар,— сабантуйларда
Узышка чыккан малайлар сыман;
И Кендек әби! —
Шылт тавыш та юк кысыр авылда
Кылып яшисең, әйт, нинди гөман?!

...Ә көн ачылган, ник ачылмаган
Ыңгыр-шыңгырлы кече капкагыз?!
Ак әбиләрем! —
Яшьлек төседәй япь-яшь карларга
Кем кот кундырыр, тормый ятсагыз?!
Ягез!..

*2004*

*** * ***

*...Тор син сакта, Шагыйрь, Җиргә*

*Бәла-каза килгән вакытта;*
*Син табиб та, хәзрәт тә бит*
*Бәндәләрдә хәсрәт бар чакта.*

**ЕГЕРМЕНЧЕ ГАСЫР УЛЛАРЫ**

Махра төреп, тирен сөртер чакта
Җылы буразнага чүгәләп,
Окоп казыды ул штык белән
Тере җирнең тәнен телгәләп, —
Егерменче гасыр уллары.

Сул колагын сузып тыңлады да
Броневикка баскан бабайны
«Юлыбыз хак» дигән оран белән
Камап алды Кышкы сарайны, —
Егерменче гасыр уллары.

Үткен үчен мыегына урап,
Җилде алар, болгап кылычын,
Кан дошманын җиңгәч, җылы каннан
Саркытты ул итек кунычын,—
Егерменче гасыр уллары.

Хакыйкатькә түгел, үзе койган
Таш сыннарга гомер табынды,
Язгы давыл бәреп аударгачтын,
Шул ташларга килеп абынды, —
Егерменче гасыр уллары.

Берлиннарның биек капкасына
Илтеп элгәч Җиңү әләмен,
Үз капкасын кайтып кагалмыйча,
ГУЛАГларда тапты әҗәлен, —
Егерменче гасыр уллары.

Чишеп атып тишек чабатасын
Коргаксыган басу башында,
Күз камашыр корабларны җигеп,
Галәм киңлегенә ашкынды, —
Егерменче гасыр уллары.
Гөл-чәчәкле шушы гүзәл Җирне
Әйләндергәч чүплек башына,
Шакшылыгын читкә түгәр өчен
Башка җисемнәргә йогына,—
Егерменче гасыр уллары.

Аң-акылын җуеп табынса да

Колгадагы кызыл комачка,
Тәхет таптап, бәхет табалмады,
Уялмады ишек оҗмахка, —
Егерменче гасыр уллары.

Чал тарихның соры битләренә
Канга манып язгач исемен,
Богауларын чаңдай чыңгылдатып
Тибеп ачты гасыр ишеген, —
Егерменче гасыр уллары.

*1999*

**КОМПЬЮТЕРДА ЯЗЫЛГАН ШИГЫРЬ**

Әкият бабай шалканыдай
Шома маңгай галимнәр
Безнең гасырның асылын
Компьютерда эзлиләр.

...Әнә кара! —
Ирек мәйданы уртасында
Ирек сөйгән җанны
Дарга асалар.
Әнә кара! —
Һәйкәленә тузан бөртеге
Кунарга өлгермәгән
Хөкемдарның
Корыч башын кыркалар.

Әнә күр! —
Кан-кызыл җиләкле аланда
Кипшенгән солдат сөякләре;
Әнә күр! —
Җиңү урамында һәйкәл-танк
Калкып тора,
Сытылганнарның салкын каны
Чылбырлы аягыннан шабырдап
Агып тора;

Кем? —
«Изм» чукмарын тагып биленә,
Кырык ямаулы иленә
Кабер казытып йөргән исәр?
Ул, —
Җир җирәнгәч куенына алырга,
Мавзолейга кереп ятып,
Йокы симертүче башкисәр;

Әнә берәү!
Ил күгенә корыч коршау кидертеп,
Биләмәсе чикләренә чәнечкеле
Тимерчыбык тарттырган;
Колларының башын идертеп,
Канлы авызларын келәт
Йозагы белән яптырган;
«Иркен сулыш ала кеше
Бары тик безнең илдә» дип,
Галәмне шаккатырган;

Кайда? —
Хокукы юк, — халык бар;
Тынчу һава сулаганга
Налог бар.

...Туң миле компьютерлар,
Йомры башлы галимнәр
Сүнеп барган карт гасырның
Җисемен эзләгәннәр;
Эзли торгач, тапканнар,
Бу хәбәрне җиткерергә
Мәйданнарга чапканнар.

Йа Хода, ни күрсеннәр! —
Иң гакыллы зат саналган
Бөтен адәм балалары
Маймылга әйләнгәннәр...

*1987*

**ТАРИХ ДӘРЕСЛЕГЕ БИТЕНӘ ӨСТӘМӘ**

Тарих битендә
Кап-кара таплар:
Кызыллар, аклар —
Кайсысы хаклар?

Бере яклаган
Иске булмышны.
Берләре — яңа
Тормыш кормышны.

Кызыллар сафы, —
Тоташ каһарман;
Акларга, имеш,
Җитмәгән дәрман.

Сыйнфый бүленеш
Аяусыз икән:
Туган туганны
Кан дошман иткән.

Сугыш кануны
Борыннан кырыс:
Кисешкән алар
Кылычка кылыч.

(Тугры калыйкчы
Һәрдаим хакка:
Бүленмәгән Ат
Кызылга, акка.

Үлем килгәндә
Каһарман иргә,
Башларын терәп,
Яшь койган җиргә.)
Ирек бирелсә,
Нәфрәткә, үчкә —
Явызлык калкып
Чыга шул өскә.

Җиңүче әнә
Гомер бакыйга
Җиңелүчегә
Укый бәддога.

Кызыл яугиргә —
Беткесез кадер.
Акларга тигән —
Әремле кабер.

Нигә тарихтан
Алмыйбыз сабак? —
Кайта вәхшилек
Чир кебек кабат.

Берләр искене,
Берләр яңаны,
Бугаздан алып,
Яклау заманы.

Пакь булсын йөрәк,
Манмагыз төскә!
Явызлык калкып

Чыкмасын өскә.

...Чал тарих бите, —
Кызыллар, аклар...
Кайсысы хаклар?
Әйтсен оныклар!

*1987*

**ЧИТЛЕКТӘГЕ КОШЛАР**

Аһ, Русия! — Тимер империя,
Хас та Кош базары төсендә:
Купкан мәхшәр, төрле-төрле кошлар
Бәргәләнә читлек эчендә.

Татарстан, читлектәге коштан
Бар соң синең нинди аерманң?!
Талпынасың, гәрчә Явыз Иван
Канатыңны күптән каерган.

Бармы кошлар — күккә ашкынмаган?!
Бармы милләт — хөрлек сөймәгән?!
Якты кояш күрер чакта гына
Ябырылган ачкүз тил(е)гән.

Аһ, Русия! Күпме милләтләрнең
Урак белән телен кистең син,
Ә дәү чүкеч белән бабамнарның
Изге кабер ташын киттең син.

Ирек кошы булып Герцен «Чаң»ы*
Кемне чакырган соң хаклыкка?
Төрмә чыңы булып ишетелә
Кремль чаңы күпме халыкка.
Аһ, Русия! — Канлы империя,
Эзлисең син кемгә һәлакәт?
Урыстан да битәр булыр хәтәр,
Кайтармаса татар мәмләкәт.

...Башым чайкап басып торам бүген
Дәверләрнең шомлы чигендә;
Татар, башкорт... Күрәм бүген сезне
Читлектәге кошлар төсендә.

*13 март, 1992*

**ЧАКЫРУ СҮЗЕ**

Шагыйрьләрем, кая постыгыз сез?
Ишетелми тавыш-өнегез,
Албастылар өскә капланганда
Тыныч үтә әллә төнегез?

Күзле сукыр кебек аермый да
Башладыкмы якты төсләрне? —
Ирек сөйде шагыйрь гомер бакый,
Сөймәде ул кара көчләрне.

Уктай сүзләр атып,
Заманында
Пиночетның теттек тетмәсен;
Ил башына залим үрмәләсә,
Шагыйрь башынниләр көтәсен
Күреп тордык ласа;
Виктор Хара
Булмагандыр шуңа безгә чит.
Бүген менә Илем — Ватанымда
Калкып чыкты сигез Пиночет.

Ник салмыйбыз оран беребез дә,
Катыйльләргә бүген ник каршы
Тормыйбыз без!
Бел син: бу бит тутык
Тәгълиматның соңгы тартышы.

Күңелләрне баскан коллык хисе
Кайчан гына икән бер бетәр?
Чилидагы түгел,
Илеңдәге
Башкисәргә, шагыйрь, баш күтәр!

*20 август, 1991*

**БАБАМНАРГА ХИТАПНАМӘ**

Ишетегез, күк катына
Күптән күчкән бабалар!
Эзли торгач, уйлап тапты
Шау «акыллы» бомбалар
Сезнең зирәк балалар.

Сызгырык ук атканнарга
Булсын диеп гыйбрәт,
Ачамын аның асылын, —
Кирәкми кылу гыйбадәт, —
Ул гадидән гыйбарәт.

Бихисап бомба тагалар
Корыч кош канатына,
Аннары аны коялар
Гавам оҗмах корып яткан
Сала вә каласына.

Әйтерсең лә күк тарафтан
Хәзрәти Гайсә иңә:
Күр кояшын! — И Илаһым,
Мәгъриптән чыгып килә,
Куба кисәк зилзилә.

Калтырый җир, ташпулатлар
Үлән кебек ишелә,
Терлек-хайван, бөҗәк-җәнлек
Керә күмер төсенә,
Таулар читкә күченә.

Үз башыңа гөнаһ алып,
Кылмый торчы бәддога!
Ул бомба бит — тач юаш эт,
Тими һич тә бәндәгә —
Ия шундый гыйльләгә.
Монда Сезләр белеп торсын,
Бар тагын сер-әкәмәт:
Ялгыштан шәһит киткәннәр,
Исәптә бар булсалар да,
Санга кертелми, әлбәт.

Адәм белән Хава кебек
Оҗмахтан сөрелгәннәр
Хәленә калган бәндәләр
Инсафлы сүгенгәннәр...
Соңра ни — сүрелгәннәр.

Карансалар — юл шәйләнә
Зур тау мәгарәсенә;
Анда шәмле зат сәламли,
Вай, машалла! Вәт сиңа! —
Күр! — Әбүгалисина!..

*P.S.*
Ике мең дә бер сәнәдән
Сезгә бу шикаятем;
Үзем шул шайкада торгач,
Күрсәтмим исем-атым,
Ам-мерикасын сатыйм!!!

*2001*

**КАЙТКАН КОШЛАР БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ**

«Кайттыгызмы тагын ил-ояга,
Кичеп чүлләр, кочып диңгезләр?
Нишләп әле канат җилпегәндә
Көек исе килә сезләрдән?»

«Җир өстендә ялкын, шәйләү кыен,
Ул үлеме әллә тереме?
Ут-очкыннан канатыбыз көеп,
Күзебезгә тулды сөреме;
Томан булып Җирне кайгы сарган,
Йөрәк җитми ярсып сайрарга...»

«Күкләрдән күп нәрсә күренгәндер,
Сугышлар соң дөрли кайларда?»

«Бәндәгә хас — мәңге бетмәс бәхәс:
Кайсы кавем, кай дин иң өстен? —
Аешалмый шуны кан коеша
Яһүдиләр илә фәләстин».

«Ходай бәндәсенә ни җитми?!»
«Күккә күчәр өчен Җир җитми».

«Канатыгыз талган, кыйтгаларның
Төягәнсез, ахры, аһ-зарын,
Сулышыгыз капмадымы, кыеп
Очкан чакта Кавказ сыртларын?»

«Биек таулар боек күренделәр,
Күз яшедәй ачы кар суы
Үксеп ага-ага үзәннәрдә
Хасил иткән хәсрәт дәрьясы.
Чечен иле Кавказ итәгенә
Җәеп салган канлы намазлык,
Иблис әйтер, күрсә: «Кодрәтемнән
Килмәс минем мондый явызлык!»

«Чеченына тагын ни җитми дә
Урысына анда ни җитми?!»

«Берәүсенә — ярым айлы ирек,
Берәүсенә — майлы җир* җитми».

«Туган җиргә кайтып җиттегез бит,

Аһ-зарыгыз, кошлар, ник бетми?
Сез бит гелән күктә, гел иректә,
Йә, сезләргә тагын ни җитми?!»

«О, кешеләр, безгә күп җитми, —
Җирдә барган зәһәр алышлардан
Караймаган зәңгәр күк җитми!»

*2000*

**ӨЧ СЫКТАУ**

**1**

Терәүле йорт тетрәп авар кебек
Тәрегә баш орган чакта;
«Басурманны җиңеп исән-аман
Кайтсын улым туган якка!» —
Дип сыктый Матрена.

**2**

Намазлыкка чүгеп дисбе тарта,
Инде күпме тарта, кем белсен?!
«Улым, сине утка тыкканнарга
Ходайның каргышлары төшсен!» —
Дип сыктый Миңнегөлсем.

**3**

Биш сабые... сөякләрен
Биш көн эзли хәрабәдә:
«Русиядә яшәгәнче...
Яшәр идем мәгарәдә!» —
Дип сыктый чечен хатын.

**ГРОЗНЫЙ ХӘРАБӘЛӘРЕ ӨСТЕНДӘ ГӘП**

Урам-урам күмер йортлар
Пыскып утыра;
Ике чукрак чечен карты
Кайнар гәп кора.

«Ай-вай, кар мул, диләр, кордаш,
Быел Аргында».
«Әйе, бахыр булып калдык
Кяфер алдында».

«Сугыш посты, ахры, кордаш,
Салкын тауларга?»
«Китте урыс танк менеп

Бүре ауларга».

«Күче белән күсе үрчи,
Үлә сабыйлар».
«Русьны басып алалмастыр,
Ай-вай, Шамилләр».

«Тере микән, ишетелми
Терек шарлавы».
«Ичкер — иксез державаның
Чәнчә бармагы».

«Җәен кабат сугыш җиле
Төшәр үзәнгә».
«Кайчан басар әсир Кавказ
Богау өзәргә?»

«Кафтау...» — ауды гәптәш, нокта
Куймый сүзенә;
Карап катты сукыр пуля
Тишкән күзенә
(Ятим карт).

*1999*

**ДҮРТЕНЧЕ КЫШ**

Сугыш афәтеннән качып, күрше Ингуш
җирендәге кола яланда палаткалар корып
яшәүче чечен картлары һәм яшь балалы
гаиләләр быел дүртенче кышка керәләр.

**1**

Дүртенче кыш килде. Дүрте-енче-е кы-ыш!
Палаткадан корган кышлакка...
Әйтерсең лә менә сөймәс үги улын
Явыз ата салкын почмакка
Бастырган да дүрт ел буе тота;
Белми-күрми, бәлкем, оныткан?!
Чечен Али, татар Апуш кебек,
Яланаяк, әллә оекчан,
Бозлы карга басып катып тора;
Йә, кемнән ул шәфкать көтмәктә?!
Ә тауларда кыя бөркет оча,
Вәхши угы җитмәс биектә...

Әйтегезче, кемнең кодрәтеннән
Яратылган соң бу Һава-Җир?—
Ходай дисәң, нигә бәндәләре
Үз илендә үксез — мөһаҗир?!
Тумыштан ук как Җир аңа — ястык,
Йолдызлардан сырган Күк — юрган;

Бу кышы да үтәр, еллар үтәр,
Үсмер Али китәр кай юлдан?—
Йөзем үстерерме, йорт төзерме,
Әллә безнең уллар-оныкларга
Тар үткелдә мылтык төзәрме ул
Көпшәсенә утлы үч тулган?..

**2**

Үз илендә сугыш ачкан кемсә
Үзенәме, кемгә үч итә?—
Өйдә сабыйлары, ә ул, мәнсез,
Ихатада бүре үрчетә...

**3**

Кавказ сыртын кансыраткан сугыш
Кайтавазы кайда?! «Без — тылда», —
Дип яшиме шагыйрь? — Җир-Күк күзе,—
Кыбырдатмый ласа, аһ, кыл да;
Кичерерме аны иртәгәсе! —

Ул мәдхия яза җылыда...

*2002*

*** * ***

Көн туса — сугыш, үтереш,
Ялган, мәкер, караклык;
Иман белән яшәүчеңә
Сабырлык бир, Ярабби!

Котыпларга качар идем,—
Башаяк бу бәладән;
Үз илемне Ватаным дип
Әйтергә дә гарьләнәм.

*1990*

## КАЯ БАРМЫЙМ...

Кая бармыйм — тимер ишек
Биш-алты кат йозакта;
Хәвефсез илдә яшим дип
«Горурланам» шул чакта.

Кая бармыйм — сайрый кошлар
Читлек читенә кунып;
Ирекле илемдә яшим
Ирекле тоткын булып.

*1990*

* * *

Җилле генә сүзләрең дә
Ник оча җилгә?
Акыллы баш нигә кирәк
Акылсыз илгә!

* * *

*Билгесез солдат кабере янында*

Санамагыз безне диванага,
Хакыйкать бар, беркем тигезсез:
Нинди ил ул, илен яклаган ир
Үз илендә булса билгесез?!

*1979*

**ПРЕЗИДЕНТНЫҢ НОТЫГЫ**

Ил дә — алтын, җир дә — алтын,
Рәсәй халкы эштә алдын;
Җиде диңгез артларыннан,
Алтын биреп, ашлык алдым.

*1990*

* * *

Кем сөйли ул анда, иртә-соңмы
Җиңәчәк, дип, Җирдә хакыйкать;
Зинданда ул. Җиде тимер ишек,
Ишек саен йозак тугыз кат.

**ҖИР ӨСТЕННӘН ҮТЕП БАРГАНДА**

Җир өстеннән үтеп барганда
Калкып чыкты Кояш каршыма,
Сорау аттым аңа кинәттән:
— Син, Кояшым, нинди милләттән?

Кояш, ахры, җавап тапмады, —
Йөзен болыт белән каплады.

Җир өстеннән үтеп барганда
Килеп чыктым хозур болынга,
Ал Чәчәккә төбәп карадым:
— Милләтеңне әйтче, аппагым?

Кызгандымы икән назларын,—
Йомды куйды яшьле таҗларын.

Җир өстеннән үтеп барганда
Башым идем моңсу Анага:
— Җиңеләер, бәлки, хәләтең,
Хәсрәтеңнең әйтче милләтен?

Нидер әйтергә ул омтылды,—
Тамагына төер тыгылды.

Җир өстеннән үтеп барганда
Сытылды бер Бөҗәк табанда.
Җаным өшеп китте ахырда:
— Милләтең кем? — дигән сорауны
Бирә алмый калдым бахырга
Фәкыйрегез — мин бер мосафир —
Җир өстеннән китеп барганда.

*1991*

* * *

Төкерек чәчеп бәхәсләшә
Зыялылар мәҗлесе:
«Кайсы милләт нәҗесе
Дөньяда иң тәмлесе?»
Мәсьәләне хәл итүне
Нигә озак көтәргә?
Галуш кидем, тышка чыктым
Хаҗәтемне үтәргә.
. . . . . . . . . . . . . . . .
Ялган булса бу сүзем,
Шартласын ике күзем:
«Фу-у-у!» — дидем.

* * *

*Чая милләттәшемә*

Тотып булса җилне ятьмәгә,
Булса аңа элмәк кидереп,
Ялган заманнарда турыдан
Ярган өчен күптән асарлар
Иде сине дарга мендереп.

Шул җил кебек чая, ирекле
Ирне күрсәм, — кышын саламын
Горур башымдагы бүрекне.

*1994*

**БЕР КАРАСАҢ...**

*Айдар дус Хәлимгә*

Бер карасаң, җил-давылда
Башын да игән кебек,
Баш игәндә дә горур ул,—
Мәһабәт Имән кебек.

Бер карасаң, тамчы яшь тә
Күрсәтмәс ирләр кебек,
Үләннәргә кырау тисә,
Ятар да үбәр кебек.

Ак көннәрен төн итсәләр,
Теш кысып түзәр кебек,
Башын Себер җибәрсәләр, —
Богаулар өзәр кебек.

Хөрлек сөяр бөркетләргә
Күкләр дә түбән кебек,
Карасаң, карамасаң да,
Күк гөмбәзен терәп торган
Илаһи Имән кебек, —
СИН!

*28 гыйнвар, 1992*

* * *

Хафаланма, дустым, хаксызлыкка,—
Калкансызга кемнәр ук атмас;
Кадер белмәс — кабереңне тапмас,
Мәгәр
Хак сүзеңне халкың онытмас.

*1994*

* * *

Тирләп чыкты мием, җитми уем:
Саташканмы әллә бу заман?
Татар булуың да хәтәр хәзер,
Башкорт булуың да бик яман.

*1992*

* * *

Татар булып туганлыгыңа
Үкенмисеңме кайчак?
Артыңа атландырганың да

Аркаңа кадый пычак.

*1981*

*** * ***

Үрчетү кирәк татарны,
Колбада гына ясап;
Юкса бетереп барабыз
Бер-беребезне ашап.

*1982*

**ЙӨРЕП ЯТА**

Берәү кора, ә ул вата,
Бар гомере — тоташ хата,
Хак бирсәләр — халкын сата,
Көне өчен — денен сата,
Телем өчен — телен сата,
Мөнбәрләргә менеп ята,
Түрдән урын көтеп ята;
Кылмасын дип берәү каза, —
Намуслыга әләк яза,
Белми оят, чикми иза
Арабызда йөреп ята.
Исем-атын атарга да
Җирәндерә.
Кирәк булса, үзең ата.

*1992*

**ЭЗ**

Беленмәс димә
Яла-ялган:
Әнә карда
Кара эзең калган;
Ахры,
Күңел каралыгың,
Тулышып-ташып,
Табаныңа тамган.

*1967*

**МИНЕМ БЕТХОВЕН**

Август киче иде. Бер ханымда
Җыелганда шулай күп кавем,
Тынып калды табын, түргә узып,
Хуҗа булды мәгърур Бетховен.

Аһ, Аллаһу, ялгышкансың бугай,
Ник яраттың милләт илә дин?
Җирдәшләрне бертугандай итә
Ала ласа илаһ Бетховен.

Кай дәвердә кайсы хаким белгән
Сынган күңелләрнең хисабын?
Хөр йөрәкнең өнсез сыкрауларын
Син ишеттең, чукрак Бетховен!

Ач изүең! Җанны җилләтик бер!
Җилкәнле җил тумас бит тагын;
Кара көннәрдә дә гел-гел акка
Табындыра моңың, Бетховен.
Иманнарым камил, бар дөньяны
Күреп белгәнсеңдер, Бетховен,—
Яфрак яра әнә күз алдымда
Авылым очындагы куш каен.

...Син, матурым, сайлап иң матурын,
Бирче ике чәчкә бәйләмең.
Булыр бусы — улым каберенә,
Бусы — сиңа, минем Бетховен!

Мин үткенче генә, син — үлемсез,
Үтенечем әйтсәм, ит кабул! —
Юк, юк, Шопен* түгел, соңгы юлга
Син озатсаң иде, Бетховен!

*2000*

**КАНАТЛЫ ИТТЕҢ БЕЗНЕ**

*Мөфтәдин Гыйләҗевкә*

Өчиледән кайтып барыш
Сугылдым Дүртөйлегә.
Төшләргә кергән кешеләр
Тарта мине бирегә.

Фидаи йөрәкле Бабич
Һәм кайнар хисле Нәҗми
Туфрагы бүген дә милләт
Пәрвәрләрдән өзелми.

Мандолина да тальян*
Уяткан җирдә таңны

Ничек тумый кала алсын
Мөфтәдин — моң солтаны!

...Күрешкәч, исләп куямын
Күңелдә йөргән уйны:
Олы талант буладыр ул
Бәләкәй Тукай буйлы.

Тау-тау комташлар актарып,
Әллә никадәр талкын!—
Меңгә бер генә табылыр
Исне китәрер алтын!

Канатлы хисләрдән тукып,
Күңелгә кордың җилкән:
Үз Әнкәем кебек газиз
Төшеңдә күргән Әнкәң!

Килеп чыкса, төртеп сине,
Исем-атларда узган,
Һич борчылма, кунмый ласа
Алтын өстенә тузан.

Кошлар гына кичә алган
Биектән торып бүген,
Актар әле саекмаган
Моң сандыгыңның төбен!

Агыйделкәй өсләрендә
Моң тирбәлә таң тугач;
Сезнең якта көзләрен дә
Өзеп сайрый сандугач!

*2004*

**КАТЫ БОРЫН ХАКЫНДА ИКЕ ШИГЫРЬ**

**1**

Кара мәте ашап йөргән
Урыс дуңгызының ите
Ник ап-ак төсле икән?
Ак икмәккә ак май ягып
Ашаучы кайбер бәндәләр
Ник кара эчле икән?

**2**

Каты борын баш-аягы белән

Сазга чумып лайла чүмерә;
Сало ашый тәмләп татар хәзер,
Әйтерсең лә сөяк кимерә.

*1989*

## МАЙМЫЛ ЕЛЫНЫҢ СОҢГЫ КӨНЕНДӘГЕ ХӘТӘР ХӘБӘРЛӘРГӘ КҮҢЕЛ АВАЗЫ

**1**

«Көньяк-Көнчыгыш Азиядә җир
тетрәүдән купкан дәһшәтле диңгез
дулкыннары җәннәт илләрендә күңел
ачучы йөзләрчә мең кешене һәлак итте».

*(«Вакыт» программасы)*

Назланганда иркә дулкын кочагында
Бар дөньяның фахише дә фахишәсе,
«Саф тәнемне пычратмагыз!» дип, шашыплар
Елагандыр гүзәл диңгез алиһәсе;

И Илаһым, атма каргыш! Адәмеңә
«Син маймылдан яралмаган!» дип төшендер;
Бу гарасат — гөнаһ җыйган без мәхлукны
Жәлләп, Җиргә тамган бөртек күз яшеңдер...

(...Кичерегез:
Әрвахларга булмас үпкәм, юк ачуым, —
Аһ, беләмен
Якыннарны югалтуның җан ачысын...)

**2**

«Урыс диңгез сәяхәтчеләре Азия
кыйтгасын Сахалиннан аерган
бугазны беренче тапкыр кичкәндә,
шундагы кечкенә утрауларда өер-өер
кыргый этләр күреп, бугазга һәм
утрауларга «татар» исемен такканнар».

*(Россия радиосының
«Сорау — җавап» тапшыруыннан)*

Күкне терәр манаралар күреп,
Карагруһ заттан берәүсе
Әләк сызган Әби патшага:
«Җиргә чүксен, җиткерегез әмер! —
Чиркәүләрне каплый шәүләсе».

«Чыккан кояш батмас державаның
Мин бердәнбер, әйе, хуҗасы!
Күкләр исә — Тәңре биләмәсе,
Ә Хак белән ара бозасы
Килми»,— дигән патшабикәсе.

Аһ, падишаһ! Тууларың хактыр

Мәгърифәтле немка анадан;
Яу чабудан туймас урысны да
«Тудырмадың» нигә яңадан?! —
Күкләр белән коргач әшнәлек...

Ниләр юктыр Ходай әвәләгән
Балчык катыш адәм канында?!
«Татар» ул кырмавык булып килгән
Кыйтгаларны дер селкетеп җилгән
Маңгыт атларының ялында.

Могҗизалар җирдә, һи, бихисап:
Бәлкем, татар эттән яралган? —
Үзе ялый ачы ярасын...
Эт нәселен гомер сүккән «брат»
Мәңге адәм булмас маймылдан
Яралгандыр, бәлкем?!

**3**

«Гыйракның көньяк чүлләрендә
бозлы кар яуган».

*(«Маяк» радиосы хәбәре)*

Ком чүлендә боз, кар ява, бу ни хәл?
Әллә күктә кузгалганмы ихтилал?

Җәт бу хәбәр Бушка барып ирешкән,
Эчләренә боз йөгереп бөрешкән;
Буш, башына киң итәкле эшләпә
Элеп алып, юлга чыккан кичләтә;

Иярләп ул ракетасын, еракка —
Очкан дәрья артындагы Гыйракка;

«Әстәгъ, әстәгъ!» Ком өсләре шау шикәр...
Белми кемгә белдерергә әр-битәр;

Шом уятып, инде күз дә бәйләнә;
Бәй, сул кулда колга шәүлә шәйләнә.

Тар мәгарә мөешендә Бен Ладен
Башлап кына тора ястү намазын;

Күзен чәнчеп, тегеләй карый, болай,
И чамалый: «Техастан килгән ковбой!»

Игезәк чүл бүреседәй икәве
Карашалар бер-берсенә текәлеп;

Тиз ара Буш, дошманын сакалыннан
Тотып, әйтә: «Кимертәм шакалыңнан!

Кем ул чүлдә боз яудыра рөхсәтсез?!

Ярам башың! — минем куәт исәпсез;

Бер океан, җиде диңгез сикереп,
Юккамы без сезгә «ирек китердек»?!

Туктат тиз үк, яудырма боз бүлше! — ди. —
Әтү монда янкиларым өши»,— ди.

Бүлдереп, Бен ләгънәтле сүзен ата:
«Әйт, илне кем тәмуг утына тота?!

Аһ, син мөртәт, аһ, син тәмуг кисәве!
Иманлыга иман кертмәк исәбе;

Төшсен каһәр! Корт илен син тузгыттың,—
Кыямәт көн күр ачысын газапның!

Бирән кебек эчәсең дә җир сутын,
Әҗер итеп, бисмилласыз «Буш боты»н

Таратасың хәләл дип бар тарафка;
Хак, әйләндең дөньябасар каракка.

Ишәккә иш күсәк тоткан Штатың!
Качып йөреп, тузды соңгы ыштаным;

Пычагыма нәҗес каткан «иреге»ң!
Кит, тыкшынма! Шиңдерермен кикригең!

Боз яудыру — Аллаһының боерыгы,
Шартлап катсын баскынчының койрыгы!

Тфү, иблис! Бүлдердең намазымны;
Дога кылам: корт чаксын авызыңны!»

Бу хурлыкка ковбой Жора түзмәде, —
Чепелт күзен көпшә итеп төзәде:

«Тәсбихеңнең тарт та соңгы төймәсен,
Укый башла әҗәлеңнең сүрәсен!..

Мин — жентелмән*, жентелмәннең сүз кыска:
Тиз әзер бул үлемечле орышка!

Ә әрнешеп ятмас өчен ярадан
Атышабыз унбиш ярдлы** арадан».
Бу тәкъдимне бик гадел гамәл күреп,
Аткардылар шартын шартка китереп;

Күр, әзерләр бер-берен ботарларга,
Ботарлагач, чәйнәп тормый йотарга;

Жора тоткан «Томагавк»*, гайрәтле, —
Тугыз башлы туксан дию куәтле;

Бен кулында, гыйбрәт ич, карале,—
Тутык совет «калашнигы» нибары!

Сукыр күрер — тигез түгел көч, әлбәт;
Ташбаш Буш та алды моны тиз шәйләп.

Бен әфьюнын торган арада чәйнәп,
Орды аңа таштан катырак таләп:

«Очкач җаның Күк штаты катына,
Җиткер фәрман баш нәчәлник Раббыңа:

Бөекмен дип, бик ашынып китмәсен,
Кайнар чүлгә салкын бозын түкмәсен!

Ул — ахирәт дигәненә баш түрә,
Ә фание минем хөкемгә керә».

Дәһридән менә шундый яманны
Ишеткәчтен зәңгәр Күк тә каралды;

Автоматын илбасарга каратып,
Әйтте Ладен шулчак, сүзен шартлатып:

«Син — Гитлерның тәмугтан качкан улы! —
Бел, мин — Аллаһның мөэмин бер колы;

Җир әйләнә башласа да кирегә,
Кол бирәлми әмер бөек Тәңрегә.

Хәер, ник дәһригә иман талкырга! —
Бас, шашлык ясыйм синнән мин шакалга!

Ашмас җаның Күккә, ансын көтмә дә,
Җирдә явар ләгънәт сиңа бар телдә;

Хак мөселман олактырган кяфергә
Бозлы кар да бик яраган кәфенгә».

Атты күккә Ладен «Аллаһ әкбәр»ен,

Буш «әп итте» дүрт ботаклы тәресен;

Кояш черем иткән чакта баешта,
Ташландылар галәм тетрәр алышка...

Шаһит булмый калмый язык һәр эштә, —
Шундук Өскә хәбәр өргән фәрештә;

«Бар Ул, бер Ул» инсанына бик нечкә:
Ялт чакырткан яраннарын киңәшкә;

Ниләр булган? — Аңар безнең уй җитми,
Мәгәр хөкем кылынгандыр, һай, җитди!

Жора ракетасын төзәп ятканда,
Бен «калашник» тәтесенә басканда,
Гаярь атлап сөзәк Гарәфә таудан*,
Җиткән төшеп Хозыр Ильяс шул заман;

Укыган да нидер, кырып тамагын,
Бәргән ташка капылт тылсым таягын...

Ни могҗиза! — Әйләнгән Бен сыртланга,
Ә Жора Буш — дүрт сыйраклы маймылга...

Шуннан бирле, сөенечем әйтәем,
Дөнья имин яшәгән, ди, әйкәем!..

*2004—2005*

**ТУКАЙ ТУФРАГЫ**

Бастым, Шагыйрь, җылы эзләреңә,
Куып җиткәч гомер баешы.
Ишетелә микән Итилләргә
Типкәләнгән йөрәк тавышы?

Музейларда күреп бабамнарның
Җаны качкан сука-урагын,
Телләремә терим күз яшеннән
Саркымаган тере туфрагын.

И уйландым каплаганда Җирне
Гасыр кичләренең томаны, —
Томаннарда гел томана туды,
Их, Тукайлар гына тумады...

Әллә хак сүз өзгеч заманнарда
Эскерт төбендәге энәме?

Бәндәләре әллә хөр хәятның
Ертык шәүләләре генәме?..

Тукай бәгырь!
«Баягылар баягыча» түгел,
Уфаларны килеп күр әле! —
Татарымның кычытмаган телен
Кашып ята күпме шүрәле.

Яньчелде дә телем, изелде дә
Уралтауның кырчын ташында.
Кичер, Ходай, мөшрикләр һәрчак
Син дә белмәс җиргә ашкына...

Бастым менә тере туфрагыңа,
Ишелгәндә гомер түшәме.
Тукай бәгырь!
Сәер сорау бирәм, туфрагыңда
Әткәң-әнкәң теле исәнме?

*Апрель, 2004*
*Казан*

**ТАТАРЛЫГЫН ТАРСЫНГАН ТУГАНГА**

«Бу заманда Тукайсыз да
Яшәп була» дисәгез,—
Әткәң-әнкәң каберенә
Ялган яшьләр түкмәгез!

Көне өчен денен саткан
Хаинне акласагыз,—
Катыйль балтасын сагайткан
Җәлилне ятламагыз!

Күшеккән талны кочаклап,
Җылы тын өрмәсәгез,—
Туфанның ачы әрнешле
Йөрәген бәйләмәгез!

Кем илаһи моң каршында
Яшь түгүдән тарсына, —
Сарылмасын ул Сәйдәшнең
Шәрыкле сагышына!

Әгәр Илһам аһәңенең
Бәһасен белмәсәгез, —
Җанга пәрәвез үрәчәк
Моңсыз киләчәгегез.

Гавамның хәсрәт күлендә

Колачлап йөзмәсәгез,—
Алтын тулы авыз белән
«Халкым» дип сөйләмәгез!

...«Татарлыкның хакын хаклап
Яшәде» димәсәгез,—
Берүк каберем туфрагына
Тамчы яшь тә түкмәгез!..

*2004*

**ШАГЫЙРЬ ЯШЕ**

Сабый чакның күз яшьләре ачы,—
Апуш белән бергә үскәнгәдер;

Шат яшьлекнең күз яшьләре ширбәт, —
Сөйгәнеңне качып үпкәндәдер;

Җирнең битен көйдерердәй кайнар, —
Әнкәң каберенә чүккәндәдер;

Гүре дөрләр кебек, — яшьләреңне
Балаң туфрагына түккәндәдер;

Җанны бозга катырырдай салкын, —
Мең хәерсез картлык килгәндәдер;

Шагыйрь яше җылы, — Тукай яшәп
Калганлыгын күреп үлгәнгәдер...

*2004*

**ТОТАШТЫР**

*Татар хакын хаклап йөргәндә*
*егылып үлгән Йосыф ага Гәрәй*
*истәлегенә*

«Арабыздан китте ул», — дип
Сөйләү, бәлкем, ялгыштыр.
Китмәү, бәлкем, шагыйрьләргә
Килә торган язмыштыр.

Төренсә дә күз яшьләре
Кайгы төсе — карага,
Тереләрдән тере булып
Яшисең син арада.

Халкыңның хаклы аһ-зарын,
Аһ, авыр кичердең син,
Үзең белеп тордың ласа

Йөрәгең киселәсен.

Ә язмышың каһарманга
Төшә торган язмыштыр;
Син исәнсең, исәннәрне
Киткәннәргә тоташтыр,
Тоташтыр!

*9 апрель, 1994*

*** * ***

Кибетләрдә сатыла ялтыр портретлар:
«Нихәл!» диеп күз кысалар президентлар
(Берәү түгел, икәү. Хаклары бер),—
Һай туклар!
...Нигә искә төшә әле балачаклар,
Нигә төшкә керде әле кичәгенәк
Ындыр арты, учак, ябык үлән,
Ач атлар?!
Ә без туклар! —
Авызларда шарт-шорт килә —
көлдә
Кыздырылган симез борчаклар...

*2003*

*** * ***

Җирдә — сулар, күктә болыт ага тора,
Хөкемдарлар килә тора, китә тора;
Сөрмәсеннәр дип курыккан һәрбер түрә
Һәрберсенең портретын сөртеп тора
Шуңа күрә.

**МЕТАМОРФОЗАЛАР**

**1**

Ак мәчетнең манарасын
Ошбу бәндә кискән элек,
Хак мөселман сурәтендә
Намаз укый бүген килеп,
Тәһарәтсез килеш,
Тәһарәтсез килеш...

**2**

Чик законнары каты:
Русиядән Израильгә
Алтын-алмаз кыстырып
Чыкмакчы була кайсы.

Ябык кына яһүди көлә-
Көлә пеләшендә кашына:
— Баш сөягемне ачып, алтындай
Гакылымны алып калырга
Берсенең дә килми башына...

*1991*

**СӘЕР ТҮГЕЛ**

Чибәр йөзен күрсәтми,
Чаршау артына поса;
Ә яшь ана, ят күз булса,
Тизрәк баласын коча.

Комнан вак алтын бөртеге
Сибелгән ком чүленә;
Ә гәүһәрләр, асылташлар —
Тирән диңгез төбендә.

Талант та әнә шундый:
Күзгә бәрелеп торырга
Һичкайчан да ашыкмый.
Үзе бер сәнгатьтер ул
Аны күрү, белү, тану.
Миңа һич тә сәер түгел
Талантларны таба алган
Талантларга табыну.

*1973*

**НИНДИ СЕР БАР...**

Нинди сер бар моңнарда?
Кайдан ала ул көчне?
Каф тавындагы кеше дә
Иң якын туган төсле.

Ядрәләр тишә йөрәкне,
Ә җырлар һаман тынмый.
Ауганда да җырлаганны
Бар дөнья басып тыңлый.

**БӘХӘСНЕҢ АЗАГЫ**

*Яшь каләмдәшкә*

Укы әле шигыреңне,

Зарыңны сөйләп торма.
Тормышыңны син тәүдән үк
Уңайга-җайга корма.

Дөньяны җылытыр хисләр
Тар бүлмәгә дә сыя;
Сарай кебек йортларда да
Саргайган уйлар туа.

*1981*

* * *

Борын заман шагыйрьләрнең хакы
Шактый кыйммәт торган мәгәр:
Мәдхиясе хаким мәртәбәсен
Тәңрегә тиң итсә әгәр, —
Алтын-мәрҗән тутырганнар
Авызына сыйган кадәр.

Очсызланды шактый шагыйрь халкы
(Заман башка, башка такса):
«Күрмәдек без акыл Сиңа чаклы,
Һәйкәлләргә сының шиксез хаклы!» —
Дип дан җырлар,
    бер-бер хаким
Авызына ипи сонып,
Күкрәгенә калай такса...

*2002*

* * *

*Наҗар ага Нәҗмигә*

Җирнең тәмен арттырырга
Мөмкиндер дә ул ашлап,
Шигырь тәмен кем арттырыр,
Наҗарлар китсә ташлап?!

*1998*

* * *

Картайды шул шагыйрь:
Күрмәс булды күзе,
Бөкрәеп бетте үзе,
(Хикмәте бардыр Ходайның)
Туры калды сүзе.

*1993*

* * *

Сыңар медаль дә юк, к чуртым!

*Әнгам Атнабаев*

Тукайны күреп төшемдә
Тетрәндем: бу ни хәл! —
Калтырап торган түшендә
Ялтырап тора медаль.

*1994*

* * *

Ата махра көйрәтә,
Ана бишек тирбәтә:
«Күз яшьсез дә елый белә:
Шагыйрь булыр бу бала».

*1979*

* * *

Биек тауда әнә «бөек затлар»
Шигырь чемчеп йөри бер көтү,
Үзәннәргә коеп төшерер идем,—
Көчтән килми тауны селкетү.

*1990*

* * *

Бакырларын алтын-көмеш дип
Исәпләүче бахыр күбәйде.
Олимп тауга уңган шагыйрьләр
Катлам-катлам шигъри чүп өйде.

* * *

Нигә күшәр хайван көн вә төн?
Күшәмәсә үләр, имеш тә;
Бөекләрне чәйни чүбекләр,
Тап булгандай татлы җимешкә.

* * *

Бөекләрне хәйран калдырырлык
Егәрлек бар бүген һәркемдә:
Дәрдмәнд гомер буе язганны
Язып ташлыйбыз без бер көндә.

* * *
Ике әдип нидер бүләлмичә
Сөзешәләр ярсып-талып,
Китаплары тора киштәләрдә,
Бер-берсенә башын салып.

* * *
Ябык шагыйрь дә симерде:
Данның майлы өйрәсен,
Кашыклап түгел, чүмечләп
Чөмергәнгә, күрәсең.

* * *
Робагый дип әтмәлләүче,
Белмим, малай, үрчи каян?
Бер яртыңа тормый алар, —
Тыныч йокла, аек Хәйям!

* * *
Хатыннар корсакка калса, —
Гыйфрит булса да туар;
Шагыйрьләр корсак кабартса, —
Гибрид шигырьләр туар.

* * *
*Гөлләргә генә җырлыймын:*
*«Сүнмәдем ич сулып та...»*
*Күр!*
*Өздереп сайрый сандугач*
*Сынган талга кунып та.*

**УКЫРСЫҢМЫ МИНЕМ ШИГЫРЕМНЕ?**

Укырсыңмы шушы шигыремне,
Үсеп җиткәч, акыл-аң алгач!..
Мин сөендем, улым, бик сөендем,
«Әттә» диеп телең ачылгач.

Туган кеше — үрмә гөл төсле ул,
Ялт үрмәли үргә, биеккә;
Өлгерерсең бер шук малай булып,
Өлгермәбез күреп-белеп тә.

Кергәләрсең, беләм, син урамнан
Авыз-борыныңны канатып.

Арт сабагың укытырмын, яме,
Йомшак каеш белән яратып.

Тукмалулар була, тукмаулар да...
Малай чакта мин дә тукмалдым,
«Әткәйгә әйтсәм...» диеп,
калай әтәчләрне
Өркетергә күпме укталдым,
Укталдым да
Телем тешләп калдым,
Көлке икәнлеген аңладым:
Үз гомеремдә бит мин бер тапкыр да
«Әткәй» диеп дәшә алмадым.

Мин бишектә чакта явыз фашист
Әтиемнең гомерен сүндергән,
Тел очымда торган сүземне дә
Шул үтергән, шул, ш-у-ул үтергән...
Якын булган, ахры, бишегем белән
Әтиләрнең окоп арасы,—
Мин сугышка шаһит, — калган әнә
Тәндә — исе, канда — ярасы.

Сызланулар арта, тик кимеми
Сөенүем имин тормышка;
Минем буын мәңге калсын иде
Соңгы шаһит булып сугышка.

Киләчәгең юрап тормыйм, улым,
Шуны гына килә әйтәсем:
Кыз-улларың синең «әттә» диеп
Күзләреңә карап әйтәлсен!

*Август, 1983*

**КҮҢЕЛ КҮНЕГЕР БУЛСА...**

Йөрәгемне ярыр идем, —
Кайгым түгелер булса.
Әгәр, улым, үлемеңә
Күңел күнегер булса
Каһәрләр идем үземне,
Бир, Ходаем, түземлек!

Минут эчендә сүндердең
Бөтен яктыларымны,
Иделләрнең чоңгылына
Күмдең шатлыкларымны.

Бу дөньяда яшәсәм дә,
Ай-кояшны танымам;
Галәмгә сыймас җылымны
Суырдың шул җанымнан.

Ак Иделгә карасам да,
Йөзкәйләрем карала;
Ходай, башка бәндәләрне
Бу кайгыдан арала!

*Август, 1998*

**НИ ГАЛӘМӘТ?!**

Сүрелер, бәлки, ялкыным,
Салкын җилләр иссәләр;
Һушларны ала икән шул, —
Хушлашмыйча китсәләр.

Төн буена төньяклардан
Бөркү җилләр исәләр;
Баскан җирдә үләр идем, —
«Ул бит исән!» дисәләр.

Чишмәләрдән су эчәмен,
Чишмә суы да кайнар;
Кеше хәлен аңладым мин, —
Минем хәлне кем аңлар?!

Күкләрдән җиргә каплана
Җан өшеткеч тавышлар:
Ни галәмәт?! — кышлар өчен
Төньякка оча кошлар.

*** * ***

Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте...

*Хәсән Туфан*

Сикерәдер бу йөрәгем
Кырлы да үрле,
Җеп өзәрдәй хәлләрем юк
Иртәдән бирле.
Күзләремнең яшь койганын
Дусларым күрде, —
Нишләптер елый алмыймын
Шул көннән бирле...

*** * ***

Сулар да сипкән идем бит, —

Бүлмәңдә гөлләр сулган;
Өстәлеңдә биш кат тузан, —
Туганымдай ул тузан.

Сулар да сипкән идем бит, —
Ул гөлләр соң ник сулган?
Сүндерегез Ай-учакны! —
Дөрләрмен күк бер куздан...

Өстәлдәге тузаннарны сөртмим
инде;
Гөлләргә дә сулар сипмим инде...
* * *
Базарларда җыр яңгырый,
Моңы бит таныш кебек:
...Кайларгадыр кемнәр белән
Китепләр барыш кебек.

Юл чатында кәрлә үлән,
Уңмаган арыш кебек;
Тәрәздән өргән җил биткә,
Сибелгән сагыш кебек.

Күлнең зәп-зәңгәр күзләрен
Оеткан җылы томан;
Улымның сап-сау башларын
Иңбашларымда тоям.

Бер гөнаһсыз бәндәләргә
Сарылмыйдыр ич каргыш?!
Шатлык — төссез, кайгы — төпсез, —
Аралары бер карыш.

Машинада моң яңгырый
Йөрәкне өтеп алгыч;
Шартлар идең — күрәчәгең
Алдыңа килсә ялгыш.

Елак моңнар тирбәлгәндә,
Егылып кала арыш;
Бу — улымның үләсенә
Ашкынып кайтып барыш...

* * *
И бу салкын бураннар,
Бергә узган урамнар
Килә дә төшә искә:

Кибет алды... һәм саилче.
Тукталдык ошбу төшкә.

Кипшеп беткән бу мескенне
Ничек урап үтәсең?!
Әйтә улым: «Хәер бирим,
Әти, мине күтәрсең».

...Җирләдек сине җәйләрен,
И эссе кояш иде;
Зиратта өләшкән хәер
Үзе зур колач иде...

...Базардан кайтам буранда,
Саилче бөтен тирәм;
Күшеккән кулдан хәерне
Синең исемнән бирәм,
Улым...

**КИЧКЕ АВЫЛ ЙОРТЫНДА**

И син, бәндә, тәүдә: «Бу дөньяның
Кендеге — мин!» — диеп яшисең,
Син хөрмәттә, кайгы-хәсрәтең юк,
Ходай белән хәтта әшнәсең.

...Яшьни яшен, күкри күк капылт,
Салкын яңгыр зират өстендә;
Кем ул шакый ишек, ахирәттән
Качып кайткан әрвах төсендә?

Кич авышкан, ә мин өйдә ялгыз,
Тамчы тавыш хәтта куркыныч;
Кисәр идем башын шул яшеннең,
Кулларымда булса ут-кылыч.

Күк күкрәген ут-чыбыркы белән
Телгәләгән яшен шикелле,
Кара кайгы ач бүредәй кинәт
Аяз йөрәгемә сикерде...

Карлыкты да бераз, күк тә тынды,
Чыбыркысы сынды яшеннең;
Гаҗәп менә, һич кызыгын тапмыйм
«Мин бәхетле!» диеп яшәүнең.

Ә күк һаман салкын яшен түгә,

Кыйгач яңгыр зират өстендә;
...Шыңшый-шыңшый бер эт ишек тырный.
Ул... ул...
Гүргә кергән улым түсендә.

* * *

Сырхау булсаң, гөл дә үсми,
Үләр елыңда корый;
Кайгыларга бер тарысаң,
Урый да сине урый.

Күңел комдай коргаксыган, —
Гөлләргә ничек багыйм?!
Карасам, кайгыртырмын күк
Иң яратканын — агын...

* * *

Туксан яшьлек әби ята,
Үлем көтеп ята һаман;
Килен-улның тәкатьләре
Корып беткән инде тәмам.

Күрше йорттан бер егетне
Унҗидедә сулар алды,
Башка сыймас бу кайгыдан
Ата-ана гаҗиз калды.

Бу ни хикмәт? — әҗәлләрен
Берәү көтә, берәү көтми;
О, Тәңрем!
Җуй гакылны! — Синең хөкем
Аңнарыма барып җитми.

* * *

Кайгысыз кеше бар микән
Дөнья йөзкәйләрендә?!
И бәхетле идем бит мин
Быелгы җәйләремдә.

Кайгысыз кешегә төртеп,
Их, күрсәтсәгез иде!
Бер хәсрәтсез яшәрләргә,
Их, өйрәтсәгез иде!..

* * *

Кояш Җиргә һаман карый алмый,
Ә мин карый алмыйм көзгегә;
Һич курыкмый идем, куркам, улым,
Тап булырмын диеп йөзеңә...

* * *
Төнге күк җиргә елышкан, —
Йолдызлар баш түбәмдә,
Мөмкиндер көләч йөзлесен
Үрелепләр үпсәң дә.

Үрелепләр коча алсам,
Кушам синең исемне;
...Ә йолдыз җиргә капланган. —
Өнемме бу, төшемме?..

* * *
Ихатада эт өере, —
Әйтерсең ач бүреләр;
Сынган үлән төсле ята
Шарт киселгән гомерләр.

Баскан, яткан җирләрем дә
Салкын таш булыр кебек;
Берәр заман бу дөньяга
Этләр баш булыр кебек.

**АНА СҮЗЕ**

Уйламадым түгелер дип
Учымдагы бодаем;
Алыр булгач, нигә генә
Бирдең икән, Ходаем?!

* * *
Юл өстендә үлгән кош ята;
Алма сата әби шул чатта;
Тукта, тукта!Ниләр генә уйлап
Шигырь язам соң мин бу хакта?

Кош — ка-ап-кара, алма — ап-ак;
Мин табындым гелән шау акка;
Алыр идем алма, үлгән кошны
Мин күрмәс тә идем ул чакта.

Көннәр елак, төннәр йончу чакта
Тора идең, улым, син сакта...
Ниләр генә уйлап, нигә генә
Шигырь язам соң мин бу хакта?!

Юл өстендә үлгән кош ята;
Алма...

*Август — сентябрь, 1998*

*** * ***

Мөгезләрен төби-төби,
Котырган үгез кеби,
И чаба бу машиналар,
Ярсыган диңгез кеби.

Җәяүлеләр генә белә
Яшәүнең бәрәкәтен;
Ә тизлекләр тизләтәдер
Бәндәнең һәлакәтен.

Мин юл бирәм, оч әйдә!..

*** * ***

Сагышларым! —
Хас та инде утлы күмер;
Җаннарымда җөй калдырып,
Эчләремне гел яндырып
Торган сагыш — минем гомер.
Бер көйрәр дә сүнәр күмер, —
Шулдыр инде — кыска гомер.

**КАЛА...**

И гомерләр — сүнгән күмерләр,
Инде сине кемнәр кадерләр?

*Улымның кабер ташындагы язу*

Үргә менеп җитмәсәң дә,
Ятасың әнә үрдә;
Ничек кенә анда хәлләр,
Салкын түгелме гүрдә?

Яткан җирләрең и матур,
Күз очыңда — Кызкала*;
Шул тауга без күтәрелдек,
Син ул чак — сабый бала.

Уң кулыңда — кара сулы

Агыйдел һаман ага.
Нигә генә Әнкәң синең
Суга каһәрле бага?

Сул ягыңда — кулың сузсаң —
Терәлеп тора урам;
Баш очыңда ябь-яшь каен, —
Күшексәң, яфрак уран.

Без китәбез, син каласың,
Ямансулама берүк,
Калдырамын йөрәгемне,
Кулъяулыгыма төреп.

*1999*

**УФА — КАЗАН ЮЛЫНДА**

Әнә генә урман. Мал көтүе.
Янында ат. Ята көтүче.
Төшеп сорыйм мәллә, бу якларда
Бармы исememне белүче?

Әле җәйнең нәни генә чагы:
Берчә көлә, берчә җылыйдыр;
Шушы тайның бабасымы типте? —
Аягымда эзе җылыдыр.

Ник бирәүгә гомер аз бирелә,
Ник бирәүнең китә озынга?
Калкытырмы башын, әгәр төшеп
Яшем койсам яшел уҗымга.

Ә мин исән әле, Казаннарга барам,
Анда күтә исән дусларым.
Элеккечә тиктомалдан көлеп,
Булмас инде алып һушларын.

Рәхмәт, Кояш! Озатасың мине
Артларымнан тотам һич калмый.
...Мин картайдым кинәт, бик картайдым,
Кайгым гына никтер картаймый...

**КИЧЕР, АГА**

*Хәсән ага Туфанны 80 яше белән*
*котлап җибәрелгән хат-шигырь*

Үзәгенә алган сине
Бу гасыр өермәсе;
Күр әнә, сының-йөзең

Чал тарих күчермәсе.

Төрлечә була торгандыр
Картлыкның кылануы,
Әмма синең сызлануың
Ул — дәвер сызлануы.

Син бәхетле,
          сыйган сиңа
Дөньяның бар булмышы;
Ләкин «ләкин»сез буламы
Олуг шагыйрь язмышы?

Исемеңне, шигыреңне
Ишетсәм дә куанам;
Син бар чакта
          шагыйрь булып
Йөрергә дә оялам.

Тыйнаклыкны читкә тибеп,
Яздым шушы такмакны;
Бөекләрнең күңеле киң,—
Кичер, ага, ахмакны!

*1980*

**ЯШӘРСЕҢ!**

*Якташым, яшьтәшем һәм дустым*
*Илфак Смаковның якты истәлегенә*

Заманалар авыр булды,
Еллары төрле булды,
Каршыга исте җил-давыл,—
Күлмәкләр керле булды.

Күлмәкләр керле булса да,
Күңелләр чиста иде,
Бикләнеп яткан чакта да
Күзебез тышта иде.

Агымсуны туктатсак та,
Булмый моңны туктатып.
Үз сагышын үзе буган,—
Юктыр бит андый халык?!

Тышта бүген яңгыр ява,
Бар табигать яшәрсен;
Яшел яфрак яшь койганда
Син дә, дустым, яшәрсең!
Яшәрсең!

*28 май, 1993*

**НИГӘ СИН ТҮГЕЛ?!**

*Дустым Ренат Хәйринең*
*якты истәлегенә*

Киткәннәрдән, дустым, беренчесе
Һәм соңгысы, әйе, син түгел.
Көпә-көндез ташлап киткәннәргә
Күнә алмас мәңге бу күңел.

Бу дөньяда яшәү — күз ачып күз
Йомган ара,— әйе, бер мизгел.
Исәннәргә авыр. Киткәннәрдән
Ник соңгысы икән син түгел?!

*1990*

**ҖАНЫҢ КҮБӘЛӘК БУЛСА ДА...**

*Нажар ага Нәҗми вафатына*

Гасыр таңын тоташтырып
Гасырның баешына,
Төшенә алдыңмы, Шагыйрь,
Бу дөнья агышына?

Өләштең син бәндәләргә
Ак җаныңны бүлгәләп;
Җаның күбәләк булса да,
Дөнья түгел түгәрәк.

Заман калды, калды еллар...
Ник Ходай сине алды?!
...Имән аугач, таллар иңрәп
Башларын суга салды.

*6 сентябрь, 1999*

**ЕЛАМАГЫЗ**

*Әнгам ага Атнабаев рухына*

Ил өстендә бергә гел бүлешеп
Яшәсәк тә ярты кабымны,
Гүргә кадәр күрмәдем лә мәгәр
Күзеңә яшь кунган чагыңны.

Кунак булып утырдыңмы әллә
Фани дөньяларның түрендә?!
Янып яши Кеше, Шагыйрь исә —
Калганчыга кадәр күмергә.

Кушлап-кушлап кайгы өйде заман

Сыңар учка сыяр йөрәккә;
Ачы хисләр ташып түгелсә дә,
Юкка түгел алар — кирәккә.

Шагыйрьләрнең зары — коры дары,
Хаксызлыкка чәчәп, гөлт итәр;
Сутлы шигырь коргаксыган күңел
Бакчаларын хәйран гөл итәр.

И Шагыйрем!
Йөрәк сүзең Синең берчә наян,
Берчә чәнечкеле гөл төсле.
(Гөлчәчәккә күмелеп ник ятасың? —
Баш очыңда Әнкәң — көл төсле.)

Гүргә кадәр күрмәдем лә мәгәр
Күзеңнән яшь тамган чагыңны.
Мин дә бүген яшьләремне тыеп,
Учларыма кыстым җанымны...
Еламагыз сез дә!..

*13 октябрь, 1999*

## ӘЙТЕП КИТӘСЕМ КИЛӘ

*Әмирхан ага Еникигә*
*юбилеенда әйткән сүз*

Кайтып төшсәм, туган җирдә
Торып каласым килә,
Алтын чуклы хатирәләр
Аргамак сыман җилә.

Тауларга карап тын гына
Еласыларым килә,
Агымсуларны кирегә
Борасыларым килә.

Карт йөрәкнең теләкләрен
Каеннарым да белә:
Аркамны терәп утырсам,
Шифалы суын бүлә.

Канатлар кайда өзелер? —
Аны бер Ходай белә.
Әйтелмәгән васыятем
Әйтеп китәсем килә.

*10 октябрь, 1994*

## ӨЗЕЛГӘН ЧӘЧКӘ

О-о, болында күпме чәчкә!
Дөньяда яшәргә була икән әле...

*Филия ханымның*
*җиләклектә әйткән сүзе*

Дустым, никтер шушы сүзең
Килә дә төшә искә.
Кояшлы хозур болында,
Әйе, күп иде чәчкә.

Яшәргә була дөньяда,
Өметләр өзелмәсә,
Кайгылар капкаң төбендә
Чиратка тезелмәсә.

Чәчкә кебек чакларында
Өзелде йөрәк парәң.
Телгәли көн-төн җаныңны
Мәңге бөтәшмәс яраң.

Килә дә баса алдыңа
Балаңның тере сыны:
Чәчкәләр булып болында
Тирбәлә җылы тыны.

Өзгәләнсә дә йөрәгең,
Түзәсең икән түзсәң,
Тик күз яшең тыялмыйсың,
Өзелгән чәчкә күрсәң.

Гафу ит, чәчкәсез генә
Каршылармын син килсәң:
Шул җәйдән бирле мин чәчкә
Өзәргә куркам,
белсәң.

*1990*

**КИНО КАРЫЙ ВЕТЕРАН**

Как диванга сиенып утырган:
Кино карый бер карт ветеран.

Бомба шартлый, мина сызгыра, —
Карт йөрәкне кабат сындыра.

Ә оныгы янда тәтелди:
«Әнә фашист ата, картәти».

Бер почмакка посып утырган
Оныгына дәшә ветеран:

«Кил яныма, анда кыен,— ди,—
Курыкма син, миңа сыен»,— ди.

Диктор сүзе яңгырый тагын да:

«...Безнең частьлар Бреслау янында...»

Ачы итеп мина шартлады,
Һәм ветеран күзен каплады...

Якты дөнья әнә шул көндә
Әйләнгән бит аңа шау төнгә...

Кино беткән, тавыш басылган,
Карт оныкның сыйпый башыннан:

«Җиңү паркын иртүк җәяүләп
Карап кайтырбыз без икәүләп».

Куанычтан малай баш кага,
Сукыр күздән тере яшь ага...

*1975*

**МАЛАЙ, ШАР ҺӘМ УЗГЫНЧЫ**

Гадәти бер җәйге көн иде;
Әллә кайдан атылып
килеп чыккан малай,
Миңа шарын сузып:
— Мәле, абый, тотып тол,— диде.
Үзе,
Нидер кырыр эшем ияседәй,
Яшь үләнгә җәелеп утырды.
Шук малайның кайдан җитсен
вакыты, —
Кабалана-ашыга
Ботинкасын каптырды.

Вәт җебегән! Күр инде! —
Кулдагы шар күккә күтәрелеп бара;
Ә малаем,
Шардай күз яшьләре белән,
Урам яңгыратып оран сала:
— Әтинеке!
Әти кителгән иде...
— Ә син кер дә тагын сора!
— Ул китте инде...
Ул икенче җилдә тола.
— Үзем алып бирәм алайса.
— Юк, әтинеке...
— Мороженый да алам, кирәксә.
— Юк, әтинеке...

Шушы сакау
тере ятимгә

Сүз дә тапма инде әйтергә!
Туктар, бәлки, мин дә еласам,
Тамчы яшем чыкмый, ичмасам...

*1972*

**ТРАГИКОМЕДИЯ**

Кичәгенәк ишеген
Тимердән корды күршем,
...Үтереп сызлый тешем...

(Кылган эше бик дөрес, —
Талыйлар көпә-көндез.)

Утыз җиденче елда
Килгәннәр дә әтисен
Алганнар икән кулга
(Барысы беткәч ятып,
Такта ишекне шакып).

...Кибет ишеге кебек
Килә ишек шак та шок.
...Тешкә түзәр әмәл юк,
Юу-ук...

Әтиләре ерактан
Җитә алмаган кайтып:
Туң җирдә калган ятып...

...Сакла, Ходай, угрыдан!
Күршем тыныч — ишеге
Бикләнә биш урыннан.

...Килә ишек шак та шок.
Кайда соң теш даруым! —
Эчәр идем бер кашык.

Күршем бит — керер кешем.
Сызланып ничек ятыйм!
Тук! Тук! Тук! Әйтерсең лә
Төрмә ишеген шакыйм...

*1994*

**КАБЕР КАЗУЧЫ**

Казый иде җырлый-җырлый,
Бүген казый җылый-җылый.

Акса да яшь күзен тырнап,
Кулда көрәк тора уйнап.

Аптырарлык түгел һич тә:

Шушы эштә — ике дистә;

Казыганын чыксаң барлап,
Рәхмәт укыр мең-мең әрвах.

Хәер, күптер ләгънәте дә, —
Бәндәләрнең ләгатенә

Сыймасны да чутсыз кылды, —
Иссә хәтер — кысар тынны.

Тап булырмын дип «алтын»га, —
Җитте, азгын, биш хатынга;

Биш хатыннан — алты сабый,
Алтысын да чит-ят саный;

Балалары бер хәл әле
(Булды ярдәм кылган мәле),—

Үз әнкәсен читкә типте...
Ә ул —
Кичәгенәк үлеп китте...

...Белми
булыр диеп язык, —
Мышный бүген кабер казып.
(Булышырга кемгә кушсын, —
Дошман күрде күршен-дустын.)

...Арып, күккә күз терәде:
«Күккә дәме юк кирәге?!»

Ялтлап яшен, күк күкрәде,
Ап-ак дөнья күм-күгәрде;

Утлы уктан сынды көрәк,
Тар кабергә башын терәп
Ауды өрәк...

*1998*

*** * ***

Бөдрәләре тузган башны
Кырт чабып өзгәч, җәллад
Канлы түмәргә утырып
Күз яшен сыкты җәлләп.

## ПӘҺЛЕВАН ЕГЕТ ИДЕ

Әфган дигән илләргә
Сугышка китте теләп,
Кандагар үзәнендә
Аттылар аңа төбәп.

Кайтып җитте иленә,
Ярты санын өстерәп,
Тәне инде тән түгел,—
Теткәләнгән чүпрәк.

...Карап тора урамга,
Тәрәзәгә тотынып,
Сызланудан ничек тә
Булмас инде котылып?!

Аста Агыйдел таша,
Зиярат — урам аша;
Барып кына ятар иде,
Казылган кабер булса!..

Көлмәген иңгә элде,
Сыңар балагын киде,
Иң бәреп ишек ачты,
Таш ярга барып басты...

...Очты...
Иңендәге ак күлмәк
Пар канат кебек иде;
Кыз сөяргә өлгермәгән
Пәһлеван егет иде.

*1989*

## ТОЯК ТАВЫШЫ

**1**

Тын далада тояк тавышы;
Чайпыла күк, чыңлый йолдызлар.
Әйтерсең ут үртәп уздылар
Сүнгән учагына яшь чакның:
Гомер мизгелләре гөлт итте
Гүргә кереп барган карчыкның.

...Ачык тәрәз. Чиллә. Буш дала.
Карак куркып йөрер кара төн.
Шундый төндә сөйгән егетен

Көтә сылу. Көтә өзелеп;
Күңел кайный, йөрәк ашкына,
Шартлап сынар кебек түземлек.

Төн гөлләре тәрәз төбендә
Нәни күзен ача ашыгып;
Кыз егеткә чыга ябышып...
Как даладан әнә дөп тә дөп
Очып килә тояк тавышы,
Җанны баскан шомны өркетеп.

Шып тукталып, кызны тәрәздән
Суыра да ала Буранбай;
(Күреп кала бары көнчел Ай
Җиргә караш аткан арада.)
Һәм кырт борып ярсу тулпарын
Җилә кабат кайнар далага.

Гөлбикәсен илә төн гөлен
Өзә егет туган туфрактан;
Очып кала очкын тояктан.
Күк чайкала, йолдыз түгелә,
Бу җылы төн гасыр-дәверләр
Дәвам итәр төсле күренә...
**2**

...Тояк тавышлары басылгач,
Бәргәләнеп озак ул ятты,—
Хәтер җебен карчык чуалтты;
Бөртек өметләрен он иткән
Заманнарны соң оныткanмы,
Заманмы соң аны оныткан?!

Онытмаган. Әнә даланың
Сулышына салып колагын,
Янә сүтә хәтер йомгагын.
...Их, яшьлектә кылма исәрлек! —
Үкенечләр өя икән ул
Үлем түшәгеңә җитәрлек.

Әйе, бозып борын йоланы,
Киңәш кылмыйча да беркемгә,
Фатихасыз чыкты бит иргә.
(Ил башына менгәч коммуннар,
Манаралар кебек киселде
Бабалардан калган кануннар.)

Шул ук Кояш, шул ук Ай бакты,
Төн гөлләре чәчәк атмады;

Ә Гөлбикә... бала тапмады!
Кемгә рәнҗеш? Кемгә каргышың? —
Куеладыр алдан язылып
Тәкъдир тактасына язмышың.

Ходай бирмеш, шунсы сөенеч:
Башкайларны башка терәшеп,
Пар күгәрчен кебек гөрләшеп,
Төгәл ун ел яшәп калынды;
Купты соңра җирдә сугышлар, —
Берсе сүнгәч, берсе кабынды.
Калдырды да янып сөйгәне
Ялгызына хәсрәт тау чаклы,
Финнәргәме — кемгә? — яу чапты;
Ай күрде лә, Кояш шул алды! —
Буранбае кулын болгый-болгый
Бураннарга кереп югалды...

Салкын кышлар үтте. Яз җитте.
Кайтты кошлар. Ә ул... кайтмады.
Күңел күген болыт каплады;
Көтеп-көтеп, өмет качса да, —
Күз яшенә күпме манчылмасын, —
Яңартмады түшәк башкача.

Даланыңмы утлы җилендә
Канатлары көйгән аккошка
Охшап калды яши торышка;
Татый алмый тамчы шатлык та,
Кетәк кебек йортта, ахырда,
Аяк басты сырхау картлыкка.

Кайчакларда ачы әрнештән
Кычкырасы килә далага:
Зарга тулганда да замана
Гөлгә бак та — гөлдәй бала сөй!
Дәвамың да синең, дәваң да
Бирәү генә икән — нарасый!

**3**

...Чал йолдызлар баеп барганда
Әйләнеп тә карчык тулганып
Ята, бахыр, һаман уйланып:
Ай-Кояшы сүнгәч, өши-өши
Дөньялыкта кеше ник яши?! —
Тик төн өнсез, телсез, ул дәшми.
Чү!

Җил-яңгырдан башка сугылмас
Тәрәзәне анда кем шакый?
(Белгән догаларын ул укый.)
Күзенәме әллә күренә? —
Карачкыдай котсыз бер шәүлә
Төннең чоңгылына күмелә.

Каргышларга баткан карт гасыр
Качып бара шулай шым гына;
Сүнеп ята карчык тын гына...
Тукталганмы вакыт агышы? —
Шом капланган шәрә далада
Яңгырамый тояк тавышы...

*1989—1990*

**АТНЫҢ СОҢГЫ ТАҢЫ**

Җилгә чәчәп эт өрә,
Ачы буран котыра;
Буш утлыкка башын терәп,
Абзарда ат пошкыра.

...Юеш төтен йота-йота
Тергезә дә учагын,
Сүрән учак яктысында
Хуҗа кайрый пычагын.

Мәхлук бүген бер йотымлык
Печәнгә дә тилмерә,
Гаҗизлектән аранының
Агачларын кимерә.

...Хуҗа, колагын уятып,
Буранны тыңлап тора;
Тәмәкесен көлгә атып,
Чәй артына утыра.

Кырыс хуҗа гомердә бер
Сыланды аңа кичтән;
Сыйлады татлы сүз белән,
Салмады сутлы печән.

...Чәен бүлеп, тагын кайрый,
Кайрый үткер пычагын;
Алтмыш кышын кышлап, кышның
Күрмәде мондый чагын.

Төннектән күз тегә малкай:
Уянмаган ихата,
Тәртәләрен күккә атып,
Кашавай йоклап ята.
...«Кансыз Кәшиф» дисәләр дә,
Ул да бит әле кеше:
Кап-кайнар пычак йөзендә
Киселә кайнар яше.

Туй-төшемнәр булыр калса,
«Тимер ат»лар табылыр...
Тояклары белән тояу —
Бусы соңгы таңыдыр.

...Җил басылган, көн ачылган,
Мич кузы сүнеп беткән;
Бисмилла әйтеп, зур эшне
Аткарыр вакыт җиткән.

Шыгыр-шыгыр тавышлардан
Өркеп качты ябык Ай;
Тәртәләрен җиргә бәреп,
Җансыз калды кашавай...

**СӨЯК ТАРТМА**

Күргәнегез бар сезнең:
Тап Уфа уртасында
Утыра борыс йортлар,
Бар усак мунчасы да.

(Хәзер ни — заман башка,
Әйләнә кала ташка;
Йортлар җиргә тезләнеп,
Күккә үсә кат-катка.)

Зифа әби шул йортта
Зур дәвер гомер кичте,
Тузган өй почмагыннан
Җил булып кайгы исте.

Алалмады ул көтеп
Сугышка киткән ирен,
Малае үсеп җиткәч...
Кояш яктыртсын гүрен!

Ач та, тук та булмады,

Тапкан белән көн итте,
Замананың зарына... —
Барына да күнекте.

Карты корган карт йортка
Күнеккән иде бик тә,
Күршесе дә пакь кеше, —
Ишек булмады биктә.

...Менә бүген карчыкны
Көзге юеш суыкта,
Иске-москысын төяп,
Күчерделәр таш йортка...
Әллә хан заманыннан
Калган шул искеләрен
Җайлаштыра башлагач
Җуйды капылт исләрен:

Ике кат күзлек элеп,
Кая гына бакмасын,
Төенчекләр эчендә
Күрми сөяк тартмасын.

Сөяк тартма — шкатулка...
Кечкенә дә — төс кенә,
Югалыр да югалтыр
Әйбер түгел һич кенә!

Сыйган анда кичергән
Гомеренең бар заты, —
Балдак, чулпы, өч фото,
Картының соңгы хаты...

Китте Зифа, җан көчен
Агач таякка терәп,
Сөяк тартма эзләргә,
Карт сөяген өстерәп.

. . . . . . . . . . . . . . . .
Йорт әле «тере» иде.
Йортка «ясин чыгачак»
Егет тә йөри иде
Бульдозер — тимер үгез
Янында ава-түнә.
Шым гына үтте карчык
Абына да сөртенә.

...Күк иренеп яшь сыга,
Эңгер-меңгер төшкән чак;
«Тап тартмаңны!» дигәндәй,
Эндәшә күк һәр почмак.

«Әнә кайда икән ул!» —
Яшергән тишек нигез.
Бух! —
Стенага мөгезен
Батырды тимер үгез...

*1993*

**ШӘМСИ КОЕСЫ**

**1**

Киткәненә инде кырык ел
Тулган җәйдә, ялга чыгып, ул
Кайтып төште туган авылга;
Каршылады этләр абалап,
Өен тапты чак-чак чамалап.
Туган йорты тора аварга.

Хатлар аша гына күрешкән
Әни исән, әмма бетешкән,
Күзе күрмәс, аера тавыштан.
Улы кайту аңа зур бәйрәм:
«Ясар идем дә бит шәп әйрән,
Аяк-куллар, улым, корышкан.
Суга ераклаштык иллә дә,
Күрше кое кибә челләдә;
Кем тазартыр, төпкә кем төшәр?!
Карт-корылар күптән хафада.
Ир-ат кулы кирәк кайда да,
Алар — кырда. Уттай эш өсте».

Чәй ясалды, әйрән эчелде.
«Сөйләп җибәр, балам, хәлеңне,
Ни гамәлләр йөргән җиреңдә?»

«Дөньяны күп, әнкәй, гизелде,
Будык башта алкын Иделне,
Аннан ачы Себер җилендә
Ангараны алдык киртәләп. —
Табигатькә бездән күп таләп.
Соңра Иртышның, борып юлын,
Бозлы суын чүлгә ташларга
Иде исәп — бәла башларга,—

Туктаттылар. Пенсиядә улың.
Күңел тартты туган җирләргә,
Китәр вакыт җиткәч гүрләргә...
Һай, шәп булды, әнкәй, әйрәнең».
Сөйләмәде Шәмси калганын,—
Ялгызлыгын... медаль алганын...
Эчендә дә калсын бәндәнең!

«Ил-курада булмас ни хикмәт!
Хата кылмас, балам, хөкүмәт.
Агымсуны гына тик менә
Тышауларга, димен, ник инде?!
Зиһен җитмәс заман-көн килде:
Төшә алмас беркем төбенә».

**2**

Аркан җайлап, чыгыр кордылар,
Ике карчык тартып тордылар
Ләм-балчыгын, черек бурасын;
Шәмси салкын кое төбендә
Язалмады сырхау билен дә,
Онытты ул дәрман-чамасын.

Чыгып басу белән кояшка
Ис җыялмый торды ул башта, —
Беткән бахыр тәмам күшегеп.
Әби-сәби әйтте рәхмәтен:
«Күр дөньяның, балам, рәхәтен!»
Бара иде бу чак көн сүнеп...

**3**

Коеда су иртән, чын мәгәр,
Күк йөзе күк зәңгәр, зәп-зәңгәр.
Тик Шәмсине генә чир тотып
Алды, каһәр. Буа сулышын.
Күреп яту кыен шунысын, —
Әни карчык йөри ут йотып...

Тукталган мәл иде күлемгә...
Киртә корып булмый үлемгә.
Сүнде Шәмси, китте бер өнсез,
Туган йортта гомер киселде;
Ана никтер җиңел кичерде:
«Аһ, ялгышты әҗәл, түземсез!»

Иртәле-кич кече-олысы

Суга килсә: «Шәмси коесы!» —
Дип хөрмәтләр булды кешене.
«И Аллаһым, күпме ялвардым,
Ишеткәнсең икән, баламның
Мир өстендә затлы исеме...»

*1986*

**БАСКЫЧЛАР**

...Кайчандыр таза бу ир
Кайчандыр назлы ярын
Көн туса «вата» иде,
Баскычтан сөйрәп чыгарып,
Урамга ата иде.

...Инде чыгара хатын
Җайланма арбасында
«Түмәр»гә калган ирен
Ихата арасына.

Кызганалар күршеләр:
«И бичара бәндә! — дип, —
Кадер белсәң, чын бәхет
Сау-сәламәт тәндә»,— дип.

Мин кызганмыйм, байтактан
Белгәнгә бу кешене,
Кеше дип атау хәтта
Вата таза тешемне.

...Көнләшкәнме, фәләнме? —
Ансы миңа караңгы.
Тик хатынның күз яшеннән
Ак болытлар каралды.

«Ташла да кит!» — дип үгет
Бирүчеләргә әйткән:
«Бер ир белән тору да
Бер гомергә бик җиткән!»

Ә ирен бердәнбер көн
Юлда фаҗига көткән...
Исән калган. Кискәннәр
Ике аягын төптән.
Больницада баш очында
Туксан тәүлек үткәреп,
Алып кайткан ирен өйгә,
Җилкәсенә күтәреп...

...Көчтек без. Күченгәннәр

Алар да шушы йортка.
Күргәчтен аһлар иттем, —
Кырык та юк — чын кортка.

Таныпмы, танымыймы,
Беркөн миңа сүз катты:
«Булыш, кардәш! Ашатыр
Вакыт җитте бу атны!..»

Лифтсыз йорт. Мендек, мендек...
Чак ислимен ахырын;
Балланып әйтте «түмәр»гә:
«Талмадыңмы, бахырым?!»

*1990*

**ЯШЬЛЕК БЕЛӘН ОЧРАШУ**

«...Менә кереп, күреп китим, дидем,
Ураү юлны аз-маз турайтып».
«Безме? Шөкер, Гарифҗаным белән
Яшәмәдек җаннар карайтып».

«Исләре бик таныш, ахры, озын
Гомерледер синең бу гөлләр?!»
«Берсе үлсә, берсе үсә тора...
Балалармы? Себер киттеләр...»

«Минем хәлме? Ак башымнан хатын
Караларын эзли... Биреште».
«Әйе, әйе!.. Улың яшьли оҗмах
Кошы булган дип тә ишеттем...»

«Ашыйм, ашыйм. Тәмле! Картайгачтын
Өйрәнәсең ризык танырга».
«Пенсиямме? Артып кала... манный
Боткадан соң тешсез авызга...»

«Күреп уздым: мәчетегез күркәм!
Басучылар күптер намазга?!»
«Һи, бездәме?! Урам тулы сәрхуш,
Пәрдә тартам көндез тәрәзгә...»

«Ач килеш тә җырлап үскәннәрнең
Тазалыкка бераз зары бар...»
«Җегәремме? Кош-корт тотам һаман...

Кайтыштырып тора оныклар».

«Өең майдай, уты, суы кергән,
Ә болары монда ник ята?»
«Бумы: тышта дым сеңә дип керттем,
Бу өч такта украт... табутка».

«Тәнгә җылы кунды. Мин кузгалыйм.
Тәмле булды чәең, коймак та...»
«Шулай тизме?! Юк, юк, хушлашмыйбыз! —
Күрешербез әле оҗмахта...»

*2004*

**ХАЛЫК АРТИСТКАСЫНЫҢ СОҢГЫ РОЛЕ**

*Кызым Резедага*

Пәрдә төште. Сүнде гөр алкышлар...
Утырып ул көзге каршына
Кайтты кабат чын үз төсенә:
Йөзен тирән сырлар сарган карчык
Карап тора яшьле күзенә...

Йә, хушыгыз, былбыл Асылъярлар,
Ак калфаклы Галиябанулар,
Нафталинлы кофта исләре...
Сәхнәләргә сеңеп калды микән
Мең-мең баскан аяк эзләре?!

...Ә иртәгә күрше Гайни белән
Базарларны урый башларлар,
Карый-карый сөт тә ит хакын;
Көн авышкач, ирен күреп килер...
Татар зиратында... бик якын.

Әле тын урамнан атлый, сүзсез
Бер Узгынчы ролен башкарып;
Хас — ялгыз каз, җуйган бәбкәсен...
Нигә атмый чүпкә тынчу кичтә
Төсе качкан соңгы чәчкәсен?!

Килеп җиткәч йорты каршысына,
Пәрдә төшкән җансыз тәрәзгә
Күз атарга курка карашлар;
...Тәтемәде бәхет: аягүрә
Үләлмәде залда алкышлар
Күкрәгәндә...

*2004*

**КӨПӘ-КӨНДЕЗ**

Кылынды бүген Җирдә
Галәмне тетрәтер гөнаһ,
Кылынды көпә-көндез...
Күреп тордың ла, Кояш! —
Сукмадың нигә башына
Яшенле кулың белән?!
Раз
Явызлыкка син битараф,—
Сипмә нурың безнең өскә,
Сүн, Кояш!

Талгын Җил таңнан торып,
Үләннәрнең чыклы битен
Суырып үпкән бер мәлдә
Кылынды ласа гөнаһ;
Аһ,
Ваемсыз икәнсең, Җил!—
Тупылның кипшек кулын,
Каерып алып, бәрмәдең ник
Бәдбәхетнең битенә?!
Раз
Син вәхшилеккә битараф, —
Каплан да җиргә, үл син!
Исмә, Җил!

Ә Җир соң?! Синме соң ул
Хак бизмәне — Җир-ана?!
Син йөреттең кабахәтне
Күтәреп үз өстеңдә,
Ник чөймәдең, чыгымчы
Аргамактай, бушлыкка!
Раз
Син кансызлыкка битараф,—
Гизмә Күкләр гөмбәзендә,
Туктал, Җир!
Әйе, көпә-көндезен —
Сабыйга сусап яшәгән
Чәчкә атмас хатыннар,
Тәрәзләргә сарылып,
Күкләрдән өмет көткәндә
Кылынды адәмчелекләрне
Һич тетрәндермәгән гөнаһ:
Җиде тәмуг кисәвенә
Әверелгән хатын кисәге,
Нәни күзләрен ачып,
Ак дөньяда нибарысы

Өч сәгать гомер кичергән,
(Ертык биләүгә төрелгән),
Наныен — җан иясен —
Чүплеккә томырып китте...

Сүнде Кояш, тукталды Җир,
Кипкән үлән кочагында
Җан бирде Җил...

*2005*

**УЛ**

**1**

...Озын гомер адәмиләр
Бер коедан су эчкәннәр;
Баксаң бүген,
Бер-беренә
Дошман булып беткәннәр...

Ул килде:
*Бура өстенә җанын терәп,*
*Чүгәләде;*
*Ярлыкаумы сорап,*
*Күзен Күккә текте;*
*Аккан ачы яшен*
*Кушучына түкте*
*һәм*
*Кое күзенә сипте, —*
*Суын тәмсез итте...*

**2**

...Ялгыздан-ялгыз калып,
Эче-тышы тузып,
Көн сүнгәндә
Шәрә ихатада
Карт, үлән өстенә ятып,
Җан бирде карт.
Михнәттәшләре җирләде...

Ул күрде:
*Ятим кабер күкрәгендә*
*Алма кадәрле таш та юк;*
*Тәүдән,*
*Якын таудан ертып алып,*
*Баш очына ак таш куйды;*
*Шадра битен тырнап*
*Ташның,*
*Язгы үлән озынлыгы*

*Уйды бер аять:*
*«Сызланудан азат бу җан,*
*Ниһаять!..»*

**3**

...Мәргән аучы атып алды
Кыелып очкан кыр үрдәген
Иртә таңда бишәүне...

Ул белде:
*Куш көбәктә*
*Игез үлем үрчегәнен;*
*Бөек Бушлык төбе*
*Җансыз калганлыгын;*
*Шаулы урманнарның*
*Өне өркеп качканлыгын;*
*Күл кашында*
*Буй җиткергән камышларның*
*Сыгылып елаганын;*
*Көзнең — көләч язга,*
*Язның моңсу көзгә*
*Әверелгәнен;*
*Йодрык түшкә сөягенең*
*Ач тамакка кадалганын.*
*Һәм —*
*Канатлылар болытларга*
*Кунып очсын өчен;*
*Җирдә-күктә*
*Аман калсын өчен —*
*Кече туганнарга*
*Кеше туганнарына*
*Йогар чир бирде...*

**4**

...Шәмседдин Суфый Зәки*,
Илһам тамар дип, бәлки,
Кояш күтәрелгәч,
Шәм яндырып куйды
Шигырь валчыклары өстенә...

Ул керде.
(Диде:)
*— Нидән Суфый балкыш баккач*
*Ут тергезеп утыра?!*
*Җан түрендә сүнде мәллә*
*Илаһ сипкән яктылык?!*

— Җир өсләрен тома булып
Каплап ятты шакшылык;
Шәйләми акны күзләрем, —
Сарды дөнья карасы.

*— Өч көнлекне Мәңгелеккә*
*Тиңләр Адәм баласы;*
*Кичмәк булыр сиратны да,*
*Какмый гөнаһ тузанын.*

— Гавам таптап чыкты тәмам
Изгелекнең ызанын;
Иман сатып, әсир төште
Нәфес ташкан Иблискә.

*— Бәндә Җирдә хур тоткындыр, —*
*Күз терәмәсә Күккә;*
*Күләгәсен сагнып елар,*
*Илаһ шәмен сүндерсә.*

— Яктыда шәм яндырсам да,
Күрмим: кай юлда инсан?!

*— Сукыр шагыйрь күрмәс булгач,*
*Күзле сукырга ни сан!..*

*2005*

**АВЫЛ ӨМӘСЕ ХАКЫНДА ХИКӘЯТ**

*(Өзек)*

**1**

Бәйрәм бүген илдә.
Бәйрәм бүген
Йөз дә кырык йортлы Килемдә.
Җиңү көне! —
Охшап тора авыл
Купшы күлмәк кигән киленгә.
Күк чалт аяз. Болыт баласы да
Куркыр бүген борын төртергә;
Керфекләргә әгәр тамчы кунса,
Ашыкмагыз аны сөртергә.
Күзләреңнән яшьләр акканда да
Гаеп итмәс сине һичбер кем:
Кайгылардан ятып үкси торган,
Юктан гына җырлый торган көн
Бүген.

...Әнә Азат, башын күккә терәп,
Оча-калка кайта клубтан.
Берлиннарны алган күкрәгендә
Орден-медальләрен балкыткан.
Яшьлегенә кабат кайтканмыни! —
Биш атлыйсы җирне бер атлый;
Эчмәгән дә үзе, шул килеш тә
Үзе белгән җырны кабатлый.
Әрләмәсен тәрәздәге күзләр,
Кыланмый бит солдат артыгын,
Ашыга ул җәһәт кенә кайтып
Сөендерим диеп карчыгын.
...Чү!
Кем ул анда,
капка төбендә,
Кара күлмәк кигән килештән
Майның шундый җылы иртәсендә
Көзге чәчәк кебек бөрешкән?
Азат якын килде:
— Кем дисәм,
Бу синмени әле, Сәлимә?!
Хәлләреңне белү кирәк тә бит,
Керү авыр синең хәлеңә.
Исән-аманлыкмы? Күзгә-башка
Күренмисең әле бу ара.
Менә карт солдатны,
зурдан кубып,
Олылады бүген идарә.
...Калтыранган кулы белән Азат
Чишкән мәлдә токтан төргәген,
Телгә килде карчык:
— Түзәр әмәл
Беткән чакларда да түзәмен.
Күренергә... Шул йорт арасында...
Йөрер чаклар узган биләмдә;
Җылы җәйне көтәм.
Тернәкләнәм
Аяк бассам яшел чирәмгә.
Чыктым әле менә,
исән чакта
Исәннәргә килә карыйсым...
И дөнья диң!
Әгәр шул тәмугтан
Янмый чыккан булса Фаризым,
Ул да бүген,
тач та синең төсле,
Биш басасы җиргә бер басып,

Кайтыр иде дә бит...
Их, язмыштан
Кала алган инде кем качып?! —
«Ярдәмең бир, зинһар!» дигән төсле
Тынды карчык җиргә күз терәп,
Тик җир өнсез калды,
дәһшәт кичкән
Солдат кына куйды тетерәп.
— Ә мин исән!
Сүз ялгады Азат. —
Бетмәгәндер ашар ризыклар...
Кырык бердә утка кергәннәрдән
Аз чыкты шул безнең гадуклар...—
Әйтер сүзен җиргә төшергәндәй,
Җиргә бакты шулчак Азат та;
Ә ул өнсез, җиде катлы җир дә
Тарыгандыр, ахры, газапка...

— Ник торабыз?!
Кемнәр кушкан безгә
Иртә таңнан урам сакларга,—
Басты карчык тотына-тотына
Үзе кебек авыш капкага. —
Әйдә, өйгә узыйк. Чәем әзер,
Коймак тугыладым әчегә;
Бәйрәм җитте исә, әллә нигә
Тансыкланам кунак кешегә...

Азат кулындагы төргәгенә,
Аннан Сәлимәгә карана,
Гаепле бер төстә әйтә: —
Һич тә
Санламый бит бу дип үйлама;
Күренимче кайтып,
карчык өйдә
Көтә булыр күптән дүрт күзләп.
Суытмый тор чәең. Урарбыз без
Гөлҗамалым белән икәүләп...

**2**

...Кайтып килә Азат. Эче-тышы
Кайнар уйлар белән туп-тулы;
Дәрт-дәрманы кая качкан аның? —
Адымнары арык бу юлы.
Ни булды соң? Бәй, ни авылдашы
Сәлимәне күрде, шул булды:
Кайнар уйлар кайнар йөрәгенә
Салкын ташкын сыман ургылды.
Җанын-тәнен өткән бу хисләрнең

Белә булыр нидән икәнен;
Ул үткәнгә ялгый бүгенгесен,
Бүгенгегә төйни үткәнен.

...Их, яшь чаклар!
            Зәңгәр ут-учаклар! —
Кайчан яныП, кайчан сүнделәр?!
Дус-яшьтәшләр —
        Азат белән Фариз —
Ике гүзәл кызны сөйделәр.
«Яратам!» — дип, бөтен мир өстендә
Йөрмәделәр алар шаулап та,
Күз карашы аша аңлаштылар
Берчак Сәлимәдә, аулакта.
Бүгенгедәй көләч май аенда
Ике пар бер көнне кавышты...
...Бу — 41 иде. Кара болыт
Ал кояшка таба шуышты.
«Сугыш!» сүзе илнең күкрәгенә
Утлы сөңге булып кадалды;
Шомырт чәчкәседәй ап-ак дөнья
Шау сөремгә батты, каралды.
Кара тәре кара песи булып
Кисте юлын күпме язмышның;
...Җәй өсте. Башаклары тулышып
Килгән чагы иде арышның.
Арыштан да, җылы караштан да
Җан дусларны сугыш аерды.
Берсен — сулга, берсен — уңга,
                    әмма
Икесен дә утка каерды.
Йөз узаман чыгып китте шулай
Йөз дә кырык йортлы Килемнән.
Торып калды туган һәм туачак
Сабыйлары белән киленнәр.
Әнә Азат та бит «малай туды!»
Дигән хәбәр алган вакытта,
Чигенүнең чикләренә җитеп,
Ята иде салкын окопта.
Авыл-калаларны калдырса да,
Калды анты тулы көчендә:
Ул дошманны ярсып тукмаячак
Яңа туган улы өчен дә.
Куркак заттан түгел иде Азат,
Баш имәде пуля каршында;
Ут эчендә булды сигез йөз көн,
Ә коймәде хәтта кашы да.

Чаяларга пуля тими, диләр,
Бәхетлеләр өчен бу хактыр;
Биш минутлык канлы алышта да
Ава ала солдат йөз тапкыр.
Кем ышаныр хәзер?! Ул чак Азат
Җиңел генә яра теләде.
Ни галәмәт! — Колак итен тешләп
Китәрлек тә ярчык тимәде.
Ут эчендә сигез йөз көн йөреп
Төгәл булгангамы дүрт саны, —
Бөтәшмәгән иске яра кебек,
Сызлап куя кайчак сау җаны.
Нинди исәр уй ул, нигә әле
Ул охшата үзен кайчакта
Фаризларның яшәр гомерләрен
Урлап алып кайткан каракка.
Аман кайткан кордашларын кара, —
Исәпкә бар да бит, санга юк;
Сәгать саен сирәгәя сафлар,
Кичтән исән берсе — таңга юк.
Йөз узаман чыгып киткән иде
Йөз дә кырык йортлы авылдан,
Күпме башка кайгы ябырылган! —
Җитмеш исем ташка уелган.
Сәлимәсен окоп төпләрендә
Уйлап гаҗиз булган Фариз да,
Агыйделе тыныч аксын өчен,
Башын салган Десна ярында...
Һай, аяусыз шул ул сугыш,
аңа
Әшнә була алмый берең дә,
Юк итә ул кемне тәүге көндә,
Ә кемнедер соңгы көнендә.
Аһ, каһәрле сугыш! Күпме затның
Асыл киләчәген талады.
Яшәде ич Фариз! —
Кайда Фариз? —
Нәселе дә җирдә калмады.
Бер Сәлимә калды. Әйт, Ходаем,
Ник ялгызга язмыш үчле соң?
Ник канаты каерылган кошка
Яңа канат кабат үсми соң?!

*1982—1987*

**КОЛБИЛӘҮЧЕ ГАЯЗНЫҢ ШОМЛЫ СУКМАГЫ**

Көнен — Кояш, төннәрен — Ай,

Җәй соңы гаҗәп аяз;
Аю ярган сукмак буйлап
Урманнан атлый Гаяз.

Аяк бөкләп утырса да
Җитмешенең түрендә,
Тимер тотса, тоткан җирдән
Сындырыр ир күренә.

Балчык беткәч, ахры, Ходай
Әвәләгән корычтан;
Исәр пуля өркеп качкан! —
Сап-сау кайткан сугыштан.

Окоп төптә контуж* алгач,
Әйе, бераз этенә,
Этенсә ни, саны төгәл, —
Сабыйлар бәхетенә.

Шөкер кылыр, дөньясы да
Түгәрәк булды болай:
Үстерделәр Зифа белән
Бер кыз да ике малай.

Тик заманына төкерим! —
Гел борылмадан торды:
Бер хакиме астан сүтсә,
Яңасы баштан корды.
Нигезе нык кураны соң
Ник тиктән яңартырга?!
...Бермәл иза чиктек сасы,
Тфү, махрасын тартырга.

Их, үртәлмәс җиреңнән дә
Үртәләсең шул кайчак!
Сагаеп яшәп саргайдык, —
Тач урмандагы качак.

Сафка тезеп атлаттылар,
Карышыр булсаң, тукмап,
Иреккә омтылган адәм, —
Ярсын үзенчә сукмак!

...Атлый Гаяз акланына,
Уйларына абынып,

Үткәнен берчә битәрли,
Ала берчә сагынып.

Сугыштан кайткан елында
Елкы карап фермада
Йөрде эшләп. Тик тизәктән
Тиз ара китте маза.

Бер төн әтисе мәрхүмнең
Шөгыле керде төшкә;
Колхоз башлыгын күндереп,
Умарталыкка күчте.

...Җил-яңгырда өч дистә ел! —
Әйтергә генә асат,
Тик эш сөйгән бәндәләргә
Эш тә бит — татлы газап.
Ял итә белмәс уңганнар,
Пенсиягә чыккачтын,
Үз умарталыгы итте
Басу як урман астын.

Шул вакытларда микән соң,
Ата ялкау Баязит
Авыл өстенә таратты:
«Корт биләүче Гаяз түгел,
Колбиләүче Гаяз», — дип.

Хәчтерүш тамак түйдырыр,
Хәлледән көлеп кенә;
Кул суздымы әллә Гаяз
Кемнеңдер өлешенә?!

Зар, кар сыман, ишеп-ишеп,
Мир өстенә яуганда,
Күктән бәхет көтмәде ич,
Кара күзләргә кергәнче
Куна ятты акланда.

Сынап торсаң, кешеләрдә
Артмый, кими кешелек;
Сорыкорт шикелле ашый
Безне кара көнчеллек!

Хак, мең-мең колга хуҗа ул,
Коллары — горур кортлар;

Талмаса тырыш канатлар, —
Гаязлар тук, и ныклар.

Юкә суера белмәгәннең
Суга төшә балтасы;
Ә Гаяз шат, хәсрәте юк,
Бар дәүләтен ясау итте
Кырык баш умартасы...
...Чаба Гаяз гомеренең
Йомгагын сүтә-сүтә;
Алачыкта куна калган
Оныгы аны көтә...

Кыз-улларын бик байтактан
Иттеләр башлы-күзле;
Акланда бал аертканда
Суытмадылар эзне.

Ник суытсын! Исәр исләр:
Балга байлык ябешә, —
Йә машина, йә бакча йорт
Өч җәйдә тамып төшә.

Балалар күптән җитеш тә,
Оныклар хәстәр көтә.
И-и-их!
Ахирәткә күчкәч кенә
Дөнья кирәге бетә...

Яшьләргә ни — шәп машина,
Дача — утардай кирәк;
Тыялмас адәм нәфсесен,
Алсын хет акча көрәп!

Алга барырга куштык шул, —
Соң, кемне гаеплисең?!
Йогышлы чир йокмый калмый, —
Телисең, теләмисең!

Тәки өйрәнде лә халык
Тир түкмичә ашарга, —
Арты кычытса, валлаһи,
Кушар сиңа кашырга.
Әнә «Бүлбе»*кирәк» диеп
Тугый төпчек оным та;
Кем теләр яшәргә хәзер

Безнең кебек — кытлыкта.

Без ул кидек кысар камыт,
Үз ирегебез белән,
Эскертләп ашлык өйгәндә
Борчак чүплӘдек көлдән...

Бәлкем, гөнаһка батканбыз,
Бәлкем, Ходай каргаган?! —
Сынык бәхет тапсак, калды
Төшеп ярык арбадан...

...Карт үләннән чык коела,
Салкын күз яше сыман;
Шәпли Гаяз, әллә нинди
Тере сизем, корт күчедәй,
Күңел агачын сарган.

Татлы бал тулышкан мәлне
Тиз тоя «чалыш аяк»,
Юлын кисә күрмә ул чак:
Тормас беркемне аяп.

«Умарталыкка иярт» дип,
Ялына онык, кайтса;
Тиз шәбәя кала егет,
Чирәмгә аяк басса.
Унсигезе тулды да соң,
Тулса да — чәйни сагыз;
Төн кунарга юкка, ахры,
Калдырдым, юләр, ялгыз?!

Кечтек калибрлы мылтык, —
Аюны өркетерлек,—
Барлыгын бар да югыйсә;
Иллә төнен алачыктан
Чыкмаган булсын берүк!..

Яман була дигәне хак
Ач кешенең ачуы;
Ач ерткычны аштан бүлмә! —
Бүлсәң, — ул ут ташкыны...

Картлык куып җитә мәллә, —
Ник йөрәк суга дөп-дөп?

Аклан тып-тын. Егет алҗып
Киткәнме, көтеп-көтеп?

Ни — нәрсә бу?.. Аяк аста!..
Бу бит — мылтык көпшәсе!
Катты Гаяз. Атты күзен...
Галәмнәргә дәшәсе!..

Кайсы! Кайсы! Улмы! Улмы!
Әллә Күкме саташа! —
Гәүдәсеннән... аеры... аеры...
Как үләндә баш ята...

*1999—2000*

**ПУЛЯ ГАРИФҖАН ВАСЫЯТЕ**

**1**

Хак сугышны кичкән каһарманның
Ул соңгысы иде авылда;
Җирләп кайткач, бисмилласыз халык
Кунаклады эчке табынга.

Балигъ булган биш баласы илнең
Төрле төбәгенә сибелгән;
Төпчек малай соңлап, табын кызгач
Кайтып төште салкын Себердән.

Карчыгыннан калып, ялгыз башы
Өч кыш кышласа да ветеран,
Балакайлар никтер юл тапмады,
Күрше-күлән бүлде ихтирам.

Ә силсәвит кыш җитмәс үк болдыр
Турысына өйде утынын;
Кибетенә, күрше коесына
Үзе йөрде соңгы көненәчә, —
Күтәрәлде, шөкер, үз сынын.

Үзеннәнме бүлеп, өч көнгә бер
Сөтен кертте Кәҗә Мәрфуга;
Өйләрдә — ут, үзеңә чут калса,
Түзеп була икән барсына.

Аллаһыга көн-төн ялварсаң да,
Сирәк бирер андый үлемне:

Кичен ятты, таңда... нибарысы
Татлы төшләреннән бүленде...
Табын гөрләп, мәрхүм телдән төшеп,
Сүз кабаргач милек хакында,
Китте кайнар тузгыш, ачы талаш...
Ник берәүсе килсә акылга!..

Ямьсез шау-шу, тәрәзләрне тишеп,
Урамнарга ташкан бер мәлдә
Сискәндерде өйне ят көр тавыш:
«Силсәвиттән!» — диде бер бәндә.

Карашларын әр-битәргә манып,
Сөзеп чыкты да ул һәммәсен:
«Гозере бар иде,— диде. — Укыйм
Әткәгезнең васыятьнамәсен».

Коты сунгән өйгә әйтерсең лә
Очып керде зәңгәр күбәләк,—
Качты шау-шу, зәһәр чырайларга
Кунды шулчак яшерен бер теләк...

Ә силсәвит мәет чыккан өйдә
Алтыны юк комны бүлешкән
Бахырларга кәгазь укып китте
Ишек төптә, баскан килештән.

«Балакайлар, һушым исән чакта
Сырдым сезгә ошбу кәгазем;
Картлык — ваклык, вәләкин дә җилгә
Очырмассыз соңгы вәгазем.

Кичерегез, байлык, мал-мөлкәт тә
Калдыралмыйм сезнең өлешкә,
Аннан кире, ничек бүлмәк кирәк
Дүрт мөешле өйне тап бишкә?
Канатыгыз каккан туган оя
Олы яшьтә инде — сәләмә,
Сата-сутә башласагыз, мәйтәм,
Тарырсыз дип куркам бәлагә.

Күзкәйләрем начар шәйләсә дә,
Күреп торам сезне еpoints
Бу нигезгә кайтыр уегыз юк,
Авыл качкан сезнең йөрәктән.

Шуңадыр да кышкы озын төннәр
Уйлар чорнап яттым гел генә:
Бар җәмәгать йортны ипләп-сипләп
Мәчет корсын ошбу нигезгә.

Хупларсыз дип, өметемне баглап,
Янә бирәм хәер-фатихам;
Васыятем бозмаң, аннан кире
Ләхеттә дә тыныч яталмам...

Тагын... Йөз сум бурыч алган иде
Совет урам Алдак Мирсәет...
Илә раслап ошбу култамгамны,
Мөһер суккан булыр силсәвит.

Йә аннары... өй эч җиһазларын
Бүлешерсез гадел, талашсыз...
Комодның, дим, сулъяк тартмасында
Пилоткада төргәк табарсыз.

Бикбылтырдан саклап килгән идем
Балтырдагы фриц пулясын...
Рәнҗемәче, улым! Бирмәдем шул...
Инде булсын аерым бүләгем!..»
Һәм силсәвит шунда тәмам итеп,
Кырып куйгач салкын тамагын,
Нинди күренешме?— Хәтерләгез
Гоголь «Ревизор»ы азагын!..

Дәррәү басты бары Төпчек, охшап
Кикриген чөйгән әтәчкә,
Кырт ыргылды тышка, ыргылганда
Комод тармасыннан пуля алды,
Бер «акбаш»ны чәлде иптәшкә...

**2**

Көз. Кояшсыз кич. Җил. Актарыла
Сабый чакның күңел дәфтәре:
«Пуля мирас итә, имеш... Һаман
Онытмаган диген, карт тәре!

Малайларның һушын алыр өчен
Елап сораганда малаең
Ник бирмәдең?! Хәзер... дөньям бөтен,—

Пычагыма кетәк сараең!..

Кадерле аңа «фриц кучтәнәче,
Үсә төшкәч бирәм», янәсе;
Юккамыни «Пуля Гарифҗан» дип
Кушамат та такты кемсәсе!..

Аяк сузар сәгать килеп җиткәч,
Иман искә төшкән берәүгә...
Сезнең догаларны Күк ишетсә,
Авыл калмас иде терәүгә!
Бәндә бүген зәңгәр куккә түгел,
Яшел кәгазьләргә табына;
Йөз йортка бер мәчет корырга да
Хәер теләнәләр. Тфү, замана!..»

Ачы уйдан чәчи-чәчи атлап,
Килеп төртелде ул зиратка;
Әнә кәс-кәс яңа кара таучык...
«Эх, мондый чакта безнең братка

Янгын җитми!» дип уфылдап, Төпчек,
Бугазыннан алып бер тында,
Сындырды да куйды яртыны
Һәм...
Сыймаслык эш кылды мыскалга:

Яшь кабергә пуля төя-төя,
«А-ал! Синеке-е!» диеп бакырды,—
Суынып та өлгермәгән җанга
Әйтерсең лә хәнҗәр батырды...

*2001—2002*

**ӨЧ БАҺАДИР ХАКЫНДА ХӘЗЕРГЕ ХИКӘЯТ**

... и не будут более
учиться воевать.

*(Книга пророка Исайи)*

**1**

Кыеш өстәл. Ипи сыныклары.
Тозлы кыяр. Әче кәбестә.
Тап уртада чирек кукрайган:
«Монда мин баш!» дигән бер төстә;
Һәм өч медаль — тере өч туштә.

Өч сугышны кичкән өч баһадир,—
Оньк, Эти һәм дә Картәти.

Хәйран шанлы бәйрәм — Җиңү көне!
Хәрәм китәр, эчсәң тост әйтми;
Хатын заты монда кирәкми!

Илья дәдә Герман сугышында
Сыңар кулын кайткан калдырып;
Ветеранга табында да хөрмәт, —
Ыстаканын сул кулына кочып,
Тәүләп басты, әлбәт, ул торып.

— Хурлык, едрит, ил чигеннән Мәскәү
Капкасына тиклем чигендек,
Соңра... ятып калган яудашларның
Кипшек сөякләрен таптый-таптый,
Берлиннарын барып җимердек.

Дүрт ел буе табаннарны өткән
Утлы үчне тәки кайтардык:
Җаны белән бергә малын алдык,—
Ни-нәрсә бар кулга тотарлык.
Нимкәсен дә, эһем, әвәләдек...
Рус — баһадир сугышырга маһир;
Кабат килсә дошман — карарбыз!
Мылтык тоталмасам, эх, нипочум,
Исем-атын сорап тормыйча да
Буш җиң белән бәреп егарбыз...—

Калтыратып йортның эчен-тышын,
Көлештеләр дәррәү ихахайлап,
Ыстаканнар килде чың да чың:
— Берлинны алган өчен!
— Нимкәне ниткән өчен!
— Белсеннәр урыс көчен!

Төбе күренгәнче эчтеләр дә
Эче тишек кыяр каптылар;
Канга ялкын йөгергәнне көтеп,
Бердәм көйрәтеп тә алдылар;
Өлгер Онык койды тагын да.

Кан кызышкач, сүз әйтергә харап
Җиңеләя төшә ир-атка;
Тик җиңелдән түгел Никитага
Басып тору резин аякта,—
Басмый булмый — ул бит чиратта.

— Кызыл төсне өнәп бетмәсәм дә,
Тугры булдым кызыл байракка;
Кабулны без, әйтим, эт сигәнче
Алып бирдек ахмак Бабракка*.
И башланды мәхшәр азакта:
«Духлар»* берне атса, без бишәвен,
Бишне суйса, чалдык унбишне...
Кисек аяк өчен менә тагып
Кайтардылар шушы көмешне;
Хәтер калды бераз, кәнишне...
— Күтәрик байрак өчен!
— Кабулны алган өчен!
— «Духлар»ны чалган өчен!

Суворовның** маңгаена чәкәп,
Чүкте артка «әфган» лап итеп,
Ыстаканга тамган күз яшьләре
Белән бергә эчте голт итеп;
Юатырга булмас сүз табып.

— Әтиеңә өсти төш, онык!
Үзебезнең тауар, топ-тонык.

«Без янганда ул да янсын» дипме,
Җибәрделәр янә көйрәтеп;
Көнгә ун сүз әйткән Лешканы да
Аласы бар әле сөйләтеп;
«Чех»* кайтарган аны чирләтеп...

Бер карасаң, черкине дә сытмас
Аллаһ бәндәсенә охшаган,
Иллә кайчак хәтерләтеп куя
Ач бүрене, канга сусаган;
Баш «шөребе», растыр, бушаган...
Үз чиратын белеп, кыстатмыйча,
Басты Леша, чак-чак чайкалып:
— Төкерим бер, Әти, Картәти,
Бар дөньясы китсен кадалып!
Чарлап йөреп Кавказ тауларын,
Үз илемдә дошман ауладым;
Алар безне күпләп аулады.
Ул суешта тәмам аңладым:
Берни тормый кеше үтерү,
Юк сүз — азак үкенү дә тетрәү...
Әнә чебен! Шап! Менә шул чама...—
Дертләп куйды чирек өстәлдә,

Мыж чебеннәр шылды бер мәлгә.—
Юк беркемдә алыш-бирешем,
Чәкәшмик моның өчен!

«А-ах-ух»тан соң пуф-пуф тәмәке,
Өйдә төтен — аркан ишәрлек,—
Агыла тәрәздән. Үткән-сүткән
«Ут капканмы?» диеп уйларлык,
Тик эчәргә дәрман җитәрлек.

Ялтырагач та чирек төпләре
Ялт урады Онык кар базын;
Тәгәрәде лә тостлар йомгактай,
Хәзер чутын кемнәр санасын?!
Оныттылар, их-ма, чамасын...

Түңкәйттеләр сәбәп, сәбәпсез:
Илья дәдә — вафат җәмәгате,
Никит — ташлап качкан «хәшәрәте»;
Аяк аста гел мыраулап йөргән
Корчаңгы ач песи өчен дә;
Ә Лешкага «татарка»ны димләү,
Тузган йортны яреннәргә сипләү;
Пенсияләр ишшу артсын өчен,
Нефть елга булып аксын өчен...
Соңга таба тәмам чатлы-ботлы;
Өч баһадир как өстәлгә башлар
Орып, гырлап киткәнчегә чаклы...

...Әҗәл явыз утлы кочагына
Алган булган бугай өчәвен дә
Оран баскан мәлдә урамны;
Кызыл бәйрәм көндә «кызыл әтәч»
Кайдан очып кунган? — сер калды...

**2**

...Һәм килделәр алар, ниһаять!
Корык сыман нәзек озыннар,
Әле генә эссе табадан
Төшкән коймак төсле — кызыллар,
Аһ, алар да бәйрәм ясаган!

Симез эчәгесен өлгер генә
Томырдылар якын коега,
Шарт-шорт килеп, эчәк авызыннан

Сулы комдыр, ләмдер коела.
«Давай!» — «Давайлама! — суы юк».

Шөкрана кылыйк, ярый җиле
Ялкау, ялкын теле котырып
Яламады күрше куралларны,
Шул йөзләгән махмыр күз алдында
Муртайган йорт янды утырып.

Бух-бух аткан очкыннарны күзләп,
Чыш-пыш килде берәү берәүгә:
— Муен тиңе гөнаһларга батып,
Җирдә оҗмах көтеп яткан халык
Нигә килми икән тәүбәгә?!
Ходай рәхиме киң, тарымас та
Идек, бәлкем, каза-бәлагә...

Имән кайрысыдай ерык учы
Белән каплап шәлпек авызын,
Шыбырдады карчык күршесенә:
— Соңра карарбыздыр кар базын!..
Сакладылар шунда... Китмәс исраф.
Их, болар да үткәч, агайне,
Кемнәр куар хутлы самайны?!

...Таралышты төркем. Түзем бетте
Янгын сүнгәнен дә көтәргә;—
Сугыш арты сугыш корбан киткән
Батырларның исемнәрен барлап,
Гөр табында бәйрәм итәргә.

Багор белән тырнап, сөяк-саяк
Эзләделәр утлы күмердән;
Йөзе көйгән өч медальне табып,
Бер кабергә илтеп күмделәр.

...Ул төн этләр улап өрделәр.

*2002*

### *ХӘЕРЛЕ КИЧ!*

*Иртәм исте, төшлегемне кичеп,*
*Офык кочагына авышам;*
*Шул мәлләрдә нигә гел-гел миңа*
*Күзен тутырып карый ахшам*
*Гөлләрем?*

*Балкышларга багып юл сапканда*
*Хәят тузанына күмелмәс,*
*Мең сорауга җавап эзләп,*
*ахыр*
*Сорау билгесе күк чүгенмәс*
*Бәндә бармы?!*

*Илаһ моңнар ник йөрәкне айкый*
*(Асыл шигырь — асылмаска өнди?),*
*Сөю хисе нидән ярала,*
*Явызлыкмы, изгелекме — бакый,*
*Адәм теле нишләп тутыкмый, —*
*Белә кайсыбыз?!*

*...Өстәл тулы ризык — туймый тамак,*
*Янда якыннарым — җаным буш;*
*Тыңла бер сүземне, моңлы килен:*
*— Улың туса, исемемне куш!*

*Йә, хуш!*
*Хәерле кич барчагызга!*
*2005*

**ШӘП ШАГЫЙРЬ ШУЛ!**

Татар шигъриятенә балкып килеп кергән Рим Идиятуллинның исеме бүгенге көндә Р.Фәйзуллиннар, Р.Гаташлар, Г.Рәхимнәр, Р.Мингалимнәр белән беррәттән аталып йөртелергә тиеш иде. Ул бит үзенең иҗат юлын алар белән бер чорда, бер югарылыкта башлап җибәрде. Яисә М.Әгъләмнәр, Зөлфәтләр, Х.Әюпләр арасында булырга хаклы иде. Ни өчен дисәң, 1969 елгы «Беренче карлыгачлар»ны алар бергәләп очырдылар. Ләкин, ни кызганыч, алай булып чыкмады. Язмыш башкачарак хәл итеп куйды. Без аңлаган һәм аңлап бетермәгән төрле сәбәпләр аркасында ул әлеге обоймалардан төшеп калды. Бу исә шагыйрь файдасына да, татар шигърияте файдасына да булмады шикелле. Әмма дә ләкин, ни генә дисәк тә, моңа кадәр Рим Идиятуллин дигән талантлы татар шагыйре булды, шөкер, әле дә бар һәм, иманым камил, моннан соң да булачак. Мин моны һич кенә дә икеләнмичә авыз тутырып әйтәм. Әлеге китап белән танышып чыккан укучыларыбыз да минем белән, һичшиксез, килешерләр дип ышанам.

Ни өчен сүземне шушылайрак башладым соң әле? Бәлки, кирәк тә булмагандыр? Хикмәт шагыйрьнең язмышында түгел, ә шагыйрьнең иҗатында лабаса. Ахыргы чиктә, барысы да барыбер шигырьгә кайтып кала. Шигыре нинди – шагыйре дә шундый.

Әмма бирedә тагын бер хикмәт бар шул. Ул да булса, вакытында күренү, язганнарыңа вакытында гадел бәя бирелү, киң җәмәгатьчелек алдында танылу. Боларның барысы да диярлек Рим Идиятуллинны ничектер читләтебрәк үтте шикелле. Нишлисең, соңлап танылу алган шагыйрьләр әдәбият тарихында Римнән башка да җитәрлек. Моннан ул кадәр фаҗига дә ясарга кирәкмидер. Шулайдыр. Тик без бит бер әдәби казанда кайныйбыз, бер шигъри дөньяда яшибез, кемнең кем икәнен яхшы беләбез, уртакулларның «классик» булып, дан-дәрәҗәләргә күмелеп яшәгәннәрен дә, күпме талантларның ишек төбендә чират көтеп утырганнарын да, бернигә дә игътибар итмичә, фәкать шигырь белән генә гомер сөргәннәрен дә күреп торабыз. Элек тә шулай булган, әле дә әллә ни үзгәреш сизелми. Ә гаделсезлек ул һәрвакыт күңелдә ризасызлык тудыра...

Ә бит Рим — чыннан да безнең талантлы шагыйребез. Ул моннан кырык еллар чамасы элек үк «Казан утлары» журналында, «Беренче карлыгачлар» җыентыгында басылган шигырьләре белән укучыларның мәхәббәтен яулаган иде. Аннан соң да Татарстан матбугатында аның әйбәт-әйбәт шигырьләре даими басылып торды, исеме дә әкренләп телгә керде. Минем тәкъдим белән Римне (Рәшит Гатауллин һәм Халисә Мөдәррисова белән бергә) Татарстан

Язучылар берлегенә дә кабул иттек. Ләкин ул ни өчендер барыбер ахырга кадәр үз шагыйребез булып китә алмады. Заманында Рим Идиятуллин яшьлек беркатлылыгы белән: «Мәрхәмәтле бул, мәхәббәтле Казан!» — дип ихластан дәшсә дә, Казан Уфада яшәүче шагыйренә мәрхәмәтле була алмады. Уфа да үзендә яшәүче татар шагыйрен үз итеп бетермәде. Алай дисәң, ул гомер буе «Кызыл таң» гәзитендә хезмәт итте, әдәбият бүлегендә эшләде, татар һәм башкорт әдипләренең исәпсез-сансыз әдәби әсәрләре аның кулы, аның күңеле аша узды. Вакыт-вакыт үз шигырьләре дә укучыларга барып иреште, хәтта башкорт телендә ике китабы да дөнья күрде. Үзенең юбилей көннәрендә каләмдәшләренең мактау сүзләрен дә ишетергә туры килде аңа. Халык шагыйрьләре Нажар Нәҗми, Әнгам Атнабаев, язучы һәм дәүләт эшлеклесе Таһир Таһиров, шагыйрь Рәдиф Тимершин, күренекле журналистлар Ремель Дашкин, Равил Кәрамов язмалары истә калган. Үзебезнең шагыйрьләребездән Рәдиф Гаташ, Мәхмүт Хөсәен, Госман Садә дә Рим турында язып чыкканнары булды.Тыштан караганда, барысы да үз көенә барган шикелле...

Шикелле генә шул менә. Яшәү рәвешенә, иҗат принципларына, эчке иманына, рухына караганда, аның үзенең башкорт шагыйре буласы килмәгәндер. Шуңа күрә дә ул Башкортстан Язучылар союзына да кермәде. Бәлки, алмаганнардыр? Аның исемен Башкортстан язучыларына багышланган биобиблиографик белешмәләрдә таба алмассың, шигырьләрен башкорт шигърияте антологияләрендә дә, башка төрле җыентыкларда да күрмәссең. Әдәби тәнкыйтьтә дә, әдәбият гыйлемендә дә аның исеме, әлбәттә инде, телгә алынмый. Ул татарча уйлый-фикер йөртә, татарча яза, үзен татарның бер шагыйре дип исәпли. Югыйсә, башкорт әдибе булу мөмкинлегеннән Башкортстандагы бик күп милләттәшләребез бик оста файдаланды. Яшерен-батырын түгел, арабызда бер караганда татар шагыйре булып, икенче караганда башкорт шагыйре булып, өченче караганда тагын татар шагыйре булып, ике арада сикергәләп йөрүчеләребез дә күренгәли. Берьюлы ике милләтнеке булырга тырышучылар да, чын-чынлап ике милләтнеке саналырдай олпатларыбыз да булды. Андыйлар әле дә бар. Ике милләт, ике әдәбият арасындагы бу күренеш – үзе бер феномен, үзе бер күзәтүне сорый торган тема...

Рим каләмдәшебезнең исә Уфада гомер кичерүче татар шагыйре булып каласы килде. Шулай булып калды да. Күрәбез ки, Рим Идиятуллинны татар шигъриятеннән читләтергә, аны күрмәмешкә салышырга бернинди җитди сәбәпләребез дә юк. Биредә инде без Уфадагы игътибарсызлыкны «үз илендә пәйгамбәрләр булмый» дип, ә инде Казанның битарафлыгын «үзе юкның күзе юк» дип кенә аклый алабыздыр. Чыннан да, ни өчен соң аның иҗаты, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булуына да карамастан, бер антологиягә дә, күмәк җыентыкларга да кертелмәгән, аның исеме Татарстан язучыларына багышланган китапларда да юк? «Мәгариф» нәшрияты күптән түгел бер уникаль китап чыгарган иде. Башкорт һәм татар шагыйрьләренең мәхәббәт турындагы берьюлы ике телдә басылган «Мәхәббәтнамә» җыентыгы ул. Анда Кол Галидән башлап бөтен шагыйрьләр дә урын алган. Рим Идиятуллин гына юк. Ни татар шагыйрьләре арасында, ни башкортныкылар арасында... Югыйсә әлеге китапның дөнья күрүендә азмы-күпме үземнең дә мөнәсәбәтем бар иде. Шунысы гыйбрәтле, боларның берсе дә махсус эшләнгән әйберләр түгел бит...

Беренче шигырьләремне «Кызыл таң» гәзитендә бастырып чыгарган, шул чакта ук җылы сүзләре, шигъри киңәшләре белән ярдәм иткән Рим Идиятуллин алдында миңа бераз уңайсызрак та. Әдәбиятка соңрак килгән, күпкә яшьрәк килеш аның иҗатына бәя бирергә мәҗбүрмен менә. Йә инде, шушы да булдымы гаделлек. Югыйсә миңа гына түгел, башка бик күп яшь шагыйрьләргә дә булышкан, «Кызыл таң» аша дөньяга чыгарган, иҗатларына бәя биргән шагыйребез бит ул. Узган гасырның алтмышынчы елларында ук шигърияткә килгән, шуннан бирле каләмен ташламаган, һаман да шундый ук талантлы шагыйрь булып калган Римнең иҗат язмышы турында уйлыйм да сискәнеп китәм. Берәү булса, күптән кул селтәр иде. Рим исә үҗәтләнеп иҗат итә. Күрәсең, шагыйрьлеге, шигъри накалы яшьтән үк нык булгандыр. Шулай булмаса, шигыйрьлеген, шигъри һәм милли рухын саклап кала алмас иде ул.

Рим шигырь белән яши торган кеше. Аның шатлыгы да, кайгысы да — шул шигырьләре. Аның шигърияте — чын, ихлас хисләргә бай, табигый агышлы шигърият. Әтисе Бөек Ватан сугышында һәлак булгангамы, Рим күбрәк үзенең балачагы турында, тол калган аналар турында язды. Миңа аның малайлар турындагы шигырьләре аеруча ошый. Үземнең малай чагымны искә төшергәнгәдер, ахры. Малай чаклар охшаш буладыр, күрәсең. Без дә «малай чакта һәрвакытта югарыга үрмәләдек», без дә «атлар көтеп төне буе күзәтә идек күкне». Әмма иҗат башындагы малай чакларны сагыну хисләре, романтик күтәренкелек күптән юк инде Римдә. Акыл утырткан, бу дөньядан күп гыйбрәтләр алган, үткәненә, бүгенгесенә аек акыл белән карауч ы, дөньяның асылына төшенә баручы шагыйрь ул бүген. Үзенең иҗатында тормыш фәлсәфәсен, яшәү мәгънәсен, яшьлек-картлык төшенчәләренең асылын ачып салырга омтыла. «Дөньяда күпме кеше! Һәрберсенең үз төсе», — дип язган шагыйрьнең үзенең дә шигъриятт ә үз төсе бар. Аның шигъри сүзе — уйчан, үтемле, күңелгә уелып кала торган. Кайчан да булса алар татар укучысына барып ирешер һәм аның күңел байлыгына әверелер дип ышанам. Әлегә исә без аның шигырьләрен өзек-өзек кенә,

вакыт-вакыт кына укый алабыз. Әмма «Кызыл таң»ны даими укып баручылар өчен Римнең иҗатына бәя бирү җиңелрәктер. Гомере буена ул шунда басылды. Башкортстанда яшәүче татар шагыйрьләре өчен «Кызыл таң» альманахларны да, журналларны да, китапларны да алыштыра торган бердәнбер басма булды...

«Тормыш йөге акрын гына күчә кеше йөзенә. Бергәләшеп күтәрсәң дә, иң авыры үзеңә», — ди шагыйрь үзенең бер шигырендә. Авыр шул. Татар өстенә төшкән йөк бигрәк тә. Рим әнә шул йөкне күтәрешә. Ул йөкнең иң авыры, гадәттә, шагыйрьләргә эләгүчән. Рим Идиятуллин кебек талантлы шагыйрьләргә.

Инде сүземне очлап, шуны әйтәсем килә: Рим Идиятуллин, һичшиксез, татар шагыйрьләре арасында булырга тиеш. Хәер, ул болай да безнең арабызда. «Хәерле кич» исемле әлеге китап — шуның бер матур дәлиле. Кулъязмадагы шигырьләрне кайта-кайта рәхәтләнеп укыдым. Элеккеләре дә җанга якын, яңалары да күңелгә ятышлы. Ул гына әйтә ала торган фикерләр, ул гына яза ала торган шигырьләр...

Ни генә дисәң дә, шәп шагыйрь шул безнең Рим Идиятуллин!

*Роберт Миңнуллин,*
*Татарстанның халык шагыйре,*
*Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*
*1993—2007*

**ЭЧТӘЛЕК**


Танылмаган талант. *Н.Нәҗми* .........................

**Шигырьләр**

*Шул бер гомер эчендә*............................

Үз йолдызым .................................
«Без балага бигрәк аз кирәккән...» .......................
«Малай чакта...» ...............................
«Тирән карда «окоп» казып...» ........................
«Безнең авылны...» ..............................
«Сугыш бетте...» ...............................
«Гомеремнең әле таңы гына...» ........................
Сукыр .....................................
Карышу ....................................
Еллар үткәч, туган җиргә кайткач .......................
Тәмамланмаган шигырь ...........................
Чакыр әле! ...................................
Туган якта ...................................
Киткәннәргә үпкә белдермәгез ........................
Бик сагындым, дусларым! ...........................
Җирән бия вафатына .............................
Ә мин калам .................................

*«Шагыйрь халкы гомер бакый...»*......................

Өйрәтү .....................................
«Күзем ачкач...» ................................
«Төн белән көн кавышканын...» .......................
Үткән җәй истәлеге ..............................
«Ялганчы ул — «яратам» дип...» .......................
Бер хатирә ...................................
Көнләшү ....................................
Memento mori! ................................
Элегия .....................................
Кызлар көлә ..................................
«Хуш бул! Хуш бул!..» ............................
Белеп тор! ...................................
Исемемә карата бер шаяру ..........................
Элегия .....................................
Үткәннән узып барыш ............................
Күзләргә дә кердек ..............................

«Гөнаһсыз фәрештә түгелсең...» ........................
«Җир-күктәге барча җисемне дә...» .....................

*Хәлегез ничек?* ................................

Хәерле көн ..................................
«Бу дөньяга без тумаган...» ..........................
Бүген минем туган көнем ..........................
Үземчә ....................................
«Бу гомерем төгәл бер көн кебек...» ....................
Яңа ел шигыре ................................
Чәчсәм дә өмет-орлык ............................
Юату һәм юану ................................
Тишек таш ..................................
Ике сурәт ...................................
Үземә кайтып барам .............................
«Белмим, кеше нидән яралгандыр?..» ....................
Ашыгу һәм ашыкмау .............................
Әллә балан картая?.. .............................
Замандашка ..................................
«Аллаларны үзебез тудырабыз...» .......................
Шундый көннәр була .............................
Без бәхетле ләса! ...............................
«Киттек, дус, елга буена...» ..........................
Барысы да кешеләргә кала ..........................
«Юанмыймын хәзер юк-барларга...» ....................
«Мин берботен. Яманга йә...» .........................
«Кайларда калды сүрелеп...» .........................
«Исәпләсәң, исең китәрлек...» ........................
Шундый халәттә ...............................
«О, Могҗиза! Торма якында...» .......................
«Көсләр өстә, ә зур балык...» ........................
Сукбайлар җыры ...............................
Кара шигырь .................................
Каберем ташындагы язу ...........................
Сез дә бит кошлар кебек ...........................
Көн өстендә туган уйлар ...........................
«Җәйне күрми көзгә кердем...» .......................
«Күрәсеңме, калка яшел үлән...» .......................
«Бәхетегез баштан ашканда...» .......................
«Карая каен...» ................................
«Аптырарсың бәндәләрнең кылыгына...» ..................
Ярый адәм көчсез әле... ...........................
«Ни кылаек, заманы залим булды...».....................
Аптыраганнан язылган шигырь .......................
«Бәхәс бара илдә ике гасыр...» ........................
«Шәһәр агачлары шыр дивана...» .......................
«Нинди гүзәл чәчкә! Бактым аңа...» .....................
Белгән килеш .................................
Нигә, ник? ...................................
Булсачы... ...................................
Исән яшиләр ич! ...............................
Гомер тоташ хушлашудан тора .......................
Җиңелсәң дә — җимермә! ..........................
Сулышымны сулган гөлгә өрдем .......................

*Кичерегез!* ..................................

Бигрәк матур яшьтәсез ............................
Әнкәйләрне яклап ...............................

Битараф ....................................
Баш күтәрү ..................................
«...Ачлык баскан елда...» ...........................
Көзге көндә йорт алдында ..........................
Ишетәсеңме? .................................
Йолдызлы йорт ................................
Толлар урамында ...............................
Авылга — әбигә хат .............................
«Авылыма кайттым, кичтән әйттем...» ....................
«Бер авылда бары бер өй калган...» .....................
«Эт күтәргән хатын бара...» .........................
Гайбәтче авызыннан .............................
«Әйт, Ходаем, мондый гамәл...» ........................
Сукты сәгать .................................
Бергәләшеп китәләр дә... ...........................
Чыра яндырып .................................
«И Әнкәем, табутың!..» ............................
«Әнкәм! Фани дөньялардан...» ........................
«Нух пәйгамбәр көймәсендә безне...» ....................
Тәүбә, тәүбә ..................................
Соңгы хат ...................................
Тәкъдир ....................................
Әллә сез әйтәсез? ...............................
Күз тимәсен! ..................................
Карлар яуганда ................................

*«...Тор син сакта, Шагыйрь...»* .......................

Егерменче гасыр уллары ...........................
Компьютерда язылган шигырь ........................
Тарих дәреслеге битенә өстәмә .......................
Читлектәге кошлар ..............................
Чакыру сүзе .................................
Бабамнарга хитапнамә ............................
Кайткан кошлар белән сөйләшү .......................
Өч сыктау ...................................
Грозный хәрабәләре өстендә гәп ......................
Дүртенче кыш ................................
«Көн туса — сугыш, үтереш...» ......................
Кая бармыйм... ................................
«Җилле генә сүзләрең дә...» .........................
«Санамагыз безне диванага...» .......................
Президентның нотыгы ............................
«Кем сөйли ул анда, иртә-соңмы...» .....................
Җир өстеннән үтеп барганда ........................
«Төкерек чәчеп бәхәсләшә...» ........................
«Тотып булса җилне ятьмәгә...» .......................
Бер карасаң... .................................
«Хафаланма, дустым, хаксызлыкка...» ....................
«Тирләп чыкты мием, җитми уем...» .....................
«Татар булып туганлыгыңа...» ........................
«Үрчетү кирәк татарны...» ..........................
Йөреп ята ...................................
Эз .......................................
Минем Бетховен ...............................
Канатлы иттең безне .............................
Каты борын хакында ике шигырь ......................
Маймыл елының соңгы көнендәге хәтәр хәбәрләргә күңел авазы .....
Тукай туфрагы ................................

Татарлыгын тарсынган туганга .......................
Шагыйрь яше ...............................
Тоташтыр ..................................
«Кибетләрдә сатыла ялтыр портретлар...» ................
«Җирдә — сулар, күктә болыт ага тора...» .................
Метаморфозалар ..............................
Сәер түгел .................................
Нинди сер бар... ..............................
Бәхәснең азагы ...............................
«Борын заман шагыйрьләрнең хакы...» ..................
«Җирнең тәмен арттырырга...» .......................
«Картайды шул шагыйрь...» .........................
«Тукайны күреп төшемдә...» .........................
«Ата махра көйрәтә...» ............................
«Биек тауда әнә «бөек затлар»...» ......................
«Бакырларын алтын-көмеш дип...» .....................
«Нигә күшәр хайван көн вә төн...» .....................
«Бөекләрне хәйран калдырырлык...» ....................
«Ике әдип нидер бүләлмичә...» .......................
«Ябык шагыйрь дә симерде...» ........................
«Робагый дип әтмәлләүче...» .........................
«Хатыннар корсакка калса...» ........................

*«Гөлләргә генә җырлыймын...»* .......................

Укырсыңмы минем шигыремне?.......................
Күңел күнегер булса..............................
Ни галәмәт?! ................................
«Сикерәдер бу йөрәгем...» ..........................
«Сулар да сипкән идем бит...» ........................
«Базарларда җыр яңгырый...» ........................
«И бу салкын бураннар...» ..........................
Кичке авыл йортында ............................
«Сырхау булсаң, гөл дә үсми...» .......................
«Туксан яшьлек әби ята...» ..........................
«Кайгысыз кеше бар микән...» ........................
«Кояш Җиргә һаман карый алмый...» ....................
«Төнге күк җиргә елышкан...» ........................
«Ихатада эт өере...» .............................
Ана сүзе ...................................
«Юл өстендә үлгән кош ята...» ........................
«Мөгезләрен төби-төби...» ..........................
Сагышларым! ................................
Кала... ....................................
Уфа — Казан юлында ............................
Кичер, ага ..................................
Яшәрсең! ..................................
Нигә син түгел?! ..............................
Җаның күбәләк булса да... ..........................
Еламагыз ..................................
Әйтеп китәсем килә .............................
Өзелгән чәчкә................................

**Кечкенә драмалар**

Кино карый ветеран .............................
Малай, шар һәм үзгынчы ...........................
Трагикомедия ................................
Кабер казучы ................................
«Бөдрәләре тузган башны...» .........................

Пәһлеван егет иде ..............................
Тояк тавышы .................................
Атның соңгы таңы ..............................
Сөяк тартма ..................................
Шәмси коесы .................................
Баскычлар ...................................
Яшьлек белән очрашу ............................
Халык артисткасының соңгы роле ......................
Көпә-көндез ..................................
Ул .......................................

**Хикәятләр**

Авыл өмәсе хакында хикәят .........................
Колбиләүче Гаязның шомлы сукмагы ....................
Пуля Гарифҗан васыяте ...........................
Өч баһадир хакында хәзерге хикәят .....................
*Хәерле кич!* ..................................
Шәп шагыйрь шул! *Р.Миңнуллин* ......................

Литературно-художественное издание

**Идиятуллин** Рим Зиннатуллович

**ДОБРЫЙ ВЕЧЕР!**

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Идиятуллин** Рим Зиннәтулла улы

**ХӘЕРЛЕ КИЧ!**

Мљхәррире *Х.Г.Әюпов*
Рәссамы *Л.П.Петрова*
Бизәлеш мљхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мљхәррире џәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 20.09.2007.
Форматы 70×108 $^{1}/_{32.}$ Офсет кәгазе. «Kudriashov» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 11,90+вкл.0,70.
Шартлы буяу-оттиск 12,95. Нәшер-хисап табагы 8,24+вкл.1,32.
Тиражы 1500 д. Заказ С-1129.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111.
Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААЌ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.